ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№11 (394)
НОЯБРЬ 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

РОССИЯ БРЕНДЛАРЫНА КЫТАЙ БАЗАРЫН НИЧЕК ЯУЛАРГА

№11 (394)
НОЯБРЬ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Шарова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Фирдәүсә Бикмәтова, Гомәр Даутов, Илдус Заһидуллин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Ольга Глухова. Автор фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-2530
Басарга кул куелды: 18.11.2024
Чыгу көне: 22.11.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

БАШТА – «РОСТКИ», АННАРЫ – КФУ

Ноябрь ае редакциягә бер дә тик утырырга бирми. Билгеле, чөнки галәми масштабтагы вакыйгалар үзләре дә республикабызны һич уратып узмый. Башта Казан «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» дип аталган II Халыкара форумны каршылады. Татарстанның Инвестицияле үсеш агентлыгы башлыгы Талия Миңнуллина әйтүенчә, әлеге форумда 25 тән артык килешү төзеләчәк. Сөйләшүләр киң колачлы – мәгариф, сәнәгать, эшлекле сөйләшүләр һәм килешүләр, IT, туризм һ.б. кебек бик күп юнәлешләрне үз эченә ала. «Алар меморандум гына булып калмас, ә чын килешүләр булыр, дип өметләнәбез», – диде ул.

Форум тәмамлануга, көн кадагына икенче олы вакыйга килеп баса: Татарстан Казан университетының олылый, чөнки дөньякүләм билгеле, данлыклы уку йортына 220 ел тула!

Сезнең өлгер редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның яртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китерep бирешле,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китерep бирешле,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 103 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары ТИК ТАТАРСТАНДА

«КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ»: ВАКЫТ АГЫШЫНА БИРЕШМИ

2004 елның ноябрендә Казан университетының 200 еллыгы уңаеннан үткәрелгән тантанага АКШтан Евгений Евтушенко килә. Шагыйрь үзенең атаклы «Казан университеты» поэмасының яңа, заманга ярашлы рәвештә үзгәртелгән версиясен алып киләчәк дигән сүзләр дә йөри. 18 ноябрьдә КДУның актлар залында Евтушенко, вәгъдә ителгәнчә, дистә еллар дәвамында мәхәббәт, сәясәт һәм тарих турында иҗат иткән иң яхшы әсәрләрен укый. «Казан университеты» поэмасыннан да өзекләр яңгырый. Шагыйрь үзе аңлатканча, поэманы үзгәртергә дә туры килмәгән диярлек. «Юлий Даниэль ГУЛАГтан кайткач, миңа барак стеналарына «Казан университеты»ннан өзекләр язылган булуы турында сөйләде, кайда күмер, кайда кадак белән тырнап язганнар. Өзекләрне сөйләп тә күрсәтте. Ихласлык һәрвакыт хак булмаса да, яңа укылган барлык материаллардан соң, «Казан университетын» кабаттан укып чыктым һәм, бәхеткә, бу очракта минем ихласлыгым ялган булмавын аңладым».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Россия–Кытай: хезмәттәшлек кырлары
Кайсы төбәкләр өчен КХР – эре сәүдә партнёры

6. Шанхай.
Россия брендлары Кытай базарын ничек яулый ала

16. Россия сәясәте аксакалы
ҮК КПСС секретаре ярдәмчесеннән тикшерүче нәрсә белергә тели

20. Партия, комсомол һәм могҗизалы икона
Казан мэры исемен дөнья ничек таныды

24. Студент, аспирант, язучы...
Ринат Мөхәммәдиев КДУга ничек барып җиткән

28. Дөньяны матурлык коткара...
Хатыйп Миңнегулов сәяхәтләрне ничек оештырган

36. Казан университеты.
2009 елда ул нинди үзгәреш кичерә

игелекле эшләр

44. Үзбәкчә сайлаулар
Россия күзәтүчесе язмалары

48. Кытай кухнясы фәлсәфәсе
Кытайлар ни өчен ут, агач, җир һәм металл «ашый»

58. Хәләл эчемлек
Аны кайдан табарга

мәңгелек кыйммәтләр

62. Тарихи сәхифә
Әхмәтһади Максуди төрмәдә ничек исән калган

66. Онытылмас исемнәр
Татар хатын-кызларыннан беренче фән кандидаты кем булган

70. Таныш булыгыз, «Тарки-Тау – 2024»
Нинди яңа форматлар әдәбият үсешенә этәргеч бирә

74. Китап киштәсе
Шигъриятнең милли авазлары кайда яңгырый

86. Афиша

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: kpfu.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР



16.10

Дмитрий Чернышенко, РФ вице-премьеры, – Президент Владимир Путин рәислегендәге Хөкүмәт утырышында:

«

– Шуны билгеләп үтәргә кирәк: Россия чит ил кунаклары өчен ачык. Быел җәйге сезонда чит ил туристларын, үткән ел белән чагыштырганда, бер ярым тапкырга күбрәк кабул иттек. Димәк, безгә килергә теләүчеләр бик күп. Июль–август айларында гына да Россиягә бер миллионга якын чит ил туристы килде, ә ел нәтиҗәләре буенча бу сан биш миллион тирәсе булачак. Мәскәү һәм Петербургтан кала, Приморье, Краснодар, Ставрополь крайлары, шулай ук Карелия Республикасы, Татарстан Республикасы, Новосибирск, Иркутск, Свердловск өлкәләрендә чит илләрдән килүче кунаклар саны яхшы арта баруы күренә.

09.10

Саламзаде Эртегин Абдул Ваһаб оглы, Азәрбайҗан Милли фәннәр академиясенең Архитектура һәм сәнгать институты генераль директоры, – Казанда, «Заманча академик фәндә Россия халыкларының телләре, әдәбиятлары һәм мәдәниятләре» халыкара фәнни форумында:

«

– Франция, Польша, Австралия әдәбиятын һәм сәнгатен бездән башка да өйрәнерләр. Ә менә татар, башкорт, азәрбайҗан, үзбәк, казах, кыргыз мәдәниятен сезнең белән бездән башка беркем дә өйрәнмәячәк. Өйрәнә калсалар да, нинди дә булса алдан ук билгеләп куелган караштан чыгып кына өйрәнәчәкләр дип шикләнә алабыз. Ягъни сезнең белән бездә яхшырак итеп моны беркем дә эшләмәячәк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

05.10

Гөлүс Баязитов, Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, – Яңа Кырлай авылында традицион Атлар көнендә:

«

– Безнең алда Татарстан Республикасында атчылыкны үстерү, татар токымын популярлаштыру бурычы тора. Ләкин атлар үрчетү коры мавыгу яки терлекчелекнең бер юнәлешен үстерү генә түгеллеген яхшы аңлыйбыз. Атлар – безнең тамырлар, тарих, без аларны онытырга тиеш түгел. Балаларыбызда аларга карата мәхәббәт тәрбияләү, бу чыганакларны тирән аңларга өйрәтү бик мөһим. Безнең алда торган бурычларны һичшиксез үти алачагыбызга ышанам.

Фото: digital.cap.ru, azmiu.edu.az, tatarstan.ru

игелекле эшләр
акыллы гамәлләр/
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстан белән Кытай **нәрсәдә** күренә

Россия брендларына Кытай базарын **ничек** яуларга

Император университеты **ничек** федераль булып китә

КДУны тәмамлаган Камил Исхаковның исеме **кайчан** дөньяга танылa

КДУны тәмамлаган Ринат Мөхәммәдиев туган ягына **кемне** алып кайткан

КДУ профессоры Хатыйп Миңнегулов **ничек** бүреләр белән очрашкан

РОССИЯ – КЫТАЙ:

2023 елда

Россия белән Кытай арасында товар әйләнеше

240,11 МИЛЛИАРД $

26,3%

2022 ЕЛГА КАРАТА ҮСЕШ

2023 елда

Татарстан белән Кытай арасында товар әйләнеше

1,6 МИЛЛИАРД $

58%

2022 ЕЛГА КАРАТА ҮСЕШ

СЕРГЕЙ ЛАВРОВ, РФ ЧИТ ИЛЛӘР МИНИСТРЫ:
«Татарстанның Кытай дусларыбыз белән уңышлы хезмәттәшлек буенча бай тәҗрибә туплавын бик рәхәтләнеп билгеләп үтәм. Дипломатик бәйләнешләр ныгый, сәүдә-икътисадый һәм фәнни-техник юнәлешләргә караган килешүләр гамәлгә ашырыла».

2020 елда Россия һәм Кытай лидерлары, ике ил арасындагы товар әйләнешен ике тапкырга арттырып, 2018 елга аны 100 миллирд долларга һәм 2024 елга 200 миллиард долларга җиткерү бурычын куйганнар иде.

НӘТИҖӘДӘ ӘЛЕГЕ КҮРСӘТКЕЧКӘ 2023 ЕЛНЫҢ НОЯБРЕНДӘ ҮК ИРЕШЕЛДЕ.

Фото: rais.tatarstan.ru, tatar-inform.ru

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КЫРЛАРЫ

АМУР ӨЛКӘСЕ, ЕВРЕЙ АО, ПРИМОРСК КРАЕ, ТАТАРСТАН, ТУЛА ӨЛКӘСЕ –

2022–2023 ел йомгаклары буенча Россия Федерациясе төбәкләренең Кытай Халык Республикасы белән хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеге рейтингының биш лидеры.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ, ТР РӘИСЕ:

«Кытай Татарстанның иң эре сәүдә партнерларының берсе санала. Бу илдән безгә бик күп товарлар кирә, шул исәптән машина төзелеше, электроника һәм башка тармаклар продукцияләре».

Россия белән Кытай арасындагы товар әйләнеше

2024 елның беренче ун ае нәтиҗәләре буенча*

202,211 МИЛЛИАРД $

2,8%

УЗГАН ЕЛНЫҢ ӘЛЕГЕ ЧОРЫНА КАРАТА ҮСЕШ

94,142 МИЛЛИАРД $

товар Россиягә Кытайдан кертелгән

ҮСЕШ – 4,7%

108,069 МИЛЛИАРД $

товар Кытайга Россиядән кертелгән

ҮСЕШ – 1,1%

* КХР таможнясы мәгълүматлары буенча

Авторын фотосы. РЕКЛАМА

ШАНХАЙ:
РОССИЯ БРЕНДЛАРЫ ӨЧЕН КЫТАЙ БАЗАРЫНА ЮЛ

Ольга Глухова

Шанхай. Борынгы һәм мәңге яшь кала. Күккә ашкан биек йортлар һәм борынгы урамнар. Таң калдырырлык шопинг һәм уңайлы чәйханәләр… һәр почмагының үз тарихы булган шәһәр бу. Өстәвенә, әлеге мегаполис – бизнес өчен идеяләр һәм ачышлар лабораториясе дә. Бирегә эш сәфәре белән килгәч, мин, ниһаять, Кытай базарына чыгу өчен ниләр кирәклеген аңладым. Бу турыда тәфсилләбрәк сөйләп бирәсем килә.

Шанхай – Кытайның иң эре мегаполисы гына түгел ул. Бу шәһәр – дөньяда иң зур кулланучылар секторына ия ил базарына чыгу өчен мөһим стратегик нокта да. Биредә иң заманча технологияләр һәм меңьеллык традицияләр искиткеч оста үрелә, шул рәвешле бизнес-стратегияләрне сынар һәм җирле шартларга яраштырыр өчен менә дигән тәҗрибә мәйданчыгы пәйда була. Кытай базарында үз урынын яуларга ниятләгән Россия компанияләренә аның үзенчәлекләрен исәпкә алу зарур. Аларның иң әһәмиятлеләре Кытай җәмгыятенең мәдәни нюансларына һәм кулланучыларның тәрбия үзенчәлекләренә бәйле.

ФӘЛСӘФӘ МӘКТӘПЛӘРЕ ҺӘМ КЫТАЙ БАЗАРЫ

Кытай мәдәнияте һәм, димәк, кулланучыларның үз-үзен тотышы күпчелек очракта өч фәлсәфә мәктәбенә – Конфуций, Дао һәм Будда тәгълиматларына нигезләнә. Әлеге тәгълиматлар социаль нормаларны гына түгел, ә бәлки, мәсәлән, брендларның клиентлар белән үзара мөнәсәбәтләренең төп принципларын да формалаштыра. Конфуцианлык төп игътибарны әхлакый кыйммәтләргә һәм иерархиягә юнәлтә, бу кулланучыларның структуралаштырылган ихтыяҗларында чагыла. Даочылык гармониягә өйрәтә, бу исә экологик трендлар – мәсәлән, электромобильләр үсеше белән бәйле булырга мөмкин. Буддачылыкка хас булган минимализм кытайларның аңлаешлы һәм функциональ продуктларга өстенлек бирүендә чагыла.

ИЕРОГЛИФ ГАЛИҖӘНАПЛАРЫ

Маркетинг стратегияләрен фәлсәфә принципларына яраклаштыру уңышка ирештерергә мөмкин. Мисал – Кытайдагы Nespresso ребрендингы. Исемен сүзгә-сүз тәрҗемә итмичә, компания «Нонг ю ко фей» («Куе һәм тәмле каһвә») дип аталган, бу мәдәни аңлашылмаучылыклардан котылу һәм кытайлар аудиториясе белән яхшырак элемтә урнаштыру мөмкинлеген биргән. Әгәр дә инде «Неспрессо» әлеге базарга «Нао си пай со» («Авызга керә торган ризык») иероглифы белән чыкса, хәлләр бөтенләй башкача булыр иде...

Сүз уңаеннан, әгәр сез үзегез өчен тирән мәгънәгә ия хәрефләрдән «җыелган» атамагыз Кытайдагы потенциаль кулланучыга нәрсә дә булса аңлата дип уйласагыз, ялгышасыз. Алар өчен бу ниндидер бер код яки IP-адрес кебек кенә – мәгънәсе дә, бренды да юк. Биредә иероглифлар хакимлек итә.

ТОВАРНЫ КИРЕ КАЙТАРУНЫ ОЕШТЫРУ МӨҺИМ

Кытай сатып алучыларының яртысыннан артыгы (52 проценты) продуктны сатып алганчы сынап карарга тели икән, ә ошамаган товарны кире кайтару мөмкинлеге базар өчен стандарт булып тора. Соңгы тикшеренү нәтиҗәләре шундый. Әлеге кагыйдә массакүләм куллану товарларына да, премиаль сегментларга да – автомобильдән алып электроникага кадәр – теләсә нинди төр товарга да кагыла.

Кытай базарына чыгарга ниятләгән Россия брендларына шуны исәпкә алу мөһим: кулланучыларның югары сыйфатка өметләнүе товарны сынау программаларын эшләүне, товарны кире кайтаруның җиңел шартларын оештыруны таләп итә. Брендка ышаныч уңышка турыдан-туры йогынты ясаган e-commerce (электрон сәүдә) секторындагы югары көндәшлек шартларында әлеге аспект аеруча мөһимгә әйләнә.

ОФФЛАЙН ВАФАТ, ЯШӘСЕН ОНЛАЙНМЫ?

Кытайлар онлайн-шопингка өстенлек бирә. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, аларның 46 проценты

онлайн сатып ала, бу – дөньяда иң югары күрсәткеч. Традицион сәүдә үзәкләрендә сату кимегән шартларда брендлар поп-ап маркетлардан файдаланып үсә. Әлеге вакытлыча сәүдә мәйданчыкларында фирмалар үз продукциясен сынап карый һәм кулланучылар турында мәгълүмат туплый. Шул рәвешле поп-ап маркетлар брендларга үз аудиториясен яхшырак аңларга һәм аннары продукцияләрен онлайн-платформаларда уңышлы сатарга булыша. Димәк, Кытай базарына чыгарга ниятләгән Россия компанияләренә бизнес-модельләр төзүдә экспериментларга әзер булырга кирәк.

УЕНЧЫКЛАР ҺӘМ ЯШӘҮ СТИЛЕ

Кытай яшьләре тиңдәшсез куллану культурасын эшли – анда җирле «Поп-Март» бренды уенчыклары һәм курчаклары үз шәхесеңне таныту элементына әйләнә. Сумкага тагылган уенчыклар һәм башка аксессуарлар статус һәм яшәү стиле турында ачык сөйли, һәм брендлар бу психологияне үз маркетинг стратегияләрендә актив файдалана. Дөресен әйткәндә, безгә бу бераз сәеррәк тоела, әмма мин ничек бар, шулай сөйлим.

Арт-инициативалар Кытай бизнесында кызыклы урын алып тора. Gentle Monster кебек заманча кибетләр үз мәйданын сәнгать галереясына әйләндерә һәм шул рәвешле клиентларны җәлеп итә, алар турында мәгълүмат туплый. Сәнгатькә бәйле чараларда катнашу кибетләрдә трафикны 25 процентка арттырырга мөмкин, бу исә бик файдалы.

СӘҮДӘНЕҢ ЯҢА СТАНДАРТЫ

Кытай кулланучыларының өстенлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә торган иң куәтле системалардан берсе – инфлюенс-маркетинг*. Кытай кулланучыларының якынча 89 проценты товарны блогерлар һәм инфлюенсерлар киңәшенә таянып сатып ала. Әмма биредәге инфлюенс-маркетинг системасы беренче карашка гына бик гади тоела, чынлыкта исә шактый катлаулы. Ул берничә баскычка бүленә. Иң югарыда KOLs лар (Key Opinion Leaders**) тора, алар җәмәгатьчелек фикерен формалаштыра. Күп миллионлы аудиториягә ия бу инфлюенсерлар брендлар белән миллионнарча долларлык контрактлар төзи, әмма хәзер аларга ышаныч кимү күзәтелә. Соңгы тикшеренүләр күрсәткәнчә, кытайларның 47 проценты бары тик коммерция мәнфәгатьләрен генә күздә тоткан бу киңәшләрдән шикләнә башлаган.

Шулай булса да, урта баскычтагы блогерлар һәм микроблогерлар аудитория белән нәтиҗәле эш алып бара әле. Алар, товарга кызыксыну уятып, кулланучылар белән аутентик мөнәсәбәт урнаштыра. Мәсәлән, «сейлз-блогерлар» еш кына товарларга ясалма кытлык тудыру стратегиясеннән файдалана: продукция инде сатылып беткән яки аңа бик зур чират тезелгән дип алдый.

Әлеге факторларны исәпкә алып, 2025 елга Кытайда инфлюенс-маркетинг базары 40 процентка үсәр, ә аңа кертелгән инвестицияләр күләме 30 миллиард долларга җитәр, дип фаразлана. Әмма брендларга кертем структурасы үзгәрешенә әзерләнергә кирәк: эре KOLs ларга ышаныч кими, бу исә микроблогерларны һәм натив рекламаны перспективалырак юнәлешкә әйләндерә.

СЫЙФАТ БӘЯДӘН МӨҺИМРӘК

Кытай кулланучыларын югары сыйфатлы товарлар белән генә кызыктырып була. Түбән бәяләр сегментында көндәшлек бик зур, һәм чит ил компанияләренә анда үтеп керүе бик кыен. Уртача һәм премиум-сегментлар исә халыкара брендлар өчен зуррак мөмкинлекләр бирә. Россия компанияләре тагын шуны да аңларга тиеш: Кытай сатып алучысын уникаль төргәк, матурлап тәкъдим итү һәм югары ышаныч белән генә яулап булачак.

Ниһаять, тел мәсьәләсе. Кытайда бөтен кеше дә инглизчә сөйләшми. Ә менә кытай теле үзен өйрәнүчеләр саны буенча хәзер дөньяда беренче урында тора. Бу сезгә нәрсә турында булса да сөйлиме? Кытайда сиздерми генә искәртәләр: безнең илдә бизнес белән безнең телдә шөгыльләнү мәслихәт.

P.S. Сүземнең азагында аңлашылмаучанлыкның нәрсәгә китерә алуы хакында сөйлисем килә. Шешәгә тутырылган су җитештерүче бер чит ил кешесе Кытай базарына чыгарга ниятли. Бренд – танылган, продукциясе – югары сыйфатлы. Әмма бизнес барып чыкмый. Моңа бик гади бер нәрсә комачаулый – шешә туптулы булмый. Кытайлар, инде кемдер бу шешәдәге суны эчкән, дип уйлый һәм товарны сатып алудан баш тарта. Килешәсездер, Кытайда клиентларның мәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алуның никадәр мөһим булуын күрсәтә торган шәп дәлил бу.

* Социаль челтәрләрдә блогерлар һәм фикер лидерлары киңәшләре дә исәпкә алынган маркетинг формасы.
** Җәмәгать фикеренең төп лидерлары (ингл.).

ИМПЕРАТОР, ДӘҮЛӘТ, ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

Фотолар проект авторлары архивыннан

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

Казан университетына – 220 ел!

Ике гасырдан артык вакыт эчендә ул берничә мәртәбә исемен дә алыштырган: Казан император университеты, Казан дәүләт университеты, Казан федераль университет... Ул эшләгән дәвердә бирердә миллионлаган студент белем алган. Кемнәрдер үз өлкәләрендә танылган белгеч булып җитешкән, араларында исемнәрен бөтен дөнья белгәннәре дә бихисап. Һәр факультет, һәр белгечлек юнәлеше үзенең шундый йолдызлары белән мактана, горурлана ала. Күпчелеге юбиляр университетны тәмамлаучылардан торган «Татарстан» редакциясе дә «КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР» проектын башлап җибәрә.

Ел буена без сезне, кадерле укучыларыбыз, иң кызыклы шәхесләр белән таныштырып барырга тырышырбыз. Алар укыган елларда университет нинди булган, бирердә тупланган белем тормышларында, эшләрендә үз урыннарын табарга ничек ярдәм иткән – барысын да беләчәкбез. Аларга (безгә дә) дөрес юл күрсәткән мөгаллимнәребезне дә җылы сүз белән искә алырбыз. Бераз сагышланырбыз да. Казан университеты – бик күп татарстанлы өчен альма-матер бит. Татарстанлылар өчен генәме соң?! Россиянең һәр гаиләсендә һичшиксез Казан университетын тәмамлаган кеше табылачак.

ПРОЕКТ АВТОРЛАРЫ

Казан университетын тәмамлаучылар:

Татьяна Челышева

Әскәр Сабиров

Руфия Рәхмәтуллина

Фәридә Хәбибуллина

Луиза Шарова

Евгения Зыкова



Рәшит Хәйретдинов

Анастасия Шахерзад

Виктория Майорова

шулай ук:

Ирина Морозова

Игорь Глушков



Дмитрий Сивков

Виктория Зубова

Студентка Талия Хәбриева.

Россия фәннәр академиясе президенты урынбасары, РФАнең Иҗтимагый фәннәр бүлеге академик-секретаре, РФ Хөкүмәте каршындагы Законнар һәм чагыштырма хокук белеме институты директоры Талия Ярулла кызы Хәбриева.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

ТАЛИЯ ХӘБРИЕВА

Дмитрий Сивков

Казан университеты хәзерге вакытта Россия фәннәр академиясе президенты урынбасары, РФАнең Иҗтимагый фәннәр бүлеге академик-секретаре, РФ Хөкүмәте каршындагы Закон чыгару һәм чагыштырма хокук белеме институты директоры булып эшләүче Талия Ярулла кызы Хәбриева өчен чын тормыш мәктәбенә әверелә.

ӘТИСЕ КЫЗЫ

1969 ел. Унбер яшьлек кыз, тыны кысылып, күзен дә алмый цирк гөмбәзе астындагы кешегә карап тора. Юк, анда һава гимнасты түгел, аның гади төзүче булып эшләүче әтисе күтәрелә.

– Казан циркын дәүләт комиссиясенә тапшырганда, гөмбәз астында ярык барлыгы ачыклана. Биектә эшләүче монтажчыларны яисә альпинистларны чакырып торырга вакыт калмый. Әтиемә үзе эшләгән 3 нче төзелеш-монтаж идарәсе җитәкчелеге әлеге ярыкны ничек тә булса ямарга куша. Миңа калса, башка кандидатуралар булмый да. Барысы да минем күз алдымда эшләнде: этиемне, бау белән бәйләп, шундый зур биеклеккә күтәрделәр! Әти һава күренеп торган әлеге ярыкны ничектер ямап куйды. Шундый биеклектәге эшне башкарып чыккач, аны иртәрәк җибәрделәр. Шуңа күрә без өйгә бергә кайтып киттек, – дип искә ала 55 ел элек булган вакыйгаларны Талия Хәбриева.

Аның әтисенә бәйле истәлекләре күп. Насыйров Ярулла Салават улы – сугыш ветераны, орден белән бүләкләнгән. Атказанган төзүче дигән мактаулы исеме булмаса да, иптәшләре, хезмәттәшләре арасында ул абруй, хөрмәт казанган кеше. Шәһәр өчен әһәмиятле бик күп биналар – цирк, Спорт сарае, Химиклар мәдәният йорты төзелешләрендә катнаша ул...

– Мин кечкенәдән әти белән бөтен төзелешләргә дә диярлек йөрдем. Әле дә хәтерлим, әни хастаханәдә ята, мине калдырыр кеше юк, этием белән эшкә барам. Бервакыт 30 градус салкыннар башланды, мәктәптә укулар булмый, диделәр, ә мин әти белән – эшкә. Мине автобус двигателенең җылырак җиренә утырттылар да юлга кузгалдык. Ул чакта беренче-икенче сыйныфларда укыганмындыр инде, – дип, сагынып искә ала Талия Ярулла кызы. Аның белән аралашканнан соң, шуны аңлыйсың: кыз өчен әтисе һичшиксез зур авторитет булган – таләпчән, гадел, тормышка һәм бала тәрбияләүгә традицион карашлы. Бу яктан Талия, һичшиксез, әтисе кызы.

БЕРЕНЧЕ ДЖИНСЫ ЧАЛБАР

«Беренче тапкыр джинсыны кайчан кидең?» – совет чорында тәрбияләнгән берәүне дә бу сорау аптыраштта калдырмас. Ул чакта джинсыга ия булу ниндидер бер хыялны тормышка ашыруга тиң иде, шуңа күрә хәтергә дә уелып кала.

Талия Ярулла кызы да аптырап калмады. Җитмәсә, бу аның беренче тапкыр чит илгә баруына бәйле булып чыкты. Монысы да 70 нче еллар өчен гайре табигый хәл була.

– Чит илгә путевка белән мине университетның өченче курсында бүләкләделәр – комсомолда актив эшләгән өчен. Беләсезме, минем чит илгә түгел, ә диңгезгә исем китте! Егерме яшьтә беренче тапкыр диңгез күрдем, – дип истәлекләре белән уртаклаша Талия Хәбриева.

Бүләкләвен бүләклиләр дә, тик путевканы үзеңә сатып алырга кирәк, җитмәсә, баргач та акча кирәк булачак. Бер тиенсез барып булмый, чөнки кибетләрдә кытлык хөкем сөргән СССРда бу әле берәр дефицит әйбер сатып алу мөмкинлеге дә. Ләкин Талиянең үз акчасы була. Каян килеп, дисезме? Беренчедән, ул югары стипендия алып укый – 55 сум, бу ул чакта уртача хезмәт хакы 60–70 сум булганда. Шуңа күрә мондый акча гаилә бюджетына яхшы ярдәм санала, икенчедән, кыз китапханәдә дә эшли. Менә шул «китапханә акчаларын» җыеп бара. Өченче курска 300 сум акча туплый һәм барысын да Болгариягә сәяхәткә тота. Болгар левларына алыштырылган сумнарның зур өлеше совет яшьләренең хыялы – Wrangler Америка джинсы чалбарын сатып алуга китә. Бу инде сезгә Польша Odraсы, Һиндстан Miltonsы яисә Болгариядә тегелгән «Рила» джинсы чалбары түгел, аларны зур кыенлык белән булса да, Казанда да юнәтеп була. Дөрес, Советлар Союзындагы кебек, Болгариядә дә мондый чалбарлар кибеттә сатылмый, аларны алыпсатарлар – фарцовщикларда гына табарга мөмкин.

– Шуларның берсе биредәге студент икән, сөйләшә торгач, аның этник төрек булуы да ачыкланды Минем татар кызы икәнемне белгәч: «Сиңа яхшы ташлама ясармын», – диде. Ниндидер бер йортның подъездына кереп киеп карадым. Ул вакытта бездә дә шулай иде. Ләкин Казанда мин «толкучка» базарына барырга җөрьәт итмәс идем, – дип сөйли әңгәмәдәшем.

Фотолар Талия Хәбриеваның шәхси архивыннан

ГАДЕЛ БУЛЫРГА ТЕЛӘҮ ЮРИСТЛЫККА КИТЕРӘ

Балачакта юридик фәннәр докторы табиб булырга хыяллана. Әнисе белән бертуктаусыз докторларга яки аның янына хастаханәгә йөрү шул хыялга китергәндер. Киләчәктә әнисенең газапларын җиңеләйтергә теләү дә. Ләкин башлангыч мәктәпне тәмамлаганда, кызның медицинадан күңелен кайтарырлык вакыйга була. Бишенче сыйныфтан инде юрист булырга хыяллана башлый. Соңрак вузга керү өчен бирелгән мәктәп характеристикасында язылганча, әлеге сайлауга «бөтен нәрсәдә гаделлеккә омтылу хисе дә» йогынты ясагандыр.

– Кайсы вузга? Вариантлар юк – бары тик Казан дәүләт университеты. Беренчедән, шәһәрдә бердәнбер юрфак шунда, икенчедән, туганнарым мине беркайчан да укырга читкә җибәрмәсләр иде.

Гаиләдә патриархаль традицияләр көчле. Беренче-икенче курсларда аны дәресләргә олы абыйсы Рөстәм озата һәм каршы да ала. Сеңлесенең университетка керү хыялы турында белгән абыйсы белән Талия мәктәптә укыганда ук әлеге уку йорты тирәләрен урап йөри. Шул рәвешле кыз күпләр өчен кадерле аббревиатура – КДУга, университет биналары урнашкан бу тирәләргә, мондагы ыгы-зыгыга ияләшә бара, үзен аның бер өлеше итеп тоя башлый.

Бары тик керү имтиханнарын уңышлы тапшырасы гына кала. Талия бу яктан да булдыра – бөтен фәннәрне бик яхшы белгесенә тапшыра. Шуңа күрә башкалар кебек кердемме-юкмы дип баш ватмый. Гәрчә ул вакытта юридик факультетка укырга керү конкурсы бик зур булса да – 1 урынга 12 кеше. Әле ул чакта бер мәзәк тә йөри: Виктор Павлович Малков (ул вакыттагы факультет деканы), математикадан имтихан кертсәк, юридик факультетка конкурс шактый кимер иде, дип шаярткан, имеш.

ДИСКОТЕКА УРЫНЫНА – КИТАПХАНӘ

Бүген Талия Ярулла кызыннан студент еллары турында сораштыра башласаң, ул үзенең бер тапкыр да дискотекада булмавы, аның каравы, күп вакытын китапханәдә үткәрүе хакында сөйләр иде. Чыннан да төп вакыт уку белән үтә. Китаплар белән аның ниндидер рухи бәйләнеше бар кебек тоела. Иң беренче хатирәләр дә китапка бәйле: аңа әле өч яшь тә юк, ул Казан трамвай депосы китапханәсендә идәндә, китап киштәләре арасында утыра. Чөнки әнисе Фәүзия Сәйфетдин кызы шунда эшли. Үскәч, студент булгач, тагын китапханәгә эшкә керә.

Әйе, студент чорының ниндидер якты мизгелләре, бәлки, аны урап та узгандыр. Мәсәлән, «Юристлар көне» кебек: университетта узган тантаналы кичәдән соң, студентлар, мөгаллимнәр, җыелышып, «Лысая гора» дигән урынга баралар, гитарага кушылып җырлар җырлыйлар, палаткаларда куналар. Ләкин болардан башка да кызның тормышы вакыйгаларга бай була, гел лекция-зачет-имтиханнар белән генә чикләнми.

– Казан яшь тамашачы театры каршындагы драма студиясен, кинога, филармониягә, театрларга йөрүләремне зур җылылык белән искә алам. Сүз уңаеннан, классик музыка концертларына билетлар арзан түгел иде, шуңа күрә һәрвакытта анда бара алмадык. Ә менә опера театрына кесәң сай булса да бара аласың: галеркага билет 30 тиен тора, кинотеатрда кичке сеансны карап кайтуга тиң диярлек, – дип, 70 нче еллардагы бәяләр белән таныштыра әңгәмәдәшем.

СТЕНА ГАЗЕТАСЫНЫҢ БАШ МӨХӘРРИРЕ

– Күрдегезме? «Прогульщикларга» шәп чәпәгәннәр! – деканат каршындагы стенаның буеннан-буена газетаның чираттагы саны беркетелгән көннәрдә мондый сөйләшүләр гадәти хәл була.

Җәмәгать эшләре... Ул вакытта студент тормышы ансыз бармый. Талия өчен дә эш табыла. Араларында иң кызыгы – «Комсомол прожекторы». Дәрескә йөрмәүчеләрне ачыкларга, факультет стена газетасын (тагын бер анахронизм, бүгенге сүзлекләр аны «әдәби-рәсемле халык иҗаты төре» дип аңлата) редакцияләргә туры килә. Ул вакытта коллективның көнүзәк проблемаларын хезмәттәшләренә ачык-төгәл итеп җиткерүнең бердәнбер мөмкинлеге була бу. Стена газетасы А1 форматындагы алты-җиде ватманны бер-бер артлы ябыштырып эшләнә, газета бөтен коридор стенасын били, рәсемнәр, факультет тормышы турындагы хәбәрләр белән тула. Шуңа күрә мөхәрриргә еш кына бер үк вакытта мәкаләләр авторы да, рәссам да булырга туры килә, ярый әле бала чактан рәсемнәр ясарга ярата. Сюжетларның төрлесен сүрәтләргә туры килә, мәсәлән, дәрес вакытында йоклап утыручы группадашларын. Кайберләрен ул аңлый да, чөнки очын очка ялгап яшәү өчен, төннәрен йөк ташырга, станциядә яки портта вагон бушатырга да туры килә аларга. Тир түгеп тапкан тиеннең бәясен кыз үзе дә яхшы белә.

КАРАҢГЫ КӨННӘР

Нигә һаман төшкә пычрак идән керә? Талия Хәбриевага моны аңлар өчен, ниндидер фаразларга күз салырга кирәкми. Ансыз да аңлашыла.

Кагыйдә буларак, яшьләр беренче акчаларын студент чакта эшләп таба. Талия исә ул вакытка инде хезмәт тиененең ничек табылганын белә. Әнисе гел авырып торганга, гаиләдә тормышны этисе тарта. Берүзенә генә, әлбәттә, бик авыр, шуңа күрә балалар мөмкин кадәр тизрәк кул астына керергә тырыша. Кыз бишенче класстан этисе эшләгән «Казаньхимстрой» трестының 3 нче төзелеш-монтаж идарәсе конторасында идән юа. Башта әнисенә булыша, аннары, югары сыйныфларда, берүзе тырыша.

Ул барыннан да бигрәк получка һәм аванс көннәрен яратмый. Бу көннәрдә эшчеләр беренче каттагы кассага агыла. Кирза итекләрдән әз, пычрак төшеп кала.

– Аннан соң озак еллар буе гел бер төш кереп интектерде, – ди Талия Ярулла кызы. – Идән такталарына уелап кергән пычракны юып бетерә алмый изаланам, икенче катта, баш инженер бүлмәсендәге лакланган өстәлнең тузанын кат-кат сөртәм, ялтыраганчы.

Әтисе белән төнге каравыл торулар да искә төшеп тора. Гаилә башлыгы үзе эшләгән шул ук 3 нче төзелеш-монтаж идарәсендә каравылчы булып эшләргә дә мәҗбүр була. Йокыны да чиратка куялар, кая анда төшләр күрү. Кыз иртән туп-туры университетка лекцияләргә йөгерә.

КИСКЕН БОРЫЛЫШ

1980 ел – беренче тапкыр Олимпия уеннарын кабул иткән ил өчен дә, Талия өчен дә истәлекле ел – кыз КДУның юридик факультетын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый һәм аспирантурага керә. Ике елдан соң аның фәнни җитәкчесе, профессор Валерий Васильевич Лазарев Мәскәүгә күченә. Университеттагы кафедра мөдире аспиранткага үзенең фәнни җитәкчелеген тәкъдим итә, ләкин кыз әлеге тәкъдимнән баш тарта. Бу адым намуссызлык, фәнни җитәкчесенә хыянәт итү кебек тоела аңа, һәм Талия дә җитәкчесе артыннан Мәскәүгә китә.

Әлеге мизгелне хәзерге вакытта РФА академигы үзенең һөнәри карьерасында кискен борылыш дип саный. Кемдер ул вакытта университеттагы перспективалы тәкъдимнән баш тартуны һәм, асылда, билгесезлеккә китүне авантюра дип саный. Башкалага фәнни дәрәҗәгә өметләнүчеләр бөтен Советлар Союзыннан җыела. Рәсми яктан Казан университеты аспиранты саналып, шулар арасында югалмау, адашмау бик катлаулы була.

1985 елда Талия Хәбриева Бөтенсоюз совет законнары фәнни-тикшеренү институтында кандидатлык диссертациясен яклый. Сүз уңаеннан, бүген әлеге оешма РФ Хөкүмәте каршындагы Законнар һәм чагыштырма хокук белеме институты дип атала һәм аның җитәкчесе – Талия Ярулла кызы Хәбриева. Хәер, боларның барысына да соңрак ирешелә. Ул чакта яшь фән кандидаты Казанга, үзе белем алган факультетка кайта, анда 11 ел укыта: мөгаллим, аннары дәүләт һәм халыкара хокук кафедрасында ассистент һәм доцент булып эшли. Һәм нәкъ менә университет еллары аны галим һәм шәхес буларак формалаштыра да.

ИКЕ ТӨП САБАК

– Әлбәттә, беренче чиратта, Казан университеты – минем өчен тормыш мәктәбе, беренче һөнәри тәҗрибә урыны. Мин моның юридик факультетка бәйле булуы белән бик бәхетле.

Ул чорда анда үз артларыннан ияртеп барырга, яшьләргә канат куярга сәләтле күренекле галимнәр, мәшһүр мөгаллимнәр эшләде. Болар барысы да коллективта үзенчәлекле атмосфера тудырды, һәм һәркем анда лаеклы урын билләргә тырышты, – дип искә ала бүген Талия Ярулла кызы.

Шул чакта ике төп сабакны үзләштердем, дип тә өсти әңгәмәдәшем: беренчесе – ярдәм һәм киңәш сорарга оялмаска; икенчесе – җаваплылыкны үз өстеңә ала белергә һәм беркайчан да сынатмаска. Бу, әлбәттә, җиңел булмый, мәсәлән, яшь ассистентка уртача йөкләнеш 400–600 сәгать булганда, шул ук хезмәт хакына 1200 сәгать укытырга да туры килә.

Әмма бу принципларга таянып эшләү алга таба бик ярдәм итә. Әйе, хәзер дә шул рәвешле эшләвен дәвам итә героинябыз, югыйсә үзенең күпсанлы вазифаларына бәйле гаять зур эшләрне башкарып чыгу мөмкин дә булмас иде. Бер үк вакытта дәүләт структурасының эш үзенчәлекләрен аңлап эш итүче яхшы оештыручы булырга да, үзенең фәнни статусын саклап калырга да туры килә.

Талия Ярулла кызы бик авыр мизгелләрдә, иртәнге сәгать дүрттә торып, әнисе белән 10 чакрым ераклыктагы бакчага барып, җиләк җыюларын искә төшерә. Җиләкне тиз генә җыеп, университетка, дәресләргә өлгерерлек итеп кайтып җитәргә дә кирәк. Урамда июнь – сессия вакыты. Хәер, мондый рухи көч өсти торган хатирәләрнең барысын да язып бетереп булмый. Алар әлегә академик Хәбриеваның шәхси стена газетасында урын алган.

КДУның тарих-филология факультеты студенты Олег Морозов.

Олег Морозов 1982 елда басылган «Вожатый китабы» белән «Хөкүмәт сәгатендә». Балалар ялын оештыру, савыктыру проблемалары, аларның сыйфатын яхшырту турында сөйләшү бара.

Олег Морозов ТРның иң яхшы студентларын үз исемендәге премия белән бүләкли.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

ОЛЕГ МОРОЗОВ

Дмитрий Сивков

Ул – Россия сәясәте аксакалы: беренче чакырылыштан алып сигезенче чакырылышка кадәр РФ Дәүләт Думасы депутаты, Дәүләт Думасы вице-спикеры, Федерация Советы әгъзасы, РФ Президентының Эчке сәясәт идарәсе башлыгы... Кеше буларак та, шәхес буларак та тәрбияләнүендә Казан дәүләт университетының роле бик мөһим. Сезнең каршыда – депутат Морозов университетларының сигез чакырылышы.

I ЧАКЫРЫЛЫШ

Казан егете Олег Морозов мәктәпне тәмамлаганнан соң кая укырга керәсен төгәл белә – Казан университетының тарих-филология факультетына, әлбәттә! Моның ике сәбәбе була. Беренчедән, анда әтисе укыган – сугыштан соң студент була, кызыл диплом алгач, аспирантурага керә, тик аннары язмыш партия эше юнәлешенә алып кереп китә.

Әмма иң мөһиме шул: Олег унынчы сыйныфта укыганда үзенең чын гуманитарий булуын аңлый, өстәвенә, моннан бер ел элек кенә тарих-филология факультетында ачылган яңа «Фәнни коммунизм» белгечлеге турында мәгълүмат та күзенә чалына. Программасы белән таныша да нәкъ менә шунда укырга керергә карар кыла. Керү баллының югары булуы да, конкурс та куркытмый егетне. Ул гомумән куркаклардан түгел, бар нәрсәнең дә үзеңнән генә торуын яхшы аңлый. Шуңа күрә имтиханнарга тырышып әзерләнә һәм мөмкин булган 20 баллдан 19ны җыя. Немец теленнән үзенә нигә дүртле чәпәүләрен генә аңламый кала, әмма ул вакытта өч имтихан нәтиҗәсе генә исәпкә алына, шунлыктан өч бишле белән ул бернинди киртәләрсез укырга керә.

Сүз уңаеннан, хәзерге студентларга факультетның «тарих-филология» дип аталуы бераз сәеррәк тоелырга мөмкин. Ләкин 1939 елдан 1980 елга кадәр ул чыннан да шулай атала. Эш шунда ки, беренче курсларда филологлар да, тарихчылар да кайбер фәннәрдән лекцияләрне барысы бергә тыңлый. Соңрак, студентлар саны күпкә артканга күрә, аларны аералар. Булачак тарихчылар һәм филологлар бер үк бинада – Ленин урамындагы дүрт катлы йортта белем ала, хәзер анда КФУның А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты урнашкан.

II ЧАКЫРЫЛЫШ

Студент тормышы беренче көннәреннән үк Олегка бик ошый. Төркемнең яртысы (читтән килүчеләр) – тулай торакта, яртысы үз өйләрендә яши. Әмма казанлылар Зур Кызыл урамындагы тулай торакта еш була. Бүлмәләрдә бергәләп семинарларга да әзерләнәләр, үзешчән сәнгать номерларына репетиция дә ясыйлар, гитарага кушылып җырлыйлар, кичләр утыралар. Монда инде Олегка тиңнәр юк – ул иҗат иткән җырлар факультетта гына түгел, Морозов, Кузин, Алеев триосы башкаруында университет сәхнәләрендә дә яңгырый.

Ул дәвер студентларын спорттан башка да күз алдына китерү кыен. Олег ату спортын, шулай ук классик һәм хәрби өч төр ярышын – ату, граната ыргыту һәм тулы хәрби киемдә кросс йөгерүне сайлый. Җиңел атлетика белән проблемалар килеп чыкмый, ә менә чаңгыда узышудан Морозов ничек тә котылып калу ягын карарга тырыша. Дөрес, бер тапкыр барыбер сыналырга һәм кышкы өч төр ярышының бөтен программасын үтәргә (атарга, граната ыргытырга, чаңгыда йөгерергә) туры килә. Һәм барлык хәрби кирәк-яракны күтәреп, Казансуның карлы бозында чаңгыда узышуы егетнең хәтеренә мәңгегә уела. Студент шулай чыныга.

Иҗтимагый тормышның тагын бер ягы – ирекле халык дружинасында кичен кизү тору һәм шәһәр урамнарындагы иминлекне саклау. Кайвакыт милиция белән бергә, кайчагында исә алардан башка да кизү торалар. Ике очракта да хулиганнар беләкләренә «ДНД» тасмасы бәйләгән, көч-куәтләре ташып торган егетләрнең күзенә чалынмаска тырыша. Хәер, тарихчы һәм филологлар мускулларын тренировкаларда гына түгел, башкача да ныгыта.

III ЧАКЫРЫЛЫШ

Студент еллары – үзең эшләп тапкан беренче акча да әле ул. Олег инде 8 нче сыйныфны тәмамлагач ук, җәйге каникулда бер ай буе Урта Кабандагы туңдырма фабрикасында эшләгән була. Ә студент елларында, стипендиядән тыш, төп керем йөкче булып эшләүдән керә. Тимер юл вагоннарын да, елга портында баржалар да бушатырга туры килә. Эш төнлә, авыр, тик бик файдалы: бер төндә стипендиянең өчтән беренә тәңгәл 15 сум акча эшләп була.

Фотолар Олег Морозов архивыннан

Нәрсә туры килсә шуны – ниндидер капчыклар, мичкәләр, әрҗәләр бушаталар... Тозлы помидор банкалары төялгән вагон бушатулары исләрендә калган. Хезмәт хакыннан тыш, һәркайсына өчәр литрлы икешәр банка помидор да биргәннәр, хәзергечә әйтсәк, кешбэк булган инде.

Сүз уңаеннан, эшләп тапкан акча юк-барга сарыф ителми. Яртысын әнисенә биреп бара, ә икенче яртысына, мәсәлән, кышкы пальто сатып алына.

IV ЧАКЫРЫЛЫШ

Олег Морозов өчен университет уку йорты гына түгел, беренче эш урыны да: ул анда ун ел буе укытучы, физика факультетында фәнни коммунизм кафедрасы доценты була.

Диплом алуга, мөгаллим кафедрасы артына баса. Яшь егет өчен бу зур сынауга әйләнә, чөнки аның беренче шәкертләре физфакның бишенче курс студентлары була. Яшьләре буенча алар укытучыларыннан өлкәнрәк, чөнки ул чакта физфакка армиядән яки рабфактан соң гына укырга кереп булган. Йөзләп бишенче курс студентына фәнни коммунизм нигезләрен аңлату өчен, аудиториягә нинди хисләр белән керүен Олег Викторович хәзергә кадәр дулкынланып искә ала.

Аларның күпчелеге әлеге фәнне дә, аны укытучыны да бер бәхетсезлек дип кабул итә. Әмма аңардан котылып булмый – фәнни коммунизмнан дәүләт имтиханы бирергә туры киләчәк. Яшь мөгаллим лекцияләрен кызыклы итү өчен бөтен көчен бирә. Һәм тырышлыгы бушка китми, дистә еллар үткәч тә, аның элеккеге укучылары мавыктыргыч лекцияләрне рәхәтләнеп тыңлауларын искә алалар. Бу – чыннан да горурланырлык казаныш.

Димәк, ул максатына ирешкән – атамасы күпләрне өркетә торган фән артына гади кешеләр язмышы, ил язмышы, дөнья сәясәте серләре яшеренүен аңлата алган. Бүген болар барысы бергә сәясәт белеме дип атала.

V ЧАКЫРЫЛЫШ

Беренче автомобиле дә университет еллары белән бәйле. Дөрес, Олег Викторович аны инде мөгаллим булып эшләгәндә – 1983 елда ала. Бу легендар «копейка» – ВАЗ-21011 була. Үз заманы өчен шактый кыйммәт – 6 мең сум тора. Әмма мөгаллимнең дә эш хакы зарланырлык булмый. Төп эшеннән тыш, ул түләүле өстәмә лекцияләр дә укый, фән кандидаты булганга, алар өчен 10 ар сум түләнә. Дөрес, ул чакта кирәкле сумманы барыбер тулысынча туплый алмый, җитмәгәнен әти-әниләре биреп тора.

Үзенең яраткан «Жигули» машинасыннан 1989 елда Мәскәүгә, КПСС Үзәк комитетына эшкә киткәндә генә аерыла ул. Анда да әле якын дустына сатып калдыра. Бүген болар барысы да бик еракта калган һәм бөтенләй башка тормыш мизгелләре булып хәтердә калка: ул вакытта университет бинасы янында гына түгел, гомумән Казан үзәгендә парковка эзләп интекмисең әле. 1986 елда партия өлкә комитетына эшкә күчкәч, ул машинасын Ирек мәйданында, үз кабинеты тәрәзәсе каршында ук диярлек калдыра. Казан ул чакта – бөтенләй башка шәһәр, һәм бүген автомобиль йөртүчеләрне борчыган проблемаларның эзе дә булмый әле.

VI ЧАКЫРЫЛЫШ

Машина йөртү күнекмәләренең тормышның авыр вакытында да кирәге чыга. Университеттагы тормыш сабакларының да күпчелеге файдалы була.

1991 ел аның өчен ныклыкка сыналуга әйләнә. Гадәттән тыш хәл буенча дәүләт комитеты путчыннан соң Коммунистлар партиясе тыела. КПСС ҮК секретаре ярдәмчесе эшсез кала: кабинетын бикләтеп, үзен Генераль прокуратурага чакырталар. Тикшерүчене җитәкчесе Валерий Болдин белән бергә Морозовның путчта катнашу-катнашмавы кызыксындыра. Моны дәлилләү бик җиңел булып чыга: илне тетрәткән август көннәрдә Морозов гомумән Мәскәүдә булмый.

Әмма партия хезмәткәренең элеккеге казанышлары яңа чынбарлыкта башкача күзаллана. Мәскәүдәге югары уку йортларында элекке Үзәк комитет хезмәткәренә шикләнеп карыйлар һәм, фәндәге уңышларына карамастан (кандидатлык диссертациясен иртә яклаган, 29 яшендә инде доцент булган), эшкә алырга атлыгып тормыйлар.

Бөтен тормышы да Советлар Союзы белән бергә җимерелгәндәй тоела. Бу мизгелләрдә дә университет сабаклары ярдәмгә килә: нәкъ менә шул студент еллары чыныктырган, күңел төшенкелегенә бирелмәскә, борынны салындырмаска, бернигә дә карамый алга барырга, максатка ирешергә өйрәткән бит. Берара машина йөртү күнекмәләренең файдасы тия – ул таксида эшләп ала.

VII ЧАКЫРЫЛЫШ

Мәскәүдән Казанга кайтырга туры килә. Бирелә «Советская Татария» (хәзер – «Республика Татарстан») газетасына сәяси күзәтүче булып урнаша. Бу очракта да университет тәҗрибәсе ярдәмгә килә. Эш шунда ки, студент тормышы, бигрәк тә фәнни коммунизм бүлегендә, үз фикерләреңне

дөрес ирештереп, халык каршында чыгыш ясау күнекмәләренә өйрәтә, моңа тагын рефератлар һәм фәнни хезмәтләр язу осталыгы да өстәлә. Болар барысы да егетнең телен дә, язма сөйләм осталыгын да чарлый, моңа табигатьтән бирелгән сәләте дә өстәлгәч, сәяси темаларны яктыртканда үз өслүбе тиз табыла.

Алай гына да түгел, аның берникадәр журналистлык тәҗрибәсе дә була әле: студент чактан ук үзенең фәнни җитәкчесе, хәзер инде мәрхүм Петр Борисович Уманскийның автордашы сыйфатында «Коммунист Татарии» (1991 елдан – «Татарстан») журналы белән хезмәттәшлек итә. Соңрак «Биотехнология» фәнни-җитештерү берләшмәсендә башта җәмәгатьчелек белән элемтә бүлегендә эшли, аннары директор урынбасары була. 1994 елда Мәскәү округы буенча РФ Дәүләт Думасына сайлауларда, 46 процент тавыш җыеп, кандидат Олег Морозов җиңә.

VIII ЧАКЫРЫЛЫШ

Дәүләт Думасының иң тәҗрибәле һәм абруйлы депутатларыннан берсе, хәзерге вакытта Контроль комитеты рәисе Олег Морозов альма-матер диварларында да, Казанда да еш кунак була – төбәк атнасы кысаларында аена бер тапкыр кайта. Үзе белем алган уку йортында соңгы тапкыр быел октябрьдә булган. Университеттагы музейны караган, сабакташы, университетның хәзерге президенты Рияз Минзарипов белән очрашкан.

Моңа кадәр республика министрлыклары дәрәҗәсендәге идарәчеләр укый торган кадрлар резервы мәктәбе тыңлаучыларына лекцияләр укый. Алар өчен эчтән сөенә лектор: чагыштырмача яшь – 40 яшь тирәсендәге бу җитәкчеләр инде мөһим, абруйлы вазыйфалар башкара. Алар белән аралашу лекторның үзен дә КПСС Үзәк комитетында карьерасын башлаган вакытка – 35 елга артка чигергәндәй була.

Гомумән, элекке студент Морозов өчен КФУның төп бинасы коридорлары вакыт машинасы порталын хәтерләтә. Алар буйлап барганда, гомерендә гаять тирән эз калдырган шәхесләр каршына килеп чыгар төсле тоела: ректорлар Михаил Тихонович Нужин яки Александр Иванович Коновалов, партком секретаре Җәмил Галим улы Сафиуллин, фәлсәфә укытучылары Леонид Ильич Тузов һәм Муза Павловна Медянцева яки тарихчы Аркадий Семёнович Шофман...

Хәер, университет коридорларында Олег Викторовичның үзен дә ихтирамга лаек шәхес буларак хәтеренә төшерүчеләр шактыйдыр әле...

Олег Морозов – КДУның физика факультетында фәнни коммунизм укытучысы.

КДУ тәмамлаган һәм кайчандыр анда укыткан Олег Морозов университет телеканалы сорауларына җавап бирергә һәрвакыт әзер.

Камил Исхаков тантаналы пленумда чыгыш ясый. 1978 елның октябре.

– Могҗизалы иконаны Казанга кайтару идеясе миндә, мөселман кешесендә, ничек туды дип сорасалар, һәрвакыт дөресен әйтәм: балконда басып торганда.

– Сезнең белән сөйләшкән арада... Бәрәңге әнә нинди матур кызган инде. Бер кыздыра башлагач, бөтен Казанга җитәрлек итеп кыздырабыз аны хәзер... Тәлинкәләргә бүләбез дә тозлы кыяр, тозлы гөмбә белән рәхәтләнеп сыйланабыз... Казаныбыздагы һәркемнең ашы тәмле булсын!

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

КАМИЛ ИСХАКОВ

Татьяна Вафина

Кешенең бәрәңге әрчү-кыздыруыннан ук аның турында күп нәрсә белеп була. Бигрәк тә бу бәрәңгене ашап караганда. 1973 елда Казан университетының физика факультетын тәмамлаган, 1989 елдан 2005 елга кадәр Казан мэры булган Камил Исхаков кыздырган бәрәңгедән авыз итүчеләр бик сирәктер ул. Ә менә безгә андый бәхет тәтеде. Тагын әле аның студент яшьлеге турында тәмләп сөйләвен дә тыңладык: КДУ студентларының барысы да яраткан бу ризыкны телне йотарлык итеп әзерләргә ул нәкъ шул чакта өйрәнгән дә инде...

«ЙОДРЫК КАДӘРЛЕ, ЙОМРЫ ГӘҮДӘЛЕ, БИГРӘК ТӘМЛЕ БӘРӘҢГЕ!»

БЕРВАКЫТ, Камил Шамил улы мэр булып эшләгән чагында, өендә бәрәңге кыздырган, һәм бу аның гаиләсендә иң яраткан ризыкка әйләнгән.

– Аннары өйдәгеләр бик еш сорый башлады, – ди ул. – Дөресен генә әйткәндә, табага күптән кагылганым юк инде. Элекке күнекмәләремне җуйганмындыр да, мөгаен... Менә хәзер тикшереп карарбыз! Миңа бәрәңге әрчү бик ошый. Кызыклы процесс. Тынычландыра... Моның белән мин әле комсомол замнында ук шөгыльләнә идем...

КЕШЕНЕҢ ЫШАНЫЧ КАНАТЛАРЫ

БЕРВАКЫТ дөньяда комсомол дигән шундый искиткеч мәктәп булган.

– Ни генә дисәләр дә, партия белән комсомол кешегә ышаныч канатлары куя иде, – дип раслый Камил Исхаков. – Кеше һәрвакыт нәрсәгәдер ышанырга тиеш. Ышанусыз, имансыз яшәү мөмкин түгел. Бездән бу «конфетны» тартып алгач, яшьләр шунда ук караучысыз калды. Комсомолны алыштырырга төрле омтылышлар ясала, яшьләр хәрәкәтләре оештырыла, әлбәттә...

Мәчеткә кергән саен мин кешегә иманның никадәр кирәк булуын тоям. Яшьләр мәчеткә дә, чиркәүгә дә йөри – бер сүз белән әйткәндә, дингә тартыла. Дин дәүләттән аерылган җәмгыятьтә бит бу. Аларны беркем мәҗбүр итми, үзләре килә. Мин бары тик үз күзәтүләремне, көн саен күргәннәремне генә сөйлим. Мин моны нәрсәгә әйтәмме? Телибезме, теләмибезме – процесс бара. Ата-аналар да, Татарстанда җәмгыять тә беркемне дә мәҗбүр итми. Җитмәсә, мәчет беркем режимына да яраклашмый – көндезге сәгать 12 дә өйлә намазы укыла, ә эштә бу вакытка киңәшмә билгеләнергә мөмкин. Ягъни дөньяви тормыш дин тотучылар өчен ислам дәүләтләрендәге кебек яраклаштырылмаган. Әмма кешеләр өйлә намазына барырга мөмкинлек таба, мәсәлән, үзенең төшке аш вакытын шуңа багышлый. Бу факт.

ҮЗЕН ДӨНЬЯГА ТАНЫТКАН МЭР

БЕРВАКЫТ, Камил Шамил улы Казан башлыгы чагында, газеталарда «Үзен дөньяга таныткан мэр» дигән башисемнәр пәйда була.

– Бу башисем, ихтимал, мин Казан мэры сыйфатында Бөтендөнья мэрлар оешмасы рәисе урынбасары булгач уйлап табылгандыр. Ә эш болай булды. Мин бу системага килеп кергәндә, мэрларның оешмалары күп иде. Ә БМО, без сезнең белән эшләр идек, тик сез бер оешмага берләшә алмассызмы икән, ди. Алайса уңайсыз, ди. Моны мин хәзер шулай гадиләштереп әйтәм инде...

Һәм берләштерү процессы башланды. Озакка сузылды ул. Без биш ел буе устав яздык. Мәсәлән, ниндидер бүлек турында фикер алышырга җыелабыз. Мэрлар бер-берсе белән бәхәсләшә, уртак карарга килә алмый, вакытвакыт бөтенләй башка юнәлешкә кереп китә... Мин тыңлап-тыңлап тордым да: «Егетләр, әйдәгез менә шулай эшлик әле!» – дидем. Һәм кинәт барысы да ризалашты. Күрәсең, шуңа күрә мине төп орган составына сайлаганнардыр, һәм мин төп оешма составына эләктем. Алга таба бурыч: һәр урынбасар нинди дә булса континент яки төбәк вәкиле булырга тиеш. Һәм шул вакытта без Евразия бүлеген уйлап таптык. Мине бу бүлекнең президенты һәм бөтендөнья оешмасының вице-президенты итеп сайладылар.

Мин һәрвакыт казанлыларга хезмәт итәргә, файда китерергә тырыштым. Моны ихластан әйтәм. Хезмәтемне күреп, Казан халкының мине хөрмәт итә башлавын иң зур казанышым дип саныйм. Моны тоя идем. Димәк, гомерем бушка узмаган!

КАЗАНЫМНЫҢ ҖИР АСТЫНДА

БЕРВАКЫТ Бауман урамында хәрәкәтне туктаталар. Ә элек исә анда троллейбуслар да йөргән...

– Ә мин әле мэр булып эшли генә башлаган идем, – дип искә ала Камил Шамил улы, – дусларым миңа: «Камил, әгәр халыкның хуплавын, алга таба да мэр булып калырга телисең икән, анда тагын юл хәрәкәтен ач! Транспорт белән килсеннәр-китсеннәр. Барысы да канәгать калыр, барысына да уңайлы булыр», – ди. Мине дөрес эшләмәвемдә инандырмакчы булалар. Әмма мин сизәм – артка чигенергә ярамый, мин дөрес юлда! Һәм мин Бауман урамын реконструкцияләүне башладым. Әмма проб-

Фото: Ната Смирнова, Юлия Калинина

лема нәрсәдә иде соң? Кесәң тулы акча булса, теләсә нинди эшкә тотынырга мөмкин. Ә бу урамны яңартырга керешкәч, әллә ниләр ачылды! Барысы да мине каргый башлады, хәтта теләктәшләрем дә икеләнеп калды. Без үзебезгә бик зур эш күләме булдырдык! Йортларның фундаменты һәм диварлары дым тарткан, ишелә. Әгәр без ул вакытта торгызу эшләрен башламасак, тарихи һәйкәлләребез күптән җимерелеп бетәр иде инде. Чөнки 1957 елга кадәр Идел суының биеклеге 17 метрга түбәнрәк булган. Куйбышев ГЭСын төзегәч, су күтәрелгән. Дамба салынган, су агып тормый шикелле, ә ул барыбер шәһәр үзәгендәге подвалларга, йортларга астан юл тапкан. Безнең бурыч корылмаларны саклап калу иде, ә бу гаять зур эш. Астан туфрак чыгарганда, нәрсә генә табылмады. Мәсәлән, имәннән салынган борынгы канализация коллекторларына тап булдык. Хәтеремдә, бер урында кызыклы әйбер казып чыгардылар: бура тора, ә эчендә тагын бер бура. Бу шундый суыткыч булып чыкты! Буралар арасына боз салалар, эчке бура эченә исә ит куялар, һәм ул бозылмыйча саклана икән.

Кыскасы, без барлык фундаментларны ачтык, киптердек, эшкәрттек, бөтен гидроизоляцияне эшләдек... Шуңа күрә, әлбәттә, миңа җәяүлеләр урамы – Бауман урамыбыз бик кадерле.

Гомумән, Казанның һәр почмагын яратам. Һәм кайдадыр берәр нәрсә начар булса, бик нык борчылам. Барысын да эшләргә өлгермәдем бит.

Хәзер исә Казаныбызда кунакны теләсә кая алып барырга була, кызарырга туры килмәячәк. Бигрәк тә Кремльне күрсәтергә яратам. Кичен елга техникумыннан аеруча матур күренә ул: дамбага бассаң, утлары балкып торган искиткеч гүзәл Кремль гаять зур су көзгесендә чагыла...

ХЫЯЛ ТОРМЫШКА АШСЫН ӨЧЕН, ЭШЛӘРГӘ КИРӘК

БЕРВАКЫТ Казанга мең ел тула...

– Меңьеллыкка без бик күп нәрсәгә ирештек. Ничекме? Бик гади: нәрсәнедер тормышка ашыру өчен, бары тик эшләргә генә кирәк! – дип раслый Исхаков. – Мәсәлән, метро турында икеләнүләр бик күп булды. Тик бер генә мисал китерәм. 1996 ел. Без Минтимер Шәрип улы Шәймиев белән метрополитен төзелешендәге беренче ташны салабыз. Шул ук көнне Уфада да шундый ук таш салына. Без метро төзелешенә баштанаяк кереп чумдык. Бүгенге нәтиҗәләргә ничек ирешә алдык – үзем дә шаккатам. Артка борылып карасаң, нindидер могҗиза бит бу! Мин 2005 елда мэр вазыйфасыннан киткәндә, инде биш станция һәм ун километр юл эшли иде. Урамда инде ничәнче ел, ә Уфада таш ничек салынган, шул килеш ята. Селкенмәгән дә. Без эшләдек, алар – юк, һәм менә нәтиҗәсе шундыйрак булып чыкты*.

МЭР, БЕЗГӘ КАЗАН ИЗГЕ АНА ИКОНАСЫН КАЙТАРЫП БИР!

БЕРВАКЫТ Казанга Ватиканнан Казан Изге Ана иконасы кайтарыла. Аны үз урынына кире кайтаруда төп рольне Казан мэры Камил Исхаков уйный.

– Могҗизалы иконаны Казанга кайтару идеясе миндә, мөселман кешесендә, ничек туды дип сорасалар, һәрвакыт дөресен әйтәм: балконда басып торганда. Мэр кабинетында Кремль урамына чыга торган балкон бар. Ишек ачык, ел саен хач йөреше процессиясе шушы балкон астында туктала һәм халык: «Мэр, безгә Казан Изге Ана иконасын кайтарып бир!» – дип кычкыра иде. Ә мин бит бу вазыйфада эшли башлаганнан бирле кешеләргә файда китерергә омтылдым. Әгәр дә андый ихтыяҗ бар икән, димәк, һичшиксез ярдәм итәргә кирәк.

Без иконаның Рим папасында булуын ачыкладык. Һәм шул вакытта мин, рәсми тел белән әйткәндә, закон тарафыннан билгеләнмәгән гамәл кылдым – хәзер мин моны аңлыйм инде. Рим папасына хат язарга, аны РФ Тышкы эшләр министрлыгы системасы аша җибәрергә тиеш булганмын. Тышкы эшләр министрлыгы аны нунцийга – Рим папасының даими дипломатик вәкиленә бирер, тегесе илчелеккә җибәрер, һәм бу бюрократия без иконаны кире кайтара алмасын өчен барысын да эшләр иде. Ә мин беркатлылыгым белән турыдан-туры Рим папасына хат яздым – дәүләт институтларыннан башка гына мөрәҗәгать иттем. Һәм ул турыдан-туры җавап җибәрде: «Аудиенциягә килегез, үзегез белән тагын биш кеше ала аласыз». «Миңа иптәшкә берәрсен бирегез әле», – дип, мин Минтимер Шәрип улы Шәймиев янына бардым. Ул үзенең киңәшчесе Рафаэль Хәкимовны, бу мәсьәлә белән башкалардан күбрәк шөгыльләнгән Людмила Андрееваны алырга киңәш итте... Һәм без Ватиканга киттек. Анда без Рим папасы Иоанн Павел II белән сөйләштек. «Син миннән нәрсә телисең? Бу икона - минем өчен иң кадерле әйбер, ул мине һөҗүмнән коткарды, ул миңа булыша. Бу икона йортым янындагы чиркәүдә тора, аның каршында көненә өч тапкыр гыйбадәт кылам. Кабинетымда аның күчермәсе бар, машинамда да - аның күчермәсе, син нәрсә телисең?» – дип сорады. Мин ул вакытта бернәрсәгә дә, беркемгә дә ышанмый идем, тик менә шунысы кызык: Казанга иконаны кайтарганнан соң, Рим папасы озак яшәмәде бит...

Мин аны ышандыра алдым. Ходай Тәгалә булышкандыр инде. «Изге Атакай, сез мине чакырдыгыз – мин килдем. Аңлавымча, изге кешенең бурычы – кешеләргә файда китерсен өчен, изге әйберләрне кире үз урынына кайтару бит ул», – дидем. Янәсе, син изге булырга телисең бит, димәк, безнең иконаны кире кайтарырга тиешсең.

Әлегә кадәр икона чын дип уйлыйм. Карагыз әле, ул ничек елый, кешеләргә күпме файда китерә! Аңа никадәр бүләк алып киләләр, аның янына күпме дин тотучы агыла! Мин, әлбәттә, иконаның чынмы-юкмы икәнлеген тикше-

* Уфа метрополитенын төзү 2011 елда шәһәр мэры карары белән туктатыла. Метрополитен проектын шәһәр электричкасы һәм тизйөрешле трамвай алыштыра.

рергә җыенмыйм. Хәтта күчермә булса да, бүген бу икона – иң күп гыйбадәт кылынганы, иң күп дога укылганыдыр.

Нәтиҗәдә, без иконаны Казанга кайтардык, ә монда үз таләпләре белән мөселманнар көтә! Казан университетының сирәк китаплар бүлегендә без революциягә кадәр, 1903 елда, Казанда дөнья күргән беренче басма Коръәнне таптык, Төркиядә репринт басмасын нәшер иттек һәм шәһәрнең 1000 еллыгына халыкка тараттык.

Бу вакытта дини күтәрелеш башланды: дәүләт чиркәү, мәчет, синагогаларны халыкка кире кайтарды. «Бу чиркәүне безгә кайтарып бир!» Ә анда склад яки тагын берәр нәрсә урнашкан. Бушатабыз: «Рәхим итегез!» Алар артыннан ук мәчеттән бер төркем кеше килә: «Ник аларга бирдең, ә безгә бирмисең!» – диләр. Шул рәвешле мин толерант карарлар кабул итәргә өйрәндем.

ТОРМЫШТАГЫ ИҢ АВЫР СЫНАУ

БЕРВАКЫТ Камил Исхаков Ерак Көнчыгышка китә. Аның әйтүенчә, бу аның тормышындагы иң авыр сынау була...

– Миңа Казаннан китү бик авыр булды. Мин 57 ел Казанда яшәдем бит: биредә тудым, укыдым, эшләдем... Шулкадәр гомер юлын узгач, каядыр кузгалу, күченеп китү бик кыен. Өстәвенә, Ерак Көнчыгышка – мине Россия Федерациясе Президентының Ерак Көнчыгыш федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле итеп билгеләделәр. Шуңа күрә анда авыр йөрәк белән киттем. Ә инде бераз вакыт эшләгәч, хатыныма шалтыратам:

– Матурым, монда шундый рәхәт, бирегә җибәрүе өчен мин Владимир Владимировичка бик рәхмәтлемен, – дим.

Анда чыннан да искиткеч. Табигый байлыклар, балык күп... Без, россиялеләр, кызганыч ки, бәяләр көйләнмәгәнгә, балык кайтару субсидияләнмәгәнгә күрә, моны белмибез дә, күрмибез дә. Ясалма сулыкларда үстерелгән, читтән китерелгән балык ашыйбыз. Тик ул Тын океаннан тотылган балык белән чагыштырырлык та түгел!

МӘШРИКЪ-МӘГЪРИБ

БЕРВАКЫТ Камил Шамил улы Россия һәм ислам дөньясы арасын якынайтучы була.

– 2008 елдан 2011 елга кадәр мин Согуд Гарәбстанының Җиддә шәһәрендә Ислам Конференциясе Оешмасы каршында Россия Федерациясенең беренче даими вәкиле булдым. Ислам Конференциясе 61 дәүләтне берләштерә: 57 әгъза һәм 4 күзәтүче. Россия анда бары тик Владимир Путин ярдәмендә генә эләкте, ул, дөнья масштабында бик дөрес сәясәт алып барып, мәсьәләнең бу ягын да кайгыртырга онытмады. Үз вакытында Малайзиядә узган дәүләт башлыклары саммитында Владимир Владимирович, Россиядә 20 миллион мөселман яши һәм алар – безнең җирле халык, шуңа күрә безнең исламга турыдан-туры мөнәсәбәтебез бар, диде. Ул шулчакта үзенең чыгышы белән бөтен ислам дөньясын кузгатты, һәм безне күзәтүче сыйфатында кабул иттеләр. Тулы вәкаләтле вәкил итеп мин сайландым. Чөнки 2005 елда, мин Ерак Көнчыгышка тулы вәкаләтле вәкил итеп җибәрелгәч, Ислам Конференциясе Оешмасы Мәккәдә дәүләт башлыкларының гадәттән тыш саммитын игълан итте. Путин да чакырылган иде. Әмма Мәккәгә мөселман булмаган кеше керә алмый, ә мөселман Исхаковны рәхәтләнеп җибәреп була. Шул рәвешле мин беренче тапкыр зур ислам дөньясына эләктем. Һәм Россия Федерациясе делегациясен җитәкләдем.

ИСЛАМ АКАДЕМИЯСЕ ТУРЫНДА

БЕРВАКЫТ Камил Исхаков Болгар ислам академиясе президенты һәм әлеге уку йортын гамәлгә куючылар советы рәисе була. Аңа абруйлы мөгаллимнәрне төрле илләрдән Татарстанга эшкә чакырып китерергә һәм студентларга сыйфатлы белем бирүне оештырырга туры килә. Һәм болар барысы да илдә йөз елга якын атеизм хөкем сөргәннән соң...

– Укытучылар составын формалаштыру – катлаулы процесс. Халыкара дәрәҗәдә диярлек. Без бит үзебезнең динсезлек елларында бөтен кадрларыбыздан да диярлек колак кактык. Галимнәр юк, белемле укытучылар юк... Шуңа күрә без шәкертләргә сыйфатлы белем бирү өчен чит ил белгечләрен чакырырга мәҗбүр булдык. Мин Рөстәм Нургали улы һәм Минтимер Шәрип улының миңа күрсәткән ышанычларын һәрвакыт акларга тырыштым. Безгә киләчәктә Россиянең иминлеген тәэмин итәчәк уку йорты булдырырга кирәк иде. Чөнки чит илләргә укырга китәргә мәҗбүр булган яшьләребезгә аларның махсус хезмәтләре йогынтысы зур. Шунлыктан безнең балалар сыйфатлы белемне читтән эзләмәскә, ә үзебездә алырга тиеш.

Безнең төп эшебез – яхшы белгечләр әзерләү, борынгы бабаларыбыз кебек фәнни эш алып бару. Чөнки нәкъ менә Болгарда 1080 елда Дарелбелем университеты – белем йорты оештырыла. Анда гыйльми кадрлар тәрбияләнә, 30 меңнән артык фәнни хезмәт чыгарыла, алардан бүгенге ислам дөньясында да теләгән һәркем файдалана ала.

Илебездә йөз елга якын атеизм хөкем сөргәннән соң укыта башладык. Бөтен ислам университетына мондый старт хас түгел. Шунысы белән кызыграк та әле ул.

ИСХАКОВНЫҢ ХЫЯЛЫ

БЕРВАКЫТ Камил Шамил улы үзенең хыяллары белән уртаклашты...

– Минем казанлыларны интеллектуаль яктан алга киткән итеп күрәсем килә. Югыйсә без күбрәк куллану өлкәсенә китәбез, берни белән дә кызыксынмыйбыз. Бездә хәзер интеллект «алыпсатарлык» дәрәҗәсендә генә. Кибетләр, төрле хезмәт күрсәтү өлкәләре бик күп... Кешеләр дә шунда эшләргә мәҗбүр, тагын кая барсын алар? Һәм, шуңа бәйле рәвештә, элек биредә булган интеллект хәзер юк инде. Аңлыйсызмы? Хыялым белән уртаклашуга килсәк, мин шәһәребездәге шул интеллектны кайтарырга хыялланам.



Студент Ринат Мөхәммәдиев.



Танылган язучы, җәмәгать эшлеклесе Ринат Мөхәммәдиев.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

Руфия Фазылова

Казан дәүләт университетын тәмамлап, югары дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр арасында Ринат Мөхәммәдиев тә бар. Танылган язучы бүген дә Кремль урамына (элеккеге Ленин урамы) килеп чыкса, Владимир Ульянов һәйкәле янәшәсендәге «сковородка»га утырып уйга кала. Яшьлек еллары, күпме остазлар, дуслар... Аның өчен барысы да бик кадерле һәм газиз.

«АБРУЙНЫ АКЛАРГА ТЫРЫШТЫМ...»

БЕРВАКЫТ, төгәлрәге 1966 елның җәендә, Казанга килә ул. Гади авыл малае: сәләмә генә өс-баш, аптыраулы караш, тик ничек тә хыял-максатын тормышка ашырасы килә аның.

– Төн буе черем дә итми пароход палубасында аягүрә басып килдем, – дип, башкалага беренче сәяхәтен искә ала Ринат Мөхәммәдиев. – Елга портыннан Ленин урамына да барып җитәсе бар бит әле. Кешедән сораштыра торган гадәт юк. Йөрәк ашкына... Таныш булмаган урамнарда адашып йөри торгач, урамын да таптым. Кыяр-кыймас кына университетка якынлашам – ап-ак бина, биек колонналар... Тукталып калдым, үрелеп-үрелеп, берөзлексез колонналарга карыйм. Шунда көяз генә бер кыз: «Егет, авызыңны ул кадәр ачма, монда күгәрченнәр бик күп...», – дип, хихылдап көлмәсенме.

Ишекләр ачык ачыгын да, әмма икеләнә калдым, бу ишекләр минем өчен микән... Эчкә узарга кыймый тордым. Шулчак күзем каршы якка төште, анданиндидер һәйкәл. Ленин дисәң, бер дә охшамаган, сакал-мыегы да юк. Яшь бер егет басып тора... Әйләнә-тирәсендә – чәчәкләр. Утырыр өчен урыннары да күп икән. Миңа шул гына кирәк: ике дә уйламый, урам аша чыктым. Университетына әллә кереп була, әллә юк, манзара кылып, рәхәтләнеп бер утырыйм ичмаса. Читтәрәк бер буш урын табып, шунда барып кунакладым...

Фотолар Ринат Мөхәммәдиевнең шәхси архивыннан

Шул мизгелдә чиксез бәхетле идем. Хакыйкатьтә, җилкәмдәге ике канатны миңа, фәрештәләр түгел, Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты иңдерде.

ОНЫТЫЛМАС ИСЕМНӘР...

БЕРВАКЫТ, төгәлрәге 1966 елда, Ринат Мөхәммәдиев КДУның тарих һәм филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты булуга ирешә.

– 1966–1971 елларда укыдым университетта. Ул дәверне онкыту мөмкин түгел! – ди язучы. – Профессор Хатыйп Госман лекцияләрен тыңлаган чаклар... Аның, башын артка чөя төшеп, Һади Такташ һәм Сәгыйть Рәмиев шигырьләрен яттан сөйләгәнен оныту мөмкинме соң? Менә профессор Ибраһим Нуруллин, тамак төбен кыра-кыра, Тукай иҗаты серләрен аңлата. Ул да түгел, Мостафа Ногман үзе иҗат иткән өр-яңа бер җырын җырлап җибәрә... КПСС тарихыннан лекция укыган җирдән бүленеп, татар халкының легендар уллары һәм кызлары турында онытылып сөйләргә керешкән Рәфик Нәфиковны да хәтердән сызып ташлап булмый. Бу галимнәр һәммәсе дә утны-суны кичкән Бөек Ватан сугышы ветераннары да иде бит.

Ә инде Мөхәммәт Мәһдиев бөтенләй башка, ул үзе бер дөнья иде безнең өчен. Лекция укымый, гүя мавыктыргыч бер хикәят сөйли, язылачак романнарының өр-яңа сәхифәләрен бәян итә кебек иде. Аны тыңлап туйган студентны мин хәтерләмим. Ә кызлар дәррәү гашыйк була торган иде...

Университетның тагын бер маягы сыман кабул ителгән Луиза Кәрим кызы Бәйрәмованы да искә төшерми үтә алмыйм. Рус теле белгече иде ул. Безнең ише авыл җирендә туып-үскән татар балаларын үз фәнен яраттыру өчен нинди олы талантка ия булды.

АСПИРАНТУРАГА ЮЛ

БЕРВАКЫТ кулына әле яңа гына диплом алган Ринатны аспирантурага керергә кыстыйлар. Ул карыша...

– Бик мавыгып һәм яратып, Казан телевидениесендә эшләп йөргән көннәрем, – дип дәвам итте Ринат Сафиевич. – Университетыбызның журналистика кафедрасы мөдире Флорид Әхмәт улы Әгъзәмов мине үзенә чакырып алды. Янында легендар Гази ага Кәшшаф утыра, аспирантурага керергә тәкъдим ясадылар. Телевидение җитәкчелеге, җибәрмибез, диде, гаиләм дә каршы... Барыбер ризалаштым. Өч ел дәвамына университет китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә утырдым... Диссертацияне Мәскәү дәүләт университетында якларга туры килде. Шул елларда минем өчен Мансур Хәсәнов һәм Флорид Әгъзәмовлар чын остаз һәм игелекле киңәшчегә әверелде. Урыннары җәннәттә булсын, һич онытасым юк...

Искиткеч гыйлемле һәм кешелекле галимнәрдән аң-белем алдым, тугрылыклы чын дуслар таптым. Илебезнең кайсы гына шәһәренә, дөньяның кайсы гына төбәгенә барып чыксам да, мин үземне һәрчак Казан университеты шәкерте итеп хис иттем. Россиянең дәүләт яисә парламент делегацияләре вәкиле һәм язучы буларак, кайда гына чыгыш ясарга туры килмәсен, һәрчак Казан университетының мәртәбәле абруен акларга тырыштым.

БОРИС ЕЛЬЦИН МАМАДЫШТА КУНАКТА

БЕРВАКЫТ Ринат Мөхәммәдиев Россиянең беренче Президенты Борис Николаевич Ельцинны туган ягы – Мамадыш районына алып кайта...

– 1990 нчы еллар башында төрле югары вазыйфаларга кандидат булдым. Гәрчә ул инициатива миннән беркайчан чыкмаса да, – дип истәлекләре белән бүлеште дөнья гизгән язучы. – Бәхеткәме икән, ул югары кәнәфиләргә утыру насыйп булмады. Байтак ыгы-зыгылардан халкым биргән сабырлык һәм Аллаһ үзе саклады кебек.

Борис Николаевич белән берничә тапкыр эшлекле сәфәрдә булырга туры килде. Тарихка кереп калган бу шәхес белән бәйле кызыклы истәлекләр бик күп. Аның башта – Мамадышка, аннан Казанга сәфәрен мин оештырдым. Борис Николаевич ул чагында Россия Югары Советы Рәисе иде. Россиягә яңа сулыш кирәк, дип, трибуналардан кычкырган әлеге сәясәтчегә ул чакта бик зур өметләр багладылар.

1990 елның июль башында Борис Ельцинның ярдәмчесе Виктор Илюшин миңа мөрәҗәгать итеп: «Борис Николаевич якын араларда Татарстанга барырга җыена. Шул сәяхәтнең маршрутын хәстәрләшсәң иде. Очрашу оригиналь булырга тиеш», – диде. Әнә шулай итеп Борис Николаевичка үземнең туган як – Мамадыш районын күрсәтергә булдым. Зур кунакны Түбән Сөн авылына алып бардык. Әлбәттә, аңа монда игътибар зур булды: Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Минтимер Шәймиев, Борис Ельцин белән вертолетка утырып, сәяхәттә үзе озатып йөрде. Ә Мамадыш районының ул чактагы беренче секретаре Фатыйх Сибгатуллин зур кунакларны каршы алды. Түбән Сөн авылында, Ельцинны күрергә дип, урамга бөтен авыл чыккан иде. Мәскәүдән килгән кунак, машинадан чыгып, авыл апалары, агайлары белән кул биреп күреште. Аннан чып-чын татар гаиләсенә төшке ашка юнәлдек. Токмачлы аш, бәлеш – барысы да үзебезчә иде. Киткәндә авыл халкы Ельцинны шулай ук аягүрә басып озатып та калды.

Зур кунак белән Мамадыштан туры Казанга юл тоттык. Язучыларның Тукай исемендәге клубы да шыгрым тулы иде. Идәндә генә түгел, тәрәзә төпләрендә дә урын юк. Журналистлар да бихисап. Мәскәү кунагына сорау артыннан сорау яуды залдан. Тарихта калган очрашу булды ул.

Беренче май бәйрәмендә. 1970 ел.

Эдуард Трескин хатыны һәм кызы белән консерваториядә.

ЭДУАРД ТРЕСКИН

Евгения Чеснокова

Кайсын сайларга – физик дипломынмы, опера сәхнәсенме? Казан университеты бик күп талантлы яшьләргә фатыйха бирә. Университетта старт алган сәләт бөтенләй көтелмәгән рәвештә үсеп китәргә дә мөмкин.

ФИЗФАК «МЕФИСТОФЕЛЕ»

КДУның актлар залында концерт бара. Физфакның 18 яшьлек студенты Эдик Трескин Гуноның «Фауст» операсыннан Мефистофель куплетларын һәм Чайковскийның «Иоланта»сыннан Роберт ариясен башкара. Гомумән алганда, физик булу һәм, бәлки, космоска да очу теләге бик җитди аның. Әмма университет башка бик күп мөмкинлекләр дә бирә. Әгәр синдә күзгә бәрелеп торган иҗади сәләт бар икән, үзешчән сәнгать осталары арасына рәхим ит! Кайвакыт син моңардан реаль дивидендлар да ала аласың.

– Безнең Виссарион Федорович Семенов исемле укытучыбыз бар иде, политэкономияне алып барды, шаян кеше иде, – дип искә ала Эдуард Германович. – Янына имтиханга киләм, ә ул миңа: «Соңгы фестивальдә бик яхшы җырладыгыз! Ә киләсендә нәрсә башкарырга ниятлисез?» – ди. – «Фигаро каватинасын», – дим аңа. – «О, минем яраткан ариям! Зачёткагызны бирегез...»

Университетның вокал түгәрәгендә студентның гаҗәеп тавышын Нәҗип Җиһановның кызы – вокал укытучысы Светлана Җиһанова ишетеп ала. Аңа консерваториягә барырга киңәш итә. 1967 елда Эдуард Трескинны консерваториянең икенче курсына кабул итәләр. Ул берничә ел ике югары уку йортында белем ала.

МАТУР ДУСЛЫК ТАРИХЫ

1969 елның 1 мае. Студент Трескин Беренче май демонстрациясе сафларында атлый. Кинәт янәшәдә генә ниндидер ыгы-зыгыга игътибар итә. Баксаң, алар арасында шагыйрь Евгений Евтушенко да бар икән! Казанга килгән чагы! Әлбәттә, күпләр шагыйрьдән автограф сорый. Кыюлыгын җыеп, Эдуард та сүз ката: «Сезгә хатынымның шигырьләрен укытып карар идем. Мөмкинме?» – «Иртәгә кич «Волга» кунакханәсенә килегез».

Фотолар Эдуард Трескинның шәхси архивыннан

Тарих факультеты студенты, яшь шагыйрә Галина Свинцованың шигырьләр дәфтәрен тотып, ул кунакханәгә бара. Ә Евтушенко, бераздан шалтыратып, шигырьләрнең бик кызыклы булуын, аларга кунакка килергә теләвен әйтә. Шагыйрь ул вакытта Казан университеты турында поэма яза, мөгаен, замана студентларының ни белән янып яшәвен дә аңларга омтылгандыр.

– Евтушенко иртә белән килде һәм төн җиткәндә генә чыгып китте, – дип искә ала Трескин. – Бу искитеч очрашу булды. Ул безгә шигырьләрен укыды. Ә мин аңа Тютчевның «Мин сезне очраттым» шигыренә язылган романсны җырладым. Күзләреннән яшь бәреп чыкты...

Аларның ярты гасырга якын дәвам иткән дуслыгы әнә шулай башлана. Язмыш аларны бергә еш очраштыра – әле Казанда, әле Мәскәүдә, әле Прагада.

– Соңгы тапкыр Евгений Александрович белән 2015 елда, ул Камал театрында чыгыш ясаганда күрештек, – ди Эдуард Трескин. – Ә ике елдан соң, ышанасызмы-юкмы, минем туган көнем – 1 апрельдә вафат булды...

УНИВЕРСИТЕТ КЕШЕЛӘРЕ

1979 елның 17 ноябрендә Казан университетына 175 ел тула. Бу көнне Эдуард Трескинның кызы Полина туа. Очраклылыкмы? Сөекле хатынын да аңа университет бүләк иткән бит.

Университетта алар бик күп яхшы дуслар таба. Үзешчән сәнгатьтә Трескин белән бергә студент-физик, хәзер исә танылган актёр һәм режиссёр Борис Львович чыгыш ясый; физика фәннәре кандидаты Альберт Таюрский (КФУның хәзерге проректоры Дмитрий Таюрскийның әтисе) рояльдә бик яхшы уйный. Киләчәктә Мәскәү Әдәбият институты ректоры һәм Россия мәдәният министры булачак Владимир Егоров Галина Свинцова белән бергә укый. Сатирик Борис Бронштейн, сәясәтче Олег Морозов, университет музееның легендар директоры Стелла Писарева, «Ленинец» газетасы мөхәррире Татьяна Николаева һәм аның ире, академик Игорь Тарчевский, профессор Борис Лаптев... Бу кешеләрнең барысы да Казан университеты тудырган зыялылык, хөрлек, дуслык атмосферасыннан чыккан. Бу аралашу гаҗәеп туганлык хисен сеңдереп калдыра!

ПРЕЗИДЕНТТАН СӘЛАМ

2007 елның 16 декабрендә Эдуард Трескинның Прагадагы фатирында телефон шалтырый. «Авыр булмаса, пани Свинцованы мөмкинме?» Галина трубканы ала. «Сезгә Чехия Президенты канцеляриясеннән шалтыраталар...»

...1992 елда Трескинны Прага дәүләт операсына солист итеп чакыралар. Чехиядә алар 18 ел яши.

Президент Вацлав Клаус белән Эдуард Трескин Россия илчелегендә таныша. 9 майга кичәләр оештырыла, аларга Клаус та килгәли. Трескин бу кичәләрдә чыгыш ясый. Бервакыт ул Чехия лидерына Галинаның «Свидание с Прагой» дип аталган шигырьләр китабын бүләк итә. Ә Галина Россия мәдәни үзәгендә юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнгәндә, бер чех дусты: «Ә сез пан президентны да чакырыгыз! Аның өчен канцеляриягә чакыру илтегез!» – дип тәкъдим итә. Һәм бәйрәм көнендә Галинага шалтыратып болай диләр:

«Президент Сезне юбилей белән котлый һәм, хәзер чит илдә булу сәбәпле, кичәдә шәхсән катнаша алмаганы өчен гафу үтенә. Югыйсә, ул һичшиксез килер иде, чөнки китабыгыз аның шәхси китапханәсендә саклана...»

ЕРАК-ЕРАК КӨНЬЯКТА...

Бервакыт гыйнварда Эдуард Трескин Бразилиянең Антарктидадагы станциясендә концерт куя. Күпмедер вакыт ул океаннар гизә торган круиз лайнерында «килеп-китеп йөрүче артист» сыйфатында эшләп ала.

– Шул рәвешле мин 95 илне йөреп чыктым, – дип сөйли Эдуард Германович. – Шпицбергенда да, Антарктидада да булдым. Димәк, мин Җир шарының барлык кыйтгаларында да җырладым булып чыга.

ЯШӘҮ КӨЧЕ БИРГӘН УРЫНЫ

2021 елның ноябре. Үзенең яраткан Казан опера театры сәхнәсендә Эдуард Трескин Вердиның «Травиата»сыннан Жермон партиясен җырлый. Аңа 75 яшь, әмма җырлау сәләте тамашачыларны һаман да сокландыра.

– Бервакыт миңа тавышымның илаһи бүләк булуын әйттеләр. Мөгаен, чыннан да, Аллаһы Тәгалә үзе миңа вокалда озын гомер биргәндер, – дип елмая Эдуард Германович. – Ләкин шуны әйтәсем килә: мин техниканы яхшыртуны гомерем буе туктатмыйм, моңа Казанда гына түгел, Бөекбританиядә дә, Италиядә дә укыдым...

Хәзер Мәскәүдә инде аның үз шәкертләре дә бик күп. Шунысы кызык: алар арасында танылган совет теноры Иван Козловский оныгының кызы да бар.

Эдуард Германович китаплар да яза. Үзен язучы дип атаудан куркуын яшерми ул, әмма уңышлары күз алдында – былтыр Рус ПЕН-үзәгенең Фазыл Искәндәр исемендәге халыкара премиясен алган.

– Барлык иҗади омтылышларым университетта алган импульска бәйле, дип саныйм, – ди каһарманыбыз. – Кайда гына булсам да, Казан – университет – опера театры минем өчен һәрвакыт тормышымның төп өчпочмагы булып кала. Яшәү көчен мин шулардан алам.

Хатыйп Миңнегулов 1960 нчы еллар башында.

Филология фәннәре докторы, профессор Хатыйп Миңнегулов.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВ

Руфия Фазылова

Хатыйп Миңнегуловның 60 елдан артык гомере Казан дәүләт университеты белән бәйле. Студент еллары, аспирантура, мөгаллимлек чоры...

Филология фәннәре докторы, профессор, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе... Бу исемлекле тагын дәвам итәргә мөмкин.

Хөрмәтле мөгаллимгә бүген 85 яшь. Редакциябезгә егетләрчә җиңел атлап килеп керде ул. Шөкер, татарның аксакалы, хөрмәтле галим һаман да сафта!

«БҮРЕЛӘР ДӘ КЫЗГАНА ИКӘН»

БЕРВАКЫТ үсмер Хатыйп туган авылыннан егерме биш чакрым ераклыкта урнашкан Сарман районы Иске Кәшер мәктәбенә укырга китә.

– Укырга кечкенәдән яраттым. Җиде класс белем белән генә каласым килмәде, – ди Хатыйп ага. – Әни дә каршы килмәде. Ара ерак булса да, туган авылым Апачка атна саен кайтып йөрдем. Тугызынчы сыйныфта укыган чак. Көз. Аякта чабата, аркада капчык. Йөгерә-йөгерә алга барам. Караңгы төшеп килә. Бер урманны узып, икенчесенең кырыена җиттем. Кызу-кызу барам шулай. Карасам, уңда бүре утырып тора. Таза, йоннары елык-елык килеп тора. Шулвакыт арттарак чыбык сынган тавыш ишетелде. Борылып карасам, тагын бүре. Нишләргә? Өнсез калдым. Әнкәй, әби өйрәткән, үзем белгән догаларымны укый башладым. Йөгереп качып та булмый. Бүреләрнең гаять тиз йөгерүен һәркем белә. Миңа карап утырышып торалар. Менә каршыдарак кына торган бүре янәшәсеннән дә узып киттем. Адымнарны тизләттем. Бераздан йөгерә башладым. Борылып караган идем, ике бүре дә урманга кереп китте.

Рәхмәт үзләренә: миңа тимәделәр. Бәлкем, бу арык, ябык малайны ашаудан ни файда дип уйлаганнардыр. Шактый калын урманны караңгыда бик тиз йөгереп уздым. Тауларны төшкәч – туган авыл. Өйдәгеләр көтеп торган. Әнкәй кайнар бәрәңгеләрне алга куйды. Катык белән тәмләп ашадым. Шунда әнкәй, нидер сизенгәндәй: «Нәрсә булды сиңа, улым?» – дип сорады. Мин сер бирмәдем. Бүреләр белән очрашуны сөйләсәм, мәктәпкә кабат укырга җибәрмәс, дип курыктым.

Фотолар Хатыйп Миңнегуловның шәхси архивыннан, Александр Ефремов.

ҮЗБӘКЧӘ ПЫЛАУ

БЕРВАКЫТ Казан дәүләт университетының беренче тулай торагында күпләр чын үзбәкчә пылау пешерә башлый.

– Тулай торак бер гаилә кебек, – ди Хатыйп Йосыфович. – Аның көндәлек тормышында бик күпләр белән аралашасың. Алар исә ул вакытта да, аннан соң да төрле урыннарда эшли. Бер-береңне танып аласың, үзара ярдәм итәргә тырышасың.

Безнең тулай торак төрле өлкә-республикалардан килгән стажёрларның да тору урыны булды. 60 нчы елларның ахырында университетка стажировкага килгән Бегали Косимов та безнең арада 3-4 ай яшәде. Ул пылау пешерү остасы булып танылды. Аның пылау исе бөтен коридорга тарала иде. Озак та үтмәде, шул рецепт белән тулай торакта пылау пешерү модага керде.

Бегали әфәнде – үзбәк, Шәрык әдәбиятының олуг белгече. Татар-үзбәк әдәби бәйләнешләрен да махсус өйрәнгән зат. Без аның белән дуслашып киттек, хезмәттәшлек итә башладык. Ташкентка барган чакларымда ул минем төп таянычым булды. 1991 елның ноябрендә докторлык диссертациямне рәсми бәяләүче дә ул иде. Ни кызганыч, галим дустым шактый яшь көенчә мәрхүм булды.

ДӨНЬЯНЫ МАТУРЛЫК КОТКАРА...

БЕРВАКЫТ мөгаллим Хатыйп Йосыфович студентлары белән Ереванга сәяхәткә китә. Ул чор өчен мондый хәлләр гадәти була.

– 1976 ел. Бер төркем студент белән шәһәрдә йөрибез, – дип дәвам итте мөгаллим. – Максат – студентларны төрле халыкларның мәдәниятләре белән таныштыру, аннан бигрәк җирле музейларны күрү. Безнең белән Харрас Әюпов та бар. Иң беренче шуны әйтим: кая барсам да, сөйләшүне югарыдан башлый идем. Әгәр ул район икән, димәк, районның беренче секретаре янына керәсең. Ә инде Ереванда университетның ректорына мөрәҗәгать иттем. Безне алдан ук кисәтеп куйдылар: «Мәскәү университеты ректоры килә, сезнең биш минут вакытыгыз бар». Минем дә бер гадәтем бар иде: җитәкче янына кергәндә, һәрвакыт үзем белән берәр чибәр кызны ияртәм. Бу юлы да шулай эшләдем. Гадәттә, чибәр хатын-кыз булганда, ир-ат гозерне кире какмый. Психология бу. Берзаман ректор чәй дә чыгартты, ачылып сөйләшеп киттек. Биш минут дигәнебез кырык минуттан артты. МДУ ректоры безнең чыкканны кабул итү бүлмәсендә көтеп утырган. Сөйләшүнең нәтиҗәсе шул булды: Ереванга өч көнгә дип килгән идек, биш көн тордык. Студентлар тулай торагыннан бушка бүлмә дә булды, ашау-эчү, экскурсия мәсьәләләре дә хәл ителде. Юкка гына дөньяны матурлык коткара, димиләр бит.

СУГЫМЧЫ?

БЕРВАКЫТ, фольклор экспедициягә баргач, Хатыйп Миңнегуловка сарык суярга туры килә...

– Еш кына университет укытучысының эшчәнлеген аудиторияләрдә лекцияләр сөйләү, семинарлар уздыру, курс һәм диплом эшләрен яздыру, имтихан-зачётлар алу рәвешендәрәк күзаллыйлар. Ләкин бу алай гына түгел. Университетта уку дәверендә миңа ике тапкыр экспедициядә булырга туры килде. Ә инде университетта эшли башлагач, студентлар белән күп еллар дәвамында фольклор экспедицияләренә чыктык. Кайларда гына булмадык: Татарстан, Свердловск, Ульяновск, Нижгар, Оренбург, Чувашстан, Башкортстан һәм башка төбәкләр.

Берсендә Пермьнән ерак булмаган Каян исемле бер авылда 3-4 көн яшәдек. Олы кунак итеп тоттылар безне. Нindидер дини бәйрәм вакыты иде. Хуҗа хатынның ире эш белән каядыр киткән чагы туры килде. Сарык суярга ир-ат таба алмыйлар. Кешегә ялынып йөрүне өнәмәгән энкәйнең гозере буенча (эти сугышта үлгән) мин бу һөнәргә яшьтән үк өйрәнгән идем. Хуҗабикә ризалыгы белән сарыкны чалып, сугымны җиренә җиткереп эшкәртеп бирдем. Бу хәбәр авылга тиз арада таралды. Шунда мине тегесе дә, бусы да мал суярга чакыра башлады. Безнең студентлар ул чагында иткә рәхәтләнде...

ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ БҮЛЕГЕ

БЕРВАКЫТ, төгәлрәге 1944 елда, Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. 1979 елга кадәр ул - тарих-филология, аннан филология факультеты составында була. 1989 елда, илдә барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә, татар бүлеге нигезендә татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультеты ачыла.

– Казанда Мәскәүдәге кебек әдәбият институты юк, – ди Хатыйп Йосыфович. – Шуңа күрә иҗади яшьләрне тәрбияләү, үстерү вазыйфасын күпмедер дәрәҗәдә Казан университеты башкарып килде. Хәзер дә шулай ул. Соңгы ярты гасырда әдәбиятка килгән язучыларның дүрттән өч өлеше, мөгаен, татар бүлеге шәкертләредер.

Сиксән ел яшәү дәверендә татар бүлеге берничә мең белгеч әзерләп чыгарды. Аларның төп өлеше мәктәпләрдә эшләп, халкыбызның милли үзаңын тәрбияләүгә зур өлеш кертте. Татар филологиясе һәм тарихы факультетының көндезге һәм читтән торып уку бүлекләрендә сигез йөз студент укыган чаклар бар иде. Ни кызганыч, бүген бу сан берничә дистә генә. Шулай да бүлекнең якты киләчәгенә мин ихластан ышанам. Милли кадрларны фәкать шундый бүлекләрдә генә әзерләп була.



Профессор Рудольф Буруковскийга 80 яшь .

«АтлантНИРО»дагы хезмәттәшләре белән.

Рудольф Буруковскийның «О чём поют ракушки» китабы.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР
РУДОЛЬФ БУРУКОВСКИЙ

Әскәр Сабиров

Бу дөньяда бер галимне «креветкалар короле» дип йөртәләр – ул аларның дистәләгән яңа төрен ачкан. Бер атаклы кабырчык җыючы сирәк очрый торган 12 000 данә кабырчыктан гыйбарәт коллекциясен МДУның зоология музеена бүләк иткән. Бер каләм иясенең «О чем поют ракушки» дигән гаҗәеп китабы инде ике тапкыр басылган. Әлеге шагыйрь, язучы, коллекционер, моллюскларның яңа төрләрен ачучы – барысы да бер үк кеше – Рудольф Буруковский. Ә Буруковскийның үзен кайчандыр «Казан университетыннан хатлар»ында дөньяга беренче тапкыр журналист Анатолий Аграновский таныта.

«Әгәр типик зоологны тасвирларга туры килсә, мин аны, мөгаен, мөлаем, кызыксынучан, гаҗәпләнә белүче һәм бераз сәеррәк кеше итеп тасвирлар идем. Ул Паганель шикелле озын, бераз тотлыгучан яки сакаурак булыр... Мин аңа сирәгрәк очрый торган исем биреп, моннан дистә еллар элек модадан чыккан шакмаклы ковбойканы кидерер идем дә... башка әйбер турында язмас идем, чөнки мондый кешене сурәтләсәң, булганы бар инде, диячәкләр. Ләкин мин нәкъ шундый кешене Казанда очраттым. Шаккатучан, озын буйлы, карап торышка таркаурак күренгән егетне. Исеме – Рудольф, Рудольф Николаевич Буруковский. Ул биология-туфрак факультетының өченче курс студенты...» Героебызны «Известия»нең махсус хәбәрчесе әнә шундый итеп сурәтләгән. Белеп әйткән диярсең: егетне зур киләчәк көтә...

«КРЕВЕТКА – ЗАКОНЛЫ ХАТЫНЫМ»

1961 ел. Дүртенче курс студенты – китап сөюче, шагыйрь һәм хыялый зат, типик «ботан» Рудольф Буруковский практикага китә. Кысан кубрик, диңгез дулкыннарында көчле чайкалу һәм авыр кием аша да салкыны белән өтеп ала торган су тамчылары... Практика балык тоту траулерында уза. Бу диңгездә сәяхәт итеп йөрү генә түгел – төньякта креветка промыселы экспедициясе! Нинди поэзия булсын монда?! Хәер, кемгә ничек инде. Кайдадыр Шпицберген тирәсендә Рудольфның җитәкчесе – профессор Вагин тралга эләккән җан ияләрен бик бирелеп тикшерә. Караңгы диңгез астыннан чыгарылган креветкаларның идеаль төзелешенә соклана һәм, аларны «коллега»сына күрсәтеп: «Рудик, болар – синеке!» – дип куя.

«Менә шулар мине гомерлеккә «элэктереп» алды да инде», – дип искә ала ярты гасыр узгач профессор Буруковский. Ни өчен нәкъ менә креветкалар? «Ә ни өчен без менә шушы хатынны яратабыз, ә башкасын түгел? Әйтә аласыңмы? – дип сорауга сорау белән җавап бирә ул бер журналистка. – Минем өчен креветкалар да шулай ук. Нәкъ менә алар – минем фәнгә мәхәббәтем. Тик аларга карата мин – полигамияле, берне генә аерып сөймим. Мин систематика, экология, туклануны өйрәнү, репродуктив биология кебек күптөрле мәсьәләләр белән кызыксынам. Хәер, тормыштагы кызыксынуларымда да полигамиялемен, чөнки мин – коллекционер да, язучы да, шагыйрь дә. Диннәр тарихы, дөнья мәдәниятендә моллюсклар һәм аларның кабырчыкларының роле һәм тагын кайбер нәрсәләр белән кызыксынам. Гади генә әйткәндә, креветкалар – законлы хатыным, ә башка кызыксынулар – сөяркәләрем».

КОРОЛЬ? ЮК, ТУГРЫ ХЕЗМӘТЧЕ!

– Ә сез үзегезне «креветка короле» дип йөрткәннәрен беләсезме? – дип сорыйлар бервакыт фән докторы, Калининград дәүләт техник университетының кафедра мөдире Буруковскийдан.

– Бу хакта интернетта язганнармы? – дип көлеп җибәрә галим. – Мин, имеш-мимешкә беркайчан да ышанырга ярамый, дип гел әйтеп киләм. Әлбәттә, креветкаларны өйрәнү буенча мин соңгылар рәтендә түгел, ләкин мине король дип тә атап булмый. Тагын да шәбрәк белгечләр бар. Мәсәлән, голландияле Липке Бидраг Хольтхойс, америкалы Феннер Чейс яки француз Ален Кронье. Менә аларның кайсын да «креветкалар короле» дип атарга була. Ә мине – юк.

Үзен бик тыйнак бәяләсә дә, Буруковский креветкаларның 76 яңа төрен, 7 төркемен һәм семьялыкның ике кече тармагын ачкан. Сигез яңа төр Буруковский хөрмәтенә аталган, димәк, «креветкалар короле» таҗы аңа бик килешә. Икенче яктан, тагын кайсы король Африка, Америка яр буйларында, арктик суларда айлар буе океан гизеп, аннары тапкан-кургән нәрсәләрне көн дими, төн дими, лабораториядә өйрәнеп һәм системалаштырып утырыр икән?! Король, диләрме? Дөресрәге, фән галиҗәнапларының тугры хезмәтчесе. Хезмәтенең 90 проценты авыр һәм еш кына пычраграк, ләкин искиткеч кызыклы хезмәт икәненә инанган ул.

Фото: atlant.vniro.ru, kaliningradlib.ru

ПРОФЕССОР ВАГИННЫҢ ЯРАТКАН ШӘКЕРТЕ

Төньяк Атлантикага зур экспедиция Буруковский бишенче курс студенты булганда оештырыла. Ике ай эшләгәннән соң, «Батайск» судносына ремонт таләп ителә, һәм алар Калининградта туктыйлар. Форсаттан файдаланып, профессор Вагин балык хуҗалыгы һәм океанография фәнни-тикшеренү институтына юл тота. Рудольф җитәкчесенә иярә, һәм институт аны шаккатыра. Анда, дип искә ала ул, һәрнәрсә диңгез белән «сугарылган», коридор диварлары буйлап музей экспонатлары урнаштырылган. Шәкерте диңгез хәзинәләрен карап йөргән арада, Владимир Львович җитәкчеләр белән сөйләшә һәм укучысын институтка чын мәгънәсендә... сатып җибәрә: биредә креветкалар буенча белгеч юк икән. Бер елдан соң яшь белгеч Буруковский Көньяк Атлантика лабораториясенә эшкә килә.

Әнә шул рәвешле, шома палубада басып торган килеш кенә, Буруковскийның фәнни киләчәге билгеләнә, ә аннары аңа эш урыны тапкан университет профессоры Владимир Львович Вагин Рудольфның кумирына әйләнә. Шулай булмый хәле юк, «Русанов», «Сибиряков» һәм «Седов» бозваткычларында арктик океанография экспедицияләрендә катнашкан шәхес бит профессор, чын легенда! Диңгез һәм төче су умырткасызларын өйрәнү өлкәсендә абруй казанган зат. Хәер, Вагин да бу егетнең галим булачагын шунда ук күреп ала. «Коры җир»гә күнеккән типик шәһәр кешесе булган Рудик, Ак диңгезгә беренче экспедициядән соң ук, диңгез белән чын-чынлап җенләнә башлый. Тормышта шундый остаз очратканнар бәхетле. Формулалар ятларга мәҗбүр иткән яки ялгышларыңны борыныңа төртеп күрсәткән кеше түгел, ә сиңа бу дөньяда үз урыныңны табарга ярдәм иткән кешеләр турында бара сүз. Профессор Владимир Львович Вагин әнә шундый остаз була.

ТӨЗӘТМӘГӘ ЫШАНЫРГА

Буруковскийның университетка керүе дә тормыш юлындагы зур киртәне узуга тиң була. Дистә еллар узгач, ул бу сынауларның ничек узганын искә ала. Имтиханнар алдыннан әнисе: «Рудик, син яһүд, димәк, бер дүртлегә генә хакың бар», – дип кисәтеп куя. Бу хәл 1957 елда була... Беренче имтихан – физика, җиңел билет эләгә. Егет ике сорауга да тотлыкмыйча җавап бирә, ләкин кинәт аңа өстәмә мәсьәлә чишәргә тәкъдим итәләр. «Ә кагыйдәләр шундыйрак иде: билетка җавап бирсәң, шунда ук «бик яхшы» билгесе аласың. Бераз ялгыштыңмы – мәсьәлә сорап алырга мөмкин...». Ләкин имтихан алучылар белән бәхәсләшеп булмый бит!

Мәктәп программасында узмаган коэффициентларны белү таләп ителсә дә, Рудольф мәсьәләне чишә. «Һәм мин, 17 яшьлек яшүсмергә хас булганча, артыгын уйлап-нитеп тормыйча гына эшләп бирдем, – дип искә ала ул. – Мөһерле битләрне алдым да чишелешне кәгазьгә язып бирдем». «Яхшы, – диде имтихан алучылар, – сиңа тагын бер сорау: «Планетаның теләсә кайсы ноктасында авырлык көченең тизләнешен исәпләп чыгар». Мине батырырга маташуларын аңладым. Урыныма киттем дә биш минутлап аптырашта утырдым. Аннары илһамланып китеп чишеп ташладым! Кәгазьләрне алып барып күрсәттем. Һәм тагын бер өстәмә сорау бирделәр...» Дөрес җавап биргәч: «Яхшы», – дип, дүртле куйдылар».

Дөньяда гаделлек барлыгына ышанычын югалтыпмы, Рудольф шуннан соң бөтенләй әзерләнми башлый. Иртә белән китапханәгә барып, йотлыга-йотлыга Джеймс Олдриджны укый. Китапханә – университетның төп бинасы каршында. Бервакыт шуннан чыгып барганда, аны: «Буруковскиймы?» – дип дәшеп алалар. Бу аны имтиханда батырырга тырышкан укытучыларның берсе була... Үзе артыннан барырга куша һәм егетне гөмбәзле университет коридорлары буйлап алып китә, ниндидер лабораториягә алып керә, имтихан кәгазен сорап ала да анда нәрсәдер сызгалый....

– Анда нәрсә язганнарын күрдеңме соң, ичмасам, – дип сорый әнисе, улы бу хәл турында сөйләп биргәч. Ә ул карамаган икән. Кәгазьдә «яхшы» билгесе сызып ташланган, аның урынына – «отлично» дип язып куелган була. Һәм янәшәдә кыска гына язу: «Ректор рөхсәте белән төзәтмәгә ышанырга...»

ШӘҺӘР «ХРУЩЕВКА»СЫНДА «ҺИНДСТАН ДАНЫ»

Бервакыт Эрмитаж директоры, аның диңгез кабырчыклары турындагы очеркын укып, Рудольф Николаевичның китап өчен материал җыюын белеп алгач, Эрмитаждагы барлык кабырчык фондының фотосурәтләрен (120 фотосурәтне) галимгә бушлай төшереп бирергә куша! Директор галимнең бердәнбер «корбан»ы түгел: Буруковскийның диңгез тирәнлекләрендә яши торган гаҗәеп тереклек ияләре турындагы бәяннарын тыңларга һәм 90 нчы еллар ахыры – 2000 нче еллар башында җыйган меңләгән бик сирәк кабырчыкларын күрергә кешеләр Калининградка хәтта махсус килә торган була.

Илнең әлеге бердәнбер кабырчыклар музее гадәти «хрущёвка»да урнашкан. Буруковский хатыны белән әнә шундый фатирда яши һәм дүшәмбе көннәрендә анда теләге булган һәркем керә ала: экскурсияләрне галим үзе үткәрә. Микроскопик зурлыктагы Урта диңгез кабырчыкларыннан алып Кариб диңгезе төбеннән табылган ярты метрлы гигант кабырчыклар да булган хәзинәләрен күрсәтеп йөргәндә, ул шагыйрьгә әверелә. Борынгы мифлар, риваятьләр, бөек шагыйрьләрнең шигырьләре экскурсия текстына гаҗәеп матур үрелеп бара. Бу фатирдагы бөтен ядкәрләрне тотып карарга була, дулкыннар шавын ишетер өчен, колакка куеп тыңларга да мөмкин: дөньяда бик сирәк

очрый торган «Һиндстан даны»н да, 40 сантиметрлы фантастик пинна нобилесны да (анысын Буруковский Африканың Дакар порты култыгы төбеннән тартып чыгара).

«Җанымның кимендә яртысын мәңгегә кабырчыкларга бирдем», – дип яза бервакыт Буруковский. Ун ел элек үзенең 12 000 нөсхәдән гыйбарәт бөтен коллекциясен галим МДУның Зоология музеена бүләк итә. Рәхмәт йөзеннән җавап итеп бирелгән грамотада кабырчыклар тупланмасының уникальлегенә басым ясала.

ҺАВАЛЫ БРАЗИЛИЯЛЕ РАРИТЕТЫ

Буруковский коллекциясендәге сирәк кабырчыклар арасында «Глориямарис конусы» дип аталганы бар. Кайчандыр бездә андый кабырчык бөтенләй булмаган. Ә беренче экземпляр Рудольф Буруковский тырышлыгы белән эләгә дип әйтергә була. Эш шунда: кабырчык җыю белән шөгыльләнүче хезмәттәшләренең берсе Бразилиягә командировкага бара һәм җирле коллекционер белән таныша. Сүз уңаеннан, ул коллекционердагы раритетлар арасында берничә (!) данә «Глориямарис конусы» да була. Әңгәмә барышында Бразилия конхиломаны үзенең өстенлегенә басым ясый, янәсе, аныңча, безнекеләрнең коллекцияләре һәм белемнәре чүп кенә. Аннары сүз конхиологик әдәбиятка күчә һәм раритетлар хуҗасы үз-үзеннән канәгать кыяфәттә: «Әгәр сезнең илдә кабырчыклар турында бер китап булса да бар икән, мин сезгә үземнең теләсә кайсы «Конусымны» сайлап алырга рөхсәт итәм!» – ди. Һәм шул вакытта СССРдан килгән кунак портфеленнән... Рудольф Буруковский китабын тартып чыгара. Мактанчык бразилияле сүзсез кала...

БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Дустым Вовка Чиков белән Казансуның кай урында Иделгә коюын белергә карар кылганда, миңа җиде яшьләр чамасы булгандыр, – дип искә ала Буруковский үзенең «О чём поют ракушки» китабында. – Шул максат белән без җәйнең матур бер иртәсендә елга яры буйлап агым уңаена юл тоттык. Ул заманда Казансу ләм баскан тар елга иде. Без яр буена ләмне сөйрәп чыгарып, шуннан елан балыклар тота идек. Без әле текә сул як яр, әле сөзәк каршы як яр буйлап бардык. Уң якта, су чигенеп, ләмле елга төбе ачылган һәм ул, кибеп, күппочмаклыкларга яргаланган иде. Суга кергәч, аяк бармаклары белән капшап, тешсез әкәмтөкәмнәр тартып чыгарабыз. Бу ташка охшаган шома нәрсәнең тере икәнен белгәч, шулкадәр гаҗәпләнүемне әле дә хәтерлим!

Учак янында корымга буялып бетеп ярым ялангач утырган чакта, без үз-үзебездән бик канәгать, күп нәрсәне ваемлап та бетермичә, тормыштан ләззәт ала идек... Ун елдан соң, төрле юллар аша узып, икебезнең дә биология фәненә кереп китәчәгебезне, хәтта фән докторлары булачагыбызны, әлбәттә, белми идек».

КАБЫРЧЫКЛАР ҖЫЮ ТЫНЫЧЛЫК УРНАШТЫРА

Буруковский кабырчыкларны җыя гына башлаганда, экспедициядән кайткан иптәше аңа берәр совет коллекционеры белән элемтә урнаштырырга теләгән америкалы ханымның адресын бирә. Бу – Китти Уэстфолл – ун бала анасы, коллекционер, фотограф, язучы һәм, аның белән читтән торып дуслашкан Рудольф Буруковский сүзләренә караганда, искиткеч кеше була. Аларның дуслыгы Буруковскийның аңа посылка җибәрүеннән башлана. Галим Америкага посылка белән Көнбатыш Африка суларында тапкан 14 кабырчык юллый. «Күз алдыгызга китереп карагыз. Бу кабырчыклар бик сирәкләрдән булып чыга, һәм аларның даны еракларга тарала. Китти ханым әйтүенчә, кабырчык сөючеләр аларны карарга дип уннарча миль ераклыктан килә. Шуңа күрә бу кабырчыкларны Флорида штатының Сент-Питерсберг шәһәрендә ел саен үткәрелә торган конхиология күргәзмәсенә куялар, анда аларга Смитсон институтының мактаулы бүләге – зәңгәр тасма тапшыралар. Ләкин эш анда түгел. Китти үзенең күргәзмәсен «Совет траулеры бортыннан килгән кабырчыклар» дигән исем белән тәкъдим итә. Кабырчык җыю бөтен дөньяда тынычлык урнаштырырга һәм үзара дуслыкны, килешүне тагын да ныгытырга ярдәм итә.

Аның шулай икәнен исбатларга кирәкме? Һәм шулай булсын да».

АНЫҢ БӘХЕТ ФОРМУЛАСЫ

Анатолий Аграновскийга (аларның дуслыгы күп елларга сузыла) язган хатларының берсендә галим болай ди: «Ә бәхет ул – күңелнең бер мизгеллек халәте. Мин аны төрле шартларда, төрле сәбәпләр аркасында күп тапкыр кичердем. Бәлки, һәрвакыт нәрсәдер эзләгәнгә һәм тапканга, бәхетледер мин?»

Болгарда Согуд Гарәбстаны принцы белән.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

ФӘРХӘТ ФӘТКУЛЛИН

Дмитрий Сивков

...Бу кешеләр чит илгә сәфәрләр вакытында яки кунаклар кабул иткәндә һәрвакыт дәүләт эшлеклеләре, эре бизнес вәкилләре артына баса. Юк, алар тән сакчылары түгел, гәрчә аларга да иминлекне саклау ышанып тапшырылса да. Бу очракта кешенең үзен түгел, ә аның сүзенең дөреслеген саклый алар. Фәрхәт Фәткуллин – тәрҗемәче. Аны Казан университетын тәмамлаган дип саный алабыз, чөнки ул белем алган Казан финанс-икътисад институты КФУ составына керә.

Фотолар Фәрхәт Фәткуллин архивыннан

РУСЧА КЫЗЫК ЯҢГЫРЫЙ

БЕРВАКЫТ итальян скульпторы Лоренцо Куинн Казанда үз күргәзмәсен ачканда: «Мин русча кызык яңгырыйм икән!» – ди. Тәрҗемәче Фәрхәт Фәткуллинның сәнгатьле һәм кайчак хәтта артистларча сөйләвенә тамашачылар гына түгел, маэстро үзе дә игътибар итә.

– Сез тәрҗемә иткәндә артистлардан бер дә ким түгел. Ниндидер әзерлек үттегезме?

– Юк, әмма театрда тәрҗемә итәргә туры килде, геройларның төрлесен – яхшыларын да, яманнарын да. Гомумән, безнең эшкә бик күп факторлар йогынты ясый: әйтик, стадионда тәрҗемә итү бер хәл, ә инде шәхси әңгәмәләрдә яисә күргәзмә ачылышында – икенче. Әмма һәр очракта да син аралашудагы барлык мәгънә төсмерләрен дөрес җиткерү өчен җаваплы: сүзләр аша әйтелгәнен дә, мимика һәм ишарәләр белән бирелгәннәрен дә.

– Бу инде психологиягә бик якын…

– Әйе, мәсәлән, «Боинг» авиаһәлакәтендә һәлак булганнарның туганнары белән юристларның аралашуын тәрҗемә иткәндә. Бу вазгыятьтә өстәмә җаваплылыкны тоеп эшлисең. Яки сиңа рухани яки врач белән аралашкандагы кебек шәхси нәрсәләрне тәрҗемә итәргә туры килгәндә. Тәрҗемәченең бурычы бер – бөтенесе дә бөтен нәрсәне дә аңларга тиеш.

ТЕМАНЫ БЕЛҮ ТУРЫНДА

– Ләкин үзенчәлекле темалар буенча аралашканда тәрҗемәчегә дә бик күпне белергә кирәк, кайчак бу турыда беренче мәртәбә ишетергә мөмкинсең.

– Әлбәттә, теманы өйрәнергә никадәр күбрәк вакыт бирелсә, шуның кадәр яхшырак. Сүз уңаеннан, мин үзем профессиональ тәрҗемәгә нәкъ шулай килдем. 2000 ел, миңа ул вакытта 20 яшь иде. Казанда ниндидер чаралар уздырылды, Минскидан теманы белүче белгеч килә алмаган. Кемдер монда «бер талантлы егет» барлыгы турында әйткән. Темага төшенер өчен, минем белән берничә көн эшләделәр. Сүз уңаеннан, ковидтан соң нигәдер заказчылар чара алдыннан бер көн кала гына элемтәгә чыга башладылар. Белмим, бу нәрсәгә бәйледер: авыру нәтиҗәсеме, буыннар алмашынуы шушымы, бәлки, планлаштырудагы үзгәрешләргә дистант йогынты ясагандыр. Яшьләр: «Нәрсәсе бар аның, хәзер хәл итәбез», – дип уйлый.

ӘНИГӘ ЭШКӘ БАРГАНДА ЮЛ УҢАЕ ИДЕ

– Гомумән сезнең профессиягә ничек киләләр? Иняз аркылымы?

– Кем ничек дип уйлыйм. Беренче белемем буенча мин – финанс менеджеры. Хәтта югары уку йортында инглиз теле дә укыттым. Телләр белән кызыксыну, үзем өчен ниндидер яңалык ачу теләге һәрвакыт бар иде. Барысы да француз мәктәбеннән башланды. Әни мине шунда укырга бирде, чөнки аңа эшкә барганда юл уңае иде. Әти-әнием – инженерлар. Юл башы шул булды. Әни бервакыт: «Улым, син инде биш тел беләсең. Бәлки, тәрҗемәчегә барыргадыр?» – диде. Ә мин ул чакта яшь, кәттә: «Бармыйм, үзләре тәрҗемә итсеннәр!» – дим. Ләкин тормыш барысын да үз урынына куйды. Һәм моңа бер дә үкенмим.

– Ничә тел беләсез?

– Татар, рус, инглиз, төрек, итальян, француз телләрен. Румын һәм испан телләрендә җиңел укысам да, аларга көч сарыф итмәскә булдым.

ТАТАРЧАДАН ИНГЛИЗЧӘГӘ ҺӘМ КИРЕСЕНЧӘ – БИК ҖИҢЕЛ!

БЕРВАКЫТ, Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән елда, Фәрхәт Фәткуллин дәүләт хакимияте органнары игътибарына эләгә.

– ТР Рәисе аппаратының Дәүләт беркетмәсе идарәсе бар, аңа тәрҗемә бүлеге дә керә. 2013 елга кадәр штатта булдым, бүлекнең баш белгече вазифасында. Гаилә мәшәкатьләре аркасында киттем: балалар үсеп килгәндә эш көненең җайлылыгы мөһимрәк иде. Әмма хәзер дә хезмәттәшлекне дәвам итәбез. Тәрҗемә бүлегенең штаты зур түгел, Татарстан исә бик актив, шуңа күрә вакыт-вакыт читтән дә белгечләр җәлеп итәләр.

Казан тәрҗемәчеләре күп түгел, безне ил буенча үткәрелгән төрле чараларга актив чакырып торалар: Мәскәүдән – Питерга, Сочидан Ерак Көнчыгышка кадәр. БРИКСта Россия рәислек иткән елда да чараларга чакыру булды. Юридик статусым – үзмәшгуль, эшләремне алып баручы секретарем бар.

– ТР Рәисе белән соңгы тапкыр кайчан эшләдегез?

– Быел җәй, Согуд Гарәбстаны принцы Турки Әл-Фейсал белән очрашуда. Мин аны республика буенча сәфәрендә озатып йөрдем. Мине күргәч, Рөстәм Нургалиевич шунда ук татарчага күчте, ә мин татарчадан инглизчәгә һәм киресенчәгә тәрҗемә иттем. Миңа калса, ул кунакларга резиденциясе буенча экскурсия уздыруны, хөкүмәт әгъзалары белән таныштыруны туган телендә алып барудан канәгать калды кебек.

КӨНДӘШЛЕК КАМИЛЛӘШЕРГӘ БУЛЫША

Бервакыт Фәрхәткә Тәрҗемәчеләр милли лигасына (аңа 20 ел) керергә һәм аның Казан бүлеген оештырырга тәкъдим итәләр.

– Элегрәк бу юнәлештә үзем аңлаганча эшләдем: конференциягә килүче чит шәһәрдәге коллегаларым турында кайгырттым, стандартлар һәм практикалар белән таныша бардым, үзебездәге хезмәттәшләргә дә киңәшләр бирдем. Яшьләр үсә, аларның иң талантлыларын чараларга даими чакырып торабыз. Кайчандыр безне дә шулай җәлеп итәләр иде бит.

– Көндәшлектән курыкмыйсызмы?

– Юк. Көндәшлек форманы сакларга һәм камилләшергә булыша гына. Гомумән, тәрҗемәчеләр дуслык күперләрен җайлауда һәрвакыт катнаштылар һәм катнашалар.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ:

«Татарстан» журналы архивыннан

2009 ел

: сәясәт : проектлар

ИМПЕРАТОР, ДӘҮЛӘТ, ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ



Наталия БЕСПАЛОВА тексты

КДУ, ТДГПИ ҺӘМ КДФИИНЫ ҮЗ ЭЧЕНӘ АЛАЧАК ИДЕЛ БУЕ ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ, МӨГАЕН, ФАЮПБУ «КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ» (ИБФУ) ДИП АТАЛЫР. ФАЮПБУ – УЛ ФЕДЕРАЛЬ АВТОНОМ ЮГАРЫ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ.

19 НОЯБРЬДӘ КДУНЫҢ ГЫЙЛЬМИ СОВЕТЫ ТӘКЪДИМ СЫЙФАТЫНДА НӘКЪ МЕНӘ ШУНДЫЙ АТАМАНЫ РАСЛАДЫ. ИҢ ЮГАРЫ НОКТАСЫ КДУ СТУДЕНТЛАРЫ ҺӘМ АНЫ ТӘМАМЛАП ЧЫГУЧЫЛАРНЫҢ 26 ОКТЯБРЬДӘ УНИВЕРСИТЕТ КАРШЫНДАГЫ «ТАБАДА» УЗДЫРЫЛГАН МИТИНГЫ БУЛГАН ЛОКАЛЬ ОКТЯБРЬ «РЕВОЛЮЦИЯСЕ» ТӨГӘЛЛӘНДЕ БУГАЙ.

Исегезгә төшерәбез, ыгы-зыгы «Төньяк-Көнбатыш, Идел буе, Урал һәм Ерак Көнчыгыш федераль округларда федераль университетлар булдыру турында» 2009 ел 21 октябрь указы дөнья күргәннән соң кабынып киткән иде. Документ, аерым алганда, өч ай вакыт эчендә Идел буе округында «В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты» дәүләт югары һөнәри белем бирү учреждениесе базасында

татарстан / декабрь / 2009

ИСЕМ АЛЫШТЫРУ НИЧЕК БУЛДЫ

2009 ел

»

– КДУга федераль университет, ә Туполев исемендәге КДТУга милли тикшеренү үзәге статусларын бирү Татарстан мәгариф системасында хәлиткеч үзгәртеп коруларга китерәчәк. Яңа федераль университет КДУ, КДФИИ һәм ТДГПУны берләштерү юлы белән оешачак. Берләштерү процессы университетларның педагогия коллективларында үзара аңлашып эшләүне таләп итәчәк, биредә тәккәбберлеккә, кода-кодагыйлыкка, төркемчел эгоизмга юл куелырга тиеш түгел. Монда безнең уртак мәнфәгатьләребез турында сүз бара. Шулай булгач, барлык бәхәсләрне узганда калдырырга кирәк. Барыбызның да ныклы һәм принципиаль торткан урыны булырга тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевнең 30 ноябрьдә вуз Гыйльми советының КДУның 205 еллыгына багышланган киңәйтелгән утырышындагы чыгышыннан.

Идел буе федераль университеты – ИбФУ оештыруга күрсәтмә бирә.

Федераль университет статусы яңа вуз атамасында чагылыш табачак. Ә аның нинди исем йөртәчәге 2010 елның 21 гыйнварыннан да соңга калмыйча билгеле булачак.

«КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ» КАЛАЧАК

КДУ студентлары һәм аны тәмамлаучыларда каршылык дулкынын һич тә иң өлкән Казан һәм Россия университетының федераль югары уку йорты булачагы тудырмады. Җәмәгатьчелекне, нигездә, университетның исемен, хәзергечә итеп әйткәндә брендын югалту куркынычы борчуга салды.

Исем алышыну борчулары белән беррәттән, башка мөһим хафаланулар да белдерелде: бу үзгәрешләр кадрларның кискен кыскаруына һәм белем бирү сыйфатының түбәнәюенә китермәсме? КДУ ректоры Мәгъзүм Сәләхов, мондый борчу-шомлануларны аңлап бетермәү һәм мәгълүмат җитешмәү нәтиҗәсе, дип исәпли.

Вуз башлыгы студентлар белән очрашты һәм хәлне аңлатып бирде. «Казан университеты» исеме (бренды) сакланачак, – дип вәгъдә бирде ректор. – ТР Президенты М. Шәймиевнең РФ Президенты Д. Медведев белән очрашуында бу мәсьәлә һәрьяклап тикшерелде».

ГРАНТ – ИМИНЛЕК ГАРАНТЫ

КДУ ректоры фикеренчә, вуз статусын алыштыру студентлар өчен дә, укытучылар өчен дә тискәре үзгәрешләр тудырмаячак. Кадрларны кыскарту көтелми, ә менә вакантлы урыннарга дәгъва тоткан укытучыларга таләпләр артачак. Ректор формаль яктан укытучыларның эш хаклары артмаячагын билгеләү белән беррәттән, хезмәткәрләрнең матди хәлләре яхшыруга исәп тота. «Галимнәргә күпләгән грантлар, ягъни акча эшләргә мөмкинлек туачак, чөнки аларга камилләшкән җиһазларда эшләргә туры киләчәк», – дип ышандырды вуз башлыгы.

ЛЕНИН ИСЕМЕ КДУ МУЗЕЕНДА ЯШӘЯЧӘК

Әлеге исем алыштыру вакыйгасының «В.И.Ульянов-Ленин исемендәге» дигән тагын бер четерекле ягы бар. Коммунистлар яңартылган вуз атамасында бөтендөнья пролетариаты юлбашчысы исемен калдыруны яклый. Бу уңайдан М. Сәләхов: «Әлегә мәсьәлә хәл ителмәгән, әмма, һәрхәлдә, тарих безнең белән кала, һәм аның белән КДУ музеенда танышырга мөмкин булачак», – дип билгеләп үтте.

Әйтергә кирәк, моның гаять символик ягы бар: яңа уку йорты рәсми исемен 2010 елның 21 гыйнварыннан да соңармыйча алачак. Бер яктан бу – ИбФУ төзелүгә караган өч айлык вакытның тәмамлану датасы гына. Икенче яктан – чын язмыш көлүе! – 1924 елда нәкъ менә шушы көндә әлегә Казан дәүләт университеты аның исемен йөрткән Владимир Ленин вафат булган! Шушы ук 2010 елда Казан дәүләт университетына В.И.Ульянов-Ленин исеме бирелүгә 85 ел тула.

ХӘРЕФ ҮЗ УРЫНЫНДА БУЛЫРГА ТИЕШ!

Сүз уңаеннан, КДУ Гыйльми советы тәкъдим иткән «Казан университеты» брендын үз эченә алган вариантка каршылар да бар. Шулай да бренд «КУ» түгел, ә «КДУ», диләр оппонентлар. 30 октябрьдә Казанда булып киткән Россиянең фән һәм мәгариф министры А.Фурсенко да иялэшенгән аббревиатура яклыларны өметләндерде. Ул вуз Гыйльми советының киңәйтелгән утырышында: «Мин «Казан дәүләт университеты (федераль)» атамасы мөмкин нәрсә дип уйлыйм», – дип белдерде.

Вузда хәлне болай аңлаттылар: «Тәкъдим ителгән атама республикада югары дәрәҗәдә уздырылган консультацияләр нәтиҗәсе булып тора. Ул юристлар белән дә килешенгән. Юристлар фикеренчә, «дәүләт» һәм «федераль» сүзләре вуз атамасында икесе берьюлы була алмый. Ә менә соңгысы тәгаен булырга тиеш».

М.Сәләхов, әле тәкъдим булганчы ук, КДУ аббревиатурасы буенча пошынмаска чакырды. Янәсе, бу ерак тарихта калган атамаларның беренчесе түгел: заманында Казан император университеты – КИУ аббревиатурасы да булган.

ЯНӘ ҮЗ ВАЗЫЙФАЛАРЫНА?

Казан (император) университетына 1804 елның 5 (яңа стиль белән 17) ноябрендә нигез салынган. Ике йөз елдан артык вакыт эчендә университет 150 меңнән артык белгеч хәзерләп чыгарган.

КДУ һәм аның факультетлары Идел буе төбәгендә дистәдән артык югары уку йортын ачу һәм үстерү базасы булды.

ТДГПУ һәм КДФИИ тарихларының тамырлары да КДУга барып тоташа. 1922 елда оештырылган Шәрык пединститутына (2005 елга бу вуз ТДГПУ булып үсеп җитте) нигез салучыларның берсе, KazanHighSchools язуынча, КДУның иҗтимагый фәннәр факультеты була. Ә Казан финанс-икътисад институты (хәзер КДФИИ) 1931 елда КДУның икътисад факультеты базасында төзелгән.

Тарих күзлегеннән караганда, «Казан университеты» атамасы, барыннан да бигрәк, аның башлангыч чорыннан ераклашу түгел, ә киресенчә, аңа әйләнеп кайту булып күренә. Вуз 1917 елның языннан алып күпмедер вакыт бары Казан университеты дип йөртелгән. Архивларда бу чорларны төгәл билгеләүче документлар сакланмаган. Кайбер тикшеренүчеләр вуз инде 1918 елда ук дәүләтнеке булган дип исәпли, кемнәрдер 1921 елны атый... Әлеге уңайдан «Казан дәүләт университеты елъязмасы»нда мондый искәрмәләр табарга мөмкин.

«1923 елның 2 мартында, – дип сөйли КДУ тарихы музее директоры С.Писарева «Елъязма»га таянып, – университет Советының беренче тантаналы утырышы була. Совет Казан университетын «В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты» дип үзгәртеп атау турындагы студентларның гомуми җыелышы мөрәҗәгатен хупларга дигән карар кабул итә».

Һәрберсенең үз тарихы, үз традицияләре булган КДУ, ТДГПУ һәм КДФИИ өчен, нәкъ менә «Казан университеты» берләштергеч атама булыр да, бәлкем. Бу вузларның икесе «казанныкы», берсе «татарныкы»; икесе университет һәм берсе институт булуга карамастан, алар барысы да, асылда, кемнәрнеңдер Казан университетлары булып торалар бит...

31

«Татарстан» журналы архивыннан

2009 ел

ТУГЫЗЛЫККА ЭЛӘГҮНЕҢ МАТУР ӨМЕТЛӘРЕ

2010 ЕЛНЫҢ 21 ГЫЙНВАРЫНА КАДӘР КАЗАН ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫ БАЗАСЫНДА ЯҢА ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТ – ИБФУ ОЕШТЫРЫЛЫРГА ТИЕШ. АҢАРГА КДУДАН ТЫШ, ТАТАР ДӘҮЛӘТ ГУМАНИТАР-ПЕДАГОГИЯ УНИВЕРСИТЕТЫ ҺӘМ КАЗАН ДӘҮЛӘТ ФИНАНС-ИКЪТИСАД ИНСТИТУТЫ КЕРӘЧӘК. ВУЗНЫҢ ПРОГРАММАСЫН ЭШЛӘП-РАСЛАУГА ЯРТЫ ЕЛ ВАКЫТ БИРЕЛГӘН. КАЗАНДА ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТ ТӨЗҮГӘ БУЛЫШЛЫК КҮРСӘТҮ ӨЧЕН РЕСПУБЛИКАДА МАХСУС КОМИССИЯ ТӨЗЕЛДЕ ҺӘМ АНЫ ТР ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ РӨСТӘМ МИННЕХАНОВ ЖИТӘКЛИ. 6 НОЯБРЬДӘ КОМИССИЯНЕҢ БЕРЕНЧЕ УТЫРЫШЫ БУЛЫП УЗДЫ.



Россия белем бирү системасында яңалык – «федераль университет»лар барлыкка килү. Бүгенге көндә ИбФУның ике генә аналогы бар – болар 2006 елда Красноярск һәм Ростов дәүләт университетлары базасында барлыкка килгән Себер һәм Көньяк федераль университетлары. Аларның модельләре бер-берсеннән берникадәр аерыла: җирле үзенчәлеккә бәйле рәвештә КФУга кергән вузлар төрле шәһәрләрдә урнашкан.

ИбФУ инде күпмедер сынап каралган юлдан китәрме, әллә үзенә бер аерым үсеш юлы сайларлармы? Бу яктан әлегә төгәл җавап юк. Бары тик киләчәккә ният һәм матур өметләр генә бар.

ТУГЫЗЛЫККА ЭЛӘГҮ

ИбФУга керергә тиешле вуз ректорлары Казанда федераль университет төзелүгә карата тулысынча диярлек бердәм фикердә торалар (аерым позиция алган КДФИИ генә үз карашын бик ачып салырга ашыкмый). ИбФУ, беренче чиратта, регионның социаль-икътисадый үсешенә ярдәм итәргә, шушы төбәккә бәйле кадрлар һәм фәнни проблемаларны чишү юнәлешендә эшләргә тиеш. Бу турыда КДУ ректоры Мәгъзүм Сәләхов октябрь азагында Татмедиада узган матбугат конференциясендә белдерде.

ТДГПУ ректоры Рәдиф Җамалетдинов ИбФУның Казанда ачылуын хуплый. «Россиянең әйдәп баручы тугыз университеты (җиде федераль вуз һәм тагын МДУ, СПбДУ – авт.) исәбенә керү – бик тә яхшы», – ди ул. Аның фикеренчә, хәтта ректор кәнәфиен югалту да федераль вуз статусы алдында берни тормый (билгеле булганча, ИбФУда бер генә ректор калачак). Иң мөһиме, студентлар отачак.

«Күз алдына китерегез, Алла боерса, бездә укып чыгучыларны нәрсә көтә! – ди ул. – Вуз һәм аның дипломының югары статусы алар алдында карьера үсеше өчен зур мөмкинлекләр ачачак. Алар югарырак эш хакына дәгъва итә алачаклар. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, югары белемгә ия булган кеше, үз һөнәре буенча эшләмәсә дә, байтак юнәлешләр буенча күбрәк яклангән. Ә федераль университет дипломы белән инде – аңа Ходай үзе кушкан!»

РФ Дәүләт Думасы депутаты, РФ Дәүләт Думасының мәгариф буенча комитеты әгъзасы Виктория Черкесова әйтүенчә, КДУ базасында федераль университет оештыру Татарстанның белем бирү тәҗрибәсен өйрәнүгә ихтыяҗ зур булуны күрсәтә. А.Н. Туполев исемендәге КДТУга милли тикшеренү университеты статусын бирү дә шуны раслый. «Болар барысы да – төбәгебезнең фәнни егәрен үстерү, яшь галимнәргә ярдәм итү мөмкинлекләрен арттыру, белем бирүнең яңа үрнәкләрен гамәлгә ашыру, талантлы педагогларны җәлеп итү өчен уңай факторлар. Һич шигем юк, тиешле шартлар тудырганда аларның күбесе, Татарстанда белем алып, биредә калырга теләячәкләр», – ди депутат.

УНИВЕРСИТЕТНЫҢ «ҮТӘЛИ ҖИЛЛӘРЕ»

ИбФУга КДУ, ТДГПУ һәм КДФИИ нинди шартларда керәчәк? Бу классик вуз кысаларында автономия (шундый модель, мәсәлән, Франция мәгариф системасына хас) булырмы? Әллә педагогия университеты һәм финанс-икътисад институты «классик» университетка кушылырлармы? Бу кушылу түгел, ә берләштерү тәҗрибәсе булачак дип, ассызыклады КДУ ректоры

32 татарстан / декабрь / 2009

2009 ел

» - Вуз һәм аның дипломының югары статусы алар алдында карьера үсеше өчен зур мөмкинлекләр ачачак. Алар югарырак эш хакына дәгъва итә алачаклар, - дип саный ТДГПУ ректоры Рәдиф Җамалетдинов.

Мәгъзүм Сәләхов Татмедиадагы шул ук матбугат конференциясендә. Кызыксынучы яклар хәзер модель сыйфатында Себер федераль университеты тәҗрибәсен тикшерәләр, аның базасында 17 институт эшли. ИбФУ, ихтимал, шундый үсеш юлыннан китәр.

«Татар-информ» агентлыгы мәгълүматларына караганда, булачак университет төзелешен база югары уку йорты башлыгы менә ничек күзаллый. ИбФУда, КДУ ректоры фикеренчә, яңа университет структурасын тәшкил итүче берничә институт барлыкка киләчәк. Мәсәлән, берләштерелә торган вузларның физика факультетлары физика институтын тәшкил итәчәк. Педагог кадрлар хәзерләүне дә нәкъ менә «классик» университетта тупларга кирәк. Бу уңайдан педагогия яки укытучылык институтын булдыру планы бар. Ә инде КДФИИга килгәндә, бу вуз ИбФУдагы икътисад институтының бер өлеше булачак.

БЕЗНЕҢ ЮЛЫБЫЗ – АВТОНОМИЯ

ТДГПУда институтлар төзүгә каршы килмиләр: ИбФУ бүлекчәләренең ничек аталулары принципиаль түгел. Вуз коллективы үзенең ИбФУ кысаларындагы вазыйфаларын яхшы күзаллый, ди Рәдиф Җамалетдинов. Һәм аларны гамәлгә ашыруда, беренче чиратта, коллективның бердәмлеген һәм бөтенлеген саклау таләп итела, дип саный ул. Хәзергесе вакытта вузда 900гә якын укытучы һәм шулкадәр ук диярлек укыту-тәрбия процессын тәэмин итүче хезмәткәр эшли. «Билгеле инде, институт алдында торган бурычларны оператив хәл итү өчен безнең вузның ИбФУ кысаларында киң мөстәкыйльлеген, автономиясен саклау таләп ителә», – дип ышанып әйтә Рәдиф Җамалетдинов.

ТРФА академигы, ТДГПУның Аксакаллар советы башлыгы Мирфатыйх Зәкиев педагогик вузның ИбФУда мөстәкыйль институт булып калырга тиешлегенә ышана: «Ассимиляция шуңа китерергә мөмкин ки, Татарстан берничә елдан Казан зонасын укытучылар белән тәэмин итү өчен яңа педагогия университеты ачарга мәҗбүр булачак. КДГПУ һәм КДФИИ хезмәткәрләре, тарихи тәҗрибәдән чыгып, киләчәктә бу вузларның ИбФУдан аерылып чыгу процессы башлану ихтималы булуын әйтәләр».

ИҢ МӨҺИМЕ, ЕГЕТЛӘР, ЙӨРӘКЛӘР КАРТАЙМАСЫН

КДУ ректоры Мәгъзүм Сәләхов ИбФУның төп бурычын белем бирү сыйфатын күтәрүдә, яңа сәләт һәм мөмкинлекләргә ия булган белгечләр әзерләүдә күрә. Чөнки хәзер, аның фикеренчә, белем бирү генә аз, алар тиз искерәләр. Даими рәвештә үзлекләреннән белем алырга омтылучы сәләтле белгечләр хәзерләү зарур. Ректор фаразлаганча, федераль вуз нәкъ менә шундый гади булмаган бурычны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Аңлатма

Жерар БРУССУА,

Франциянең Мәгариф һәм фән министрлыгы генераль инспекторы:

– Хәзерге вакытта бөтен Көнбатыш Европа бердәм белем бирү системасы буенча эшли. Система студентларның белем дәрәҗәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән. Аз санлы институтлар мондый гаять зур мәсьәләне хәл итә алмый. Франциядә хәзер шундый тенденция – университетларны бөтен дөньяга танылып эшләрлек итеп берләштерү. Классик университетларга кергән университет һәм институтлар автономияле икътисадый статуска ирешәләр. Бүгенге көндә Франциядә, укытучы профессиясенең абруен күтәрү йөзеннән, шулай ук мәгариф системасын үзгәртеп кору бара. Белем бирүнең сыйфатын күтәрү белән бергә, укытучыларның эш хаклары арттырыла. Әгәр дә элегрәк эшли башлаучы укытучы айга 1200 евро алган булса, хәзер аның айлык эш хакы 3300 еврога җитә. Һәм чынлап та, хәзер Франциядә укытучылар тагын да белемлерәк булачак. Әмма, билгеле инде, мондый үзгәртеп коруларның проблемалары да юк түгел. 20-25 ел буена бер юнәлеш буенча эшләгән, үз белем бирү системаларына ия булган кешеләр алдына яңача эшләү проблемасы килеп баса.

33

«Татарстан» журналы архивыннан

2009 ел

ТУЛАЙ ТОРАК ТЕОРИЯСЕНӘ ҺӘМ ПРАКТИКАСЫНА КЫСКАЧА ЭКСКУРС

ТУГАН ШӘҺӘРЕНДӘ ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫ ТӘМАМЛАУЧЫДАН СТУДЕНТ ЧАГЫНДАГЫ ИҢ ҖИТЕШМӘГӘН НӘРСӘСЕ ТУРЫНДА СОРАСАҢ, УЛ, МӨГАЕН: «КЫЗГАНЫЧ, ТУЛАЙ ТОРАКТА ЯШӘРГӘ ТУРЫ КИЛМӘДЕ!» – ДИП ҖАВАП БИРЕР ИДЕ. «БӘЛКИ, ХӘЕРЛЕГӘ БУЛГАНДЫР», – ДИП КАРШЫ ТӨШӘР ТУЛАЙ ТОРАК ТОРМЫШЫНЫҢ ҺӘМ УРТАК ЯШӘЕШНЕҢ БАРЛЫК «РӘХӘТЛЕГЕН» БИШ ЕЛ БУЕ, ЭЧТӘН-ТЫШТАН КҮРЕП, ҮЗ ҖИЛКӘСЕНДӘ ТАТУЧЫЛАР.

Әмма Татарстан югары белеменең торак-көнкүреш тарихы инде бөтен көченә языльп баручы яңа сәхифәсен ачарга әзер: Парин урамында Универсиада–2013 авылының беренче чираты төзелә. Мәгълүм булганча, студентлар анда киләсе елдан ук яши башлаячаклар. Ә инде Бөтендөнья уеннарыннан соң авыл Казанда КДУ базасында төзелүче Идел буе федераль университетына калачак.

«ТУЛАЙ ТОРАК»КА ӨМЕТЛӘНҮЧЕ ИДЕАЛЬ СТУДЕНТ ПОРТРЕТЫ

Чын студент менә нинди рәк булырга тиеш: «Иртән торып һәм юынып, укырга китә. Көндез дәресләрдән соң үзенең белемен баету өчен китапханәгә бара, спорт комплексында шөгыльләнә. Һәм тулай торакка төнлә чын мәгънәсендә ял итү өчен генә кайта». Ни кызганыч, тулай торакта яшәүчеләрнең барысы да мондый өметләрне акламый шул! «Кайбер гамьсез студентлар (өзек китерәм – авт.) көндез йоклыйлар, ә төнлә «һава суларга» чыгып, шыксыз кыяфәттә тиешсез вакытта кайтып керәләр».

Әйтеп үтелгән өметләргә янә тукталып, ирексездән уйлап куясың: «Ә мондый бала булганмы соң?» Вузлар, тулай тораклар барлыкка килгән көннән алып, проректорлар, профорглар, комендантлар әвәләргә тырышкан шундый «идеаль студент» булдымы икән?

ТОЛСТОЙДАН АЛЫП, УЛЬЯНОВКА КАДӘР...

Әгәр дә кирәкле томны алып, тиешле урынын ачсаң, күрәсең: төрле чордагы Казан студенты күпләргә мәгълүм һәм хәтта аңа әдәбиятта да мәдхия җырланган. Мәсәлән, Евгений Евтушенконың «Казан университеты» поэмасы: аның юллары аша революциягә кадәрге студентларның барысы өчен уртак портрет күренә.

Конкрет студент персонажларына килгәндә исә, аларга тукталмый мөмкин түгел. Граф Толстойга, мәсәлән:

> **Масаюлы күз карашы белән**
> **билетына бага ник дисәң,**
> **Граф Лев Николаевич Толстой**
> **Тарихтан бит тота имтихан.**
> **Ул бәйләнчек, тәмлетамак, граф,**
> **ул җилкуар – шулай билгеле,**
> **Орлов юртагы бар, нәрсә тагы? –**
> **Кондыз яка – һәйбәт шинеле.**

Менә тарих сәхнәсендә яшь Володя Ульянов та пәйда була.

> **Һәм яшь ташкын, тыелгысыз**
> **кайный да ургыла,**
> **сулдан-уңнан Помпеяга –**
> **патша режимына!**
> **Фетнә кайный, казанында, –**
> **ярсу белән янып, –**
> **йодрыкларын өскә чөйгән**
> **Володя Ульянов.**

Килешерсез дип уйлыйм, бу яшь кешеләрне идеаль студентлар дип атау кыен. Дөрес, гаделлек хакына шуны әйтү кирәк, алар тулай торакта яшәмәгәннәр...

КОРОЛЬЛӘР УЕНЫ

Узган гасырның 70 еллар башында «идея» бәхәсләре университет аудиторияләреннән һәм коридорларыннан тулай торакларга күченде. Кечәге мәктәп балаларын тагын

2009 ел

> Бүгенге көндә КДУ тулай торакларында 2600 студент яши, ә тагын 500-600е торакка мохтаҗ. Студшәһәрчектә урын дагъва итүчеләр саны әле тагын да артачак диләр: БДИ кертелү белән читтән килгән студентлар саны да ишаячак.

тыеп булмый башлады! Тулай торак коридорларында җилкуарларга карата, әдәби телдә булса да, ачулы нотыклар ишетергә мөмкин иде.

Ә ни өчен үгет-нәсихәт биргәннәр соң? Әйе, кайчак салгалаганнар (күбесенчә — затлы «Саперави»). Әйе, ашханәдән савыт-саба ташыганнар. Дөресрәге, ашы-ние белән бүлмәгә алып кайтканнар. Аннан кире кайтарганнар... кайчагында. Әйе, карта уйнаганнар! Ниндидер вульгар «очко»га түгел, хәтта шахмат короле Эммануил Ласкер да кимчелек дип санамаган, зыялы преферанска.

Ә имтиханнарга исә, торакларның берсендә, мәсәлән, ярымподвалда урнашкан кер юу бүлмәсендә хәзерләнә торган булганнар.

РИФМАЛЫ СҮЗ «ОБЩАГА»ДА ДА КҮҢЕЛГӘ ХУШ

Тулай торак романтикасы сәнгатьтә үз чагылышын тапкан. КДУ «общага»ларының да үз җырчылары булган. Студентларның «Әбҗәлилов» тукталышы тирәсендә урнашкан яшәү урыннарын, мәсәлән, эзләре кайдадыр Торонто якларында югалган табиб, бард һәм журналист Борис Гордон мәңгеләштергән.

Әбҗәлилнең тулай торагыннан
Тәти кызлар тәтемәде һич тә безгә,
Җиләктәй булмады үткән көннәр,
Тирә-юньдә күренмәде
берни күзгә...
Чехов базарында сәүдә,
ә «Кольцо»да
Җир асты юлында үбешү –
үзе бер рәхәт...
Бурычларны язмыш кире
кайтарырлык
Казан урамын табарбыз әле без, шәт.

Бу юлларның стиленә карата бәйләнер урын бар, әлбәттә, әмма булып узганны үзгәртеп булмый, ул кала: узган гасырның 90 еллар башында яңгыраган бу җырны тулай торакларда еш «әйләндергәннәр».

ТЫЮЛАРСЫЗ ҺӘМ КУЛГА АЛУЛАРСЫЗ...

КДУ Студшәһәрчегенең тулай тораклары бөтен чор авыруларын кичерде. КДУның тулай тораклары — күбесенчә коридор системалы һәм кечкенә бүлмәләрдән торган бишкатлы хрущевкалар, һәм дә блоклардан торган тугыз катлы биналар. Хәер, аларга рәхмәт һәм хөрмәт! Алардан башка хәзерге торакка коточкыч югары бәяләр чорында нишләр идең! Ә Студшәһәрчектә торучылар «ятак урын» өчен стипендияләренең нибары биш процентын гына түлиләр, ягъни студенттан бер айга 55, ә аспиранттан — 75 сум.

Бүгенге көндә КДУ тулай торакларында 2600 студент яши, ә тагын 500-600е торакка мохтаҗ. Студшәһәрчектә урын дәгъва итүчеләр саны әле тагын да артачак диләр: БДИ кертелү белән читтән килгән студентлар саны да ишаячак.

Тулай тораклар суның начар килүенә дә, кухня торбаларының тыгылуына да, кырып бетергесез тараканнарга түзделәр. Элементар яшәү чараларын мәгънәсез чикләүләрне дә кичерделәр. Хәзер, мәсәлән, студентларга шәхси электр чәйнекләреннән, микродулкынлы мичләрдән файдаланырга рөхсәт иттеләр, ниһаять. Ә бит көнкүреш приборларын «кулга алган» вакытлар да булды! Узган ел ике насос урнаштырдылар һәм тулай торак краннарындагы мәңге хәл ителмәс тоелган су проблемасы юкка чыкты. Имтихан алдындагы төннәрне кер юу бүлмәсендә уздыруның да хаҗәте калмады — барлык гомуми торакларның да уку заллары сессия вакытында тәүлек әйләнәсе эшли. Барлык тулай торакларда да Интернетка бушлай керүле компьютер класслары бар.

Быелгы җәйдә 2 һәм 4 тулай торакларда кухняларга, коридорларга һәм башка гомуми файдалану урыннарына тулысынча санитар эшкәртү уздырылган. Ә җан сөймәгән бөҗәкләр инде күптәннән юк дип сөйлиләр (кайбер мәгълүматларга караганда, алар хәзерге вакытта студентларда артыгы белән булган мобильле телефоннардан чыккан радионурланышны күтәрә алмыйлар имеш).

Тулай торакларда көнкүреш шартлары яхшыра бара. Мебель яңартыла, Студшәһәрчектә ул барысына да җитә дип ышандыралар.

Хәзер КДУ Студшәһәрчегендә алты тулай торак бар. Вуз юбилеена тагын берне төзү турында хыялланганнар иде дә, акча җитмәгән...

Аңлатма

Владимир ЛЕОНОВ,

«Казанда 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада башкарма дирекциясе» автоном коммерцияле булмаган оешма җитәкчесе:

— Уку елы ахырына Универсиада авылының беренче чираты файдалануга тапшырылачак. Бу 75 мең квадрат метр мәйдан. 2013 елгы Бөтендөнья студентлар уеннарыннан соң әлеге комплекс студентлар шәһәрчегенә һәм җыелма командалар резервын әзерләү үзәгенә әйләнер дип көтелә. Күптән түгел «Россия – спорт державасы» форумы кысаларында Универсиада авылының спортсменнар һәм башка катнашучылар яшәргә тиешле бүлмәсен тәкъдир итү үткәрелде. Өч кешегә исәпләнгән 21,9 квадрат метрлы бүлмәдә йокы һәм эш урыннары булдырылган. Фатирда аш бүлмәсе (9,8 квадрат метрлы) һәм шулай ук аерым ванна һәм туалет бүлмәләре каралган. Бүлмәне бизәүдә бернинди артык чуарлыклар булмаячак, әмма заманча төзү материллары кулланылачак.



35

РӘДИФ ҖАМАЛЕТДИНОВ: «БЕЗНЕҢ БУРЫЧ – БҮГЕНГЕ ҖӘМГЫЯТЬ ӨЧЕН ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ ЭЛИТА ТӘРБИЯЛӘҮ»

Евгения Чеснокова

Бу ел Казан федераль университеты өчен юбилейлар елы. Беренчедән, аның оешуына 220 ел тула, икенчедән, татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылуга – 80 ел, ә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдиновка 55 яшь. Галим «Татарстан» журналы хәбәрчесенә филолог булу серләре, хәзерге студентларны ни өчен яратуы, бүгенге көндә тел һәм әдәбият белгечләренең ни дәрәҗәдә кирәклеге турында сөйләде.

– Рәдиф Рифкатович, сез профессияне ничек сайладыгыз? Ни өчен нәкъ менә филология?

– Безнең өйдә һәрвакыт китапларга ихтирам-хөрмәт яшәде, бала чактан китап укырга яраттым. Әти-әниемнең укуын бик рәхәтләнеп тыңлаганым истә. Китапларда гади генә, гадәти генә сүзләр белән әйләнә-тирә дөньяны тасвирлый, нииндидер вакыйгаларны, кеше язмышларын җанлы итеп сурәтли, гәүдәләндерә алу сокландыра иде мине. Акрынлап сүзнең нинди көчкә ия булуын аңлый башладым, шулай итеп, филологиягә мәхәббәтем бөреләнде. Чүпрәле районы Кече Чынлы урта мәктәбе укытучыларына, бигрәк тә беренче мөгаллимәм Рәйсә апа Сафиуллинага рәхмәтем зур.

Филолог булу ул – сүзләр ярдәмендә фикереңне төгәл, дөрес итеп формалаштыра белү, телне сөйләм сәнгатенең югары дәрәҗәсенә җиткереп кулланырга өйрәнү.

– Сез тулы бер буын студентларын тәрбияләү өчен җаваплы. Аларның елдан-ел үзгәргәнен күреп, күзәтеп торасыз. Хәзерге яшьләргә нинди бәя бирер идегез? Нинләр белән кызыксына алар, нәрсәгә омтыла?

– Безнең студентлар – иң беренче чиратта, актив һәм иҗади кешеләр. Аларны чикләмибез, теләк-омтылышларын һәрчак хупларга тырышабыз. Институт базасында төрле иҗат коллективлары актив эшли, алар татар халык мәдәниятен саклау һәм яңа буынга тапшыру вазифасын үти. 2010 елдан институтта «Милли хәзинә» дип аталган халык иҗаты фестивале уздырыла, анда Идел буе федераль округының башка төбәкләреннән килгән студент коллективлары да катнаша. Театр эшчәнлеге киң җәелгән, «Әдәби клуб» эшли. Һәр студент иҗатын үзе теләгән телдә күрсәтә, таныта ала.

Фотолар Рәдиф Җамалетдиновның шәхси архивыннан

– Ә фәндә ничек? Бүгенге көндә заман яшьләренә фән белән шөгыльләнү ни дәрәҗәдә актуаль?

– Студентлар фәнни-тикшеренү эшләре белән дә актив шөгыльләнә. «Мультилингваль шәһәрләрнең лингвистик ландшафты», «Клиник лингвистика», «Текстның катлаулылыгы», «Мәдәниятләр диалогы» һәм башка күпсанлы фәнни түгәрәкләр эшләп килә.

Гомумән алганда, илдә барган социаль-икътисади үзгәрешләр, инновацион үсешкә йөз тоту – болар барысы да булачак белгечләрне әзерләүгә җитди таләпләр куя. Хәзерге белгечләр вакыйгаларны дөрес аңларга, бәяли белергә, яңа вазгыятькә тиз яраклашырга, булган мәгълүматны максатчан рәвештә эшкәртә алырга, гамәли бурычлар белән иҗади якын килеп эшләргә тиеш. Фән белән шөгыльләнгәндә, кешедә нәкъ менә шушы сыйфатлар тәрбияләнә дә. Фән хәзерге вакытта еш кына социаль лифт буларак кабул ителә. Алга таба хезмәт баскычы буйлап үсәр өчен, фәнни дәрәҗә алу – бик әһәмиятле фактор.

– Казан федераль университеты бурычлары арасында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының ролен нәрсәдә күрәсез? Бүген институтта нинди проектлар тормышка ашырыла?

– Институт бүген лаеклы рәвештә КФУ эшчәнлегенең социаль-гуманитар юнәлешендә әйдәп баручыларның берсе исәпләнә. Без, мәсәлән, дисциплинаара фәнни тикшеренүләр өлкәсендә алдынгылардан саналабыз. Институтка укырга кергән яшьләр арасында имтиханнарын 100 баллга тапшыручылар саны һәм БДИның уртача баллы буенча безнең күрсәткечләр бик югары. Студентлар контингентының өчтән берен чит ил гражданнары тәшкил итә. Институтның миссиясен без, беренче чиратта, филологик, педагогик һәм культурологик белемнәрне булдыруда, үзебездә туплауда һәм башкаларга тапшыруда күрәбез. Моннан тыш кешелек тарафыннан тупланган гуманитар кыйммәтләрне тагын да баетуны, бүгенге җәмгыять өчен югары дәрәҗәдәге интеллектуаль элита тәрбияләүне дә бурычыбыз дип саныйбыз.

Зур проектларга килгәндә, алар арасында мәктәп укучылары һәм студентлар өчен Россия дәүләт телләре буенча бөтенроссия олимпиадасы финалын атарга мөмкин. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен рус теле буенча «Живые сказки» онлайн-мәктәбен, Россия һәм БДБ илләренең төрки телле халыклар әдәбиятлары буенча халыкара мәктәп укучылары һәм студентлар фестивален дә билгеләп үтәргә була.

Без тагын бер җитди проектка – татар теле буенча «Ана теле» республикакүләм онлайн-мәктәбенә фәнни-методик ярдәм күрсәтәбез. Анда 34 илдән 10 меңгә якын укучы белем ала, араларында АКШ белән Япониядән торып укучылар да бар.

2020 елдан бирле Казан халыкара лингвистика саммитын уздырабыз. Бу саммитта Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән күренекле белгечләр – лингвистлар катнаша.

– Бүгенге көндә лингвистика гуманитар, физика-математика, табигать фәннәре чикләрендә торган тикшеренүләргә бәйле заманча трендларны үзләштерә һәм актив үсеш кичерә торган өлкә санала. Әлбәттә, институтта да мондый төр фәнни тикшеренүләр уздырыладыр?

– Чыннан да, күпсанлы фәнни эзләнүләр бүгенге көндә лингвистика һәм компьютер технологияләре чигендә уза. Институтыбызда шулай ук «Лингвистика һәм ясалма интеллект» фәнни-тикшеренү лабораториясе дә эшли. Аны бу өлкәдәге зур белгеч, физика-математика фәннәре докторы Валерий Соловьев җитәкли. Лабораториядә тикшеренүләрне филологлар гына түгел, математиклар да, IT-белгечләр дә уздыра. Цифрлаштырылган зур сүзлекләр төзү эше бик актив тормышка ашырыла. Лабораториядә когнитивистика һәм нейрофәннәр өлкәсендә дә тикшеренүләр алып барыла. Шул рәвешле без баш мие эшчәнлеге өлкәсендәге белемнәрне тирәнәйтәбез, кешенең аңы ничек итеп аның сөйләме, билгеле бер дәрәҗәдәге тел берәмлекләре белән бәйле

Рәдиф Җамалетдинов студентлары арасында.

Республика җитәкчелеге институт эшенә һәрвакыт хәерхаһлы.

булуын ачыклыйбыз, телдәге сүзләр һәм гыйбарәләрне барлыкка китерүдә баш мие эшчәнлеген билгели алабыз.

Профессор Марина Солнышкина җитәкчелегендәге фәнни лаборатория базасында мәктәп дәреслекләрендәге текстларга анализ ясыйбыз, аларның балалар тарафыннан ничек үзләштерелүен бәялибез.

«Нейрокогнитив тикшеренүләр» фәнни-тикшеренү лабораториясендә филология фәннәре кандидаты Елена Горобец җитәкчелегендә лингвистика, медицина һәм когнитив фәннәр чигендә кызыклы, уңышлы тикшеренүләр уздырыла. Мәсәлән, табибларга балаларның нейропсихологик һәм сөйләм статусын бәяләргә ярдәм итә торган көндәлек кулланылышта кирәкле инструментарий эшләнде.

– Бүген берничә телдә укыта алучы мәктәп мөгаллимнәрен әзерләү – мөһим мәсьәләләрнең берсе... Белүебезчә, сезнең институт әлеге юнәлештә актив эш алып бара.

– Чынлап та, 2018 елдан, Татарстан Республикасы Хөкүмәте заказы буенча, безнең институт базасында – билингваль, ә 2020 елдан полилингваль педагогик кадрлар әзерләү бара. Алар мәктәпләрдә предметларны рус, татар һәм инглиз телләрендә укыта алырга тиеш. Безнең уку-укыту программалары республиканың полилингваль педагогик кадрларга булган ихтыяҗын тулаем канәгатьләндерә алырлык мөмкинлеккә ия. Иң әһәмиятлесе – әлеге проектны тормышка ашыруда университетның башка институтлары да катнаша. Моннан тыш, университет лицейлары һәм КФУ каршындагы 2 нче гимназия ресурслары да файдаланыла. Педагогик практиканы студентлар Казан шәһәре «Адымнар» полилингваль комплексында да узалар.

Россиядә тиңе булмаган әлеге проект республика бюджеты хисабына гамәлгә ашырыла. Көндезге бүлектә укучы студентлар 15 мең күләмендә стипендия ала, ә укуны тәмамлагач, алар биш ел дәвамында максатчан килешүдә күрсәтелгән мәктәпләрендә мөгаллим булып эшләргә тиешләр.

2023 елда бездә 60 билингвал студент укып чыкты, 2024 елда инде аларның саны 78 гә җитте. Алар барысы да бүгенге көндә максатчан килешү нигезендә мәгариф учреждениеләрендә эшли, 25 белгеч теге яки бу фәнне татар телендә укыта.

– Лингвистикадан аермалы буларак, әдәбият белеме бүгенге көндә әһәмиятле түгел дигән караш яши. Сез моны кире кага аласызмы, әллә ул чынлап та шулаймы?

– Россия фәннәр академиясендә эшләүче хезмәттәшләребез һәм КФУ галимнәре бу хакта башкачарак фикердә. Алар нәкъ менә әдәбиятның хәзерге вакытта лингвистикадан күпкә әһәмиятлерәк булуын раслый, чөнки җәмгыять тормышының игътибар үзәгенә формаль конструкцияләр түгел, ә кыйммәтләр куела.

Уйлап карагыз әле: дәүләт һәм иҗтимагый идеология нәрсәгә нигезләнә? Тарих һәм әдәбиятка! Аларны өр-яңадан җентекләп тикшерәләр, тарихи вакыйгаларны шәрехләү буенча кайнар бәхәсләр бара, шул исәптән кайсы текстларны мәктәп һәм югары уку йортлары программаларына кертү хакында да... Шуңа әдәбият һәм әдәбият белеме искиткеч әһәмияткә ия. Югарыда искә алынган мәсьәләләрне профессиональ дәрәҗәдә хәл итә алырдай белгечләр – әдәбият галимнәре.

Шулай итеп, безнең институтыбызда алып барыла торган тикшеренүләр, әзерли торган белгечләребез замана таләпләренә җавап бирә, аларга ихтыяҗ зур. Димәк, киләчәгебез якты!

акыллы
гамәлләр

игелекле
эшләр

мәңгелек
кыйммәтләр
/

Бу санда тәкъдим итәбез:

Россия күзәтүчесе **ничек** үзбәк сайлауларын күзәткән

Ни өчен кытайлар ут, агач, җир һәм металл «ашый»

Хәләл эчемлекләрне **кайда** әзерлиләр

Германиядән килгән күзәтүче Фәрит Закиров.

ҮЗБӘКЧӘ САЙЛАУЛАР
РОССИЯ КҮЗӘТҮЧЕСЕ ЯЗМАЛАРЫ

Татьяна Вафина

27 октябрьдә Ташкентта иртәдән кояшлы булды.

– Чөнки сайлаулар! – дип елмаялар миңа Ташкент дусларым. – Ә иртәгә тагын яңгыр вәгъдә итәләр...

Мин аларга иярәм, чөнки бу көнне юлларның барысы да Үзбәкстан Республикасы Югары Мәҗлесе* закон чыгару палатасы һәм җирле кенгашлар** депутатларын сайлауларга алып бара.

Үзбәкстан парламентының закон чыгару (аскы) палатасына сайлауларда **75,35%** сайлаучы тавыш бирде.

«МИНЕМ ТАВЫШ – ВАТАНЫМНЫҢ ЯКТЫ КИЛӘЧӘГЕ»

110 нчы мәктәптә урнашкан сайлау участогында сайлаучылар килүгә барысы да әзер. Яшь һәм чибәр көнчыгыш кызлары, журналист һәм күзәтүчеләргә шатлык өстәп, иртәдән үк тавыш бирергә килеп кенә торалар. Күзәтүчеләр арасында – Германия, Россия, Италия вәкилләре һәм хәтта кояшлы Һиндстан вәкиле дә бар – сарига уралган бу ханым барыбыздан да аерылып тора. Әлбәттә, экзотика кадрга да беренче булып эләгә. Ханым мәктәпнең төп истәлекле урыны – китап инсталляциясе фонында җирле телеканаллар өчен бик теләп фотога төшә. Китап янында сайлау урнасы урнашкан. Бу һәркемгә илнең якты киләчәге белемгә бәйле булуын һәм аны тавыш бирү юлы белән сайларга мөмкин икәнлеген искәртә кебек. Сайлауларның төп девизы да «Минем тавыш – Ватанымның якты киләчәге» дигәнне аңлата.

КАЯ КАРАМА – ЯКТАШЛАР

Аннары Ташкент сайлаучылары арасында үзебезнекеләрне (кем уйлаган!) танып алабыз. «Якташлар!» дип, ТНВ телеканалы журналистларының кочагына ташланабыз – Татарстан хәбәрчеләр пункты бу көнне Үзбәкстандагы сайлауларны яктырта икән. Тагын бер «Якташлар!» дигән шатлыклы тавышны без Германия күзәтүчеләре станы тарафыннан ишеттек: күзәтүченең исеме дә гап-гади, үзебезнеке – Фәрит Закиров.

– Әнием рус, әтием татар, ә мин Ташкентта туып үстем, димәк, мин кем? Үзбәк! – ди ул саф татар-рус-үзбәк телендә. – Үстем, укыдым, аннары Германиягә киттем. Анда үз бизнесым бар. Туган ягыма еш кайтам. Иртәгә менә мәктәпкә премия тапшырачакмын... Монда түгел, үзем укыган мәктәпкә, сез дә рәхим итегез, кадерле якташлар!

Барабыз, дип, вәгъдә бирәбез.

БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ ТАВЫШ БИРҮ

Якташлар, хезмәттәшләр белән гәпләшкәндә күзәтүче миссиябез турында да онытмыйбыз. Менә Севара Абдулхаликова беренче тапкыр тавыш бирергә килгән – аңа күптән түгел унсигез тулган. Үзенең гражданлык позициясен аңлатуы гадилеге, самимилеге белән сокландыра: «Мин беренче тапкыр сайлауда катнашам. Сайлауларның ничек узуы бик кызыклы. Демократик партия өчен тавыш бирәм, чөнки ул миңа ошый». Аның белән килгән дус кызлары, кызыксынып, Севараның бюллетеньне урнага төшерүен күзәтә һәм, озак уйлап тормыйча, аның артыннан ук үзләре дә элеге процессны кабатлый. Бер, ике, өч, дүрт, биш... – барлыгы сигез кыз, гражданлык бурычларын үтәп, сайлау участогыннан чыгып та китә. Ә мин бүген дөньядагы иң зур татар диаспорасы кандидатының нәкъ менә шушы партиягә сайлануын искә төшерәм. Сайлаучылардан уңды, ахры, дип тә уйлап куям.

СОВЕТ ЧОРЫНДАГЫДАЙ КҮҢЕЛЛЕ

Бераздан икенче мәхәлләдәге 18 нче мәктәпкә юл тотам, анда тагын бер сайлау участогы урнашкан. Биредә беренче тапкыр E-Saylov*** мәгълүмат системасы ярдәмендә электрон тавыш бирү кулланыла. Монда халык та азрак, матбугат вәкилләре бөтенләй юк. Килеп җитмәгәннәрдер әле. Күзәтүчеләрдән мин үзем генә булса кирәк. Ярар, күзәтүе кызыграк булыр.

– Бездә халык соңрак килә, – дип аңлатты бу хәлне участок эше өчен җаваплы мәктәп директоры Анна Адольфовна Борзова. – Беләсезме ни өчен? Безнең мәктәптә Фәррух Закиров тавыш бирә. Ул якында гына яши. Беләсезме аны? «Ялла» ВИА сәнгать җитәкчесе.

** Үзбәкстан Республикасы Югары Мәҗлесе – Үзбәкстан Республикасы парламенты, дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм закон чыгару органы.*
*** Кенгашлар – советлар.*
**** И-Сайлау (ингл.).*

БЕРЕНЧЕ тапкыр Үзбәкстан парламентына сайлаулар катнаш сайлау системасы нигезендә узды. Шул ук көнне халык депутатларының өлкә, район һәм шәһәр кенгашларына сайлаулар узды.

БЕРЕНЧЕ тапкыр Үзбәкстанда сайлаулар E-Saulov мәгълүмат системасы ярдәмендә электрон тавыш бирү ысулын кулланып узды, бу, сайлауларны оештыручылар фикеренчә, бюрократик киртәләрне бик күпкә киметә һәм аларның үтә күренмәлелеген арттыра.

БЕРЕНЧЕ тапкыр сайлау системасы реформасы партияләрдә хатын-кызлар өчен күбрәк урын калдырды.

Сайлауларда биш сәяси берләшмә катнашты:

Либераль-демократик партия (ҮзЛиДеп) **34,75% тавыш җыйды**;

«Миллий тикланиш» («Милли яңарыш») – **18,82% тавыш**;

Халык-демократик партиясе (НДПУ) – **17,11% тавыш**;

«Адолат» («Гаделлек») – **16,20% тавыш**;

Экология партиясе (ЭПУ) – **13,20% тавыш**.

Белмәгән кая! Советлар Союзында үскән һәр бала белә бу җырчыны.

– Ул гадәттә тавыш бирергә кичкә табарак килә – халык та шуңа күрә шул вакыткарак җыела, бер уңайдан аны күрергә, аралашырга. Ул безгә монда түләүсез концерт куя.

Янәшәбездә торган кешеләр дә директорның сүзләрен хуплап баш кага. Кайберләре атаклы совет суперхиты - «Учкудук»ны көйләп тә җибәрә, сайлау участогында совет чорындагыдай күңеллеләнеп китә...

– Фәррух күренмәдеме әле? – дип кызыксына электрон тавыш бирергә кергән бер әби дә. – Алайса соңрак керермен. Ә тагын бер тапкыр тавыш бирергә мөмкин булачакмы? – дип елмая ул.

– Булды инде, сез үз тавышыгызны бирдегез, – дип җаваплыйлар мәктәп хезмәткәрләре.

– Алайса тавышсыз килермен, – дип көлә җор телле әби. – Фәррух белән исәнләшеп чыгармын, узган сайлаулардан бирле күргәнем юк.

ЭЛЕКТРОН ТАВЫШ БИРҮ

– Ә миңа үз кандидатым өчен тавыш бирергә мөмкинме? Тик мин башка участоктан... – дип кызыксына мөлаем генә бер кыз. – Алайса кайда тавыш бирергә кирәклеген алданрак уйламаганмын. Менә сезнең мәктәп янынннан узганда уйлап куйдым: бәлки, электрон юл белән булгач, монда да сайларга буладыр? – диде ул, өметләнеп.

– Юк, сез үз кандидатыгыз сайланган мәхәлләдә генә аның өчен тавыш бирә аласыз. Безнең мәхәлләдә башка кандидатлар, – дип, кызның өметен өзә Анна Адольфовна.

– Электрон тавыш бирү бит! – дип сүзен бирми теге кыз.

– Без бу системаны беренче тапкыр сынап карыйбыз, – дип аңлата директор сабыр гына. – Бәлки, киләсе сайлауларга теләсә кайсы сайлау участогында үз кандидатың өчен тавыш бирергә мөмкин булыр. Ә хәзергә ярамый.

– Ә монда «Яшелләр» партиясе катнашамы? – дип сорый кыз.

– Катнаша, әлбәттә! – дип җавап бирәләр аңа, партияләр исемлеген күрсәтеп.

– Алайса мин бу партия өчен тавыш бирермен, – дип тынычлана кыз. – Иң мөһиме, минем партия узсын, ә анда барысы да лаеклылар. Мин алар белән! Мин алар яклы!

ИҢ ЯШЬ ҺӘМ ИҢ «ЯШЕЛЛӘР» ТУРЫНДА

Алга китеп шуны әйтәм: кунакчыл илдән киткәндә аэропортта Uzbekistan Airports матбугат хезмәте җитәкчесе Евгения Колосова белән сөйләшеп алдык. Ул да «яшелләр» партиясе өчен тавыш биргән (Үзбәкстанның экология партиясе, республиканың иң яшь партиясе, тавыш бирү нәтиҗәләре буенча барлык тавышларның 13,2% җыйды һәм парламентта 16 мандат алды. – Ред. иск.).

– Экология темасы дөньяда да, аерым алганда Үзбәкстанда да көннән-көн актуальләшә бара, – диде Евгения. – Агачларны законсыз кисүгә каршы көрәш, иясез калган хайваннарны кайгырту, приютлар төзү һәм финанслау, башкалада һәм башка миллионлы шәһәрләрдә һаваның сыйфаты һәм яңартыла торган энергия чыганакларына күчү мәсьәләләре дәүләт дәрәҗәсендә ешрак күтәрелә. Болар барысы да икътисад, мәгариф яки сәламәтлек саклау кебек үк мөһим. Партия программасында бүгенге көндә мөһим мәсьәләләрнең күбесе буенча конкрет карарлар бар. Моннан тыш, бу сайлауларда экопартиядән Мирзо-Олугбәк районы кенгашына сайлауларда танылган хайваннар яклаучысы, Үзбәкстанда сукбай этләр өчен беренче «Хәят» приюты ачкан Ирод Маткәримов катнаша. Бу, һичшиксез, минем экопартия өчен тавыш бирүемә йогынты ясады.

КИЛӘЧӘГЕ МАТУР БУЛСЫН!

...Кич белән төрле илләрдән килгән барлык күзәтүчеләр ресепшен янында түгәрәк өстәлгә җыелдык. Фикер алмаштык, тәэсирләр белән уртаклаштык. Барыбыз да гөр килә. Кытайлар – кытай телендә, инглизләр - инглизчә, итальяннар – итальянча, россиялеләр исә рус телендә. Очрашу азагында – Үзбәкстанның милләтара аралашу телендә. Без кунак булган ил, аның халкы, гореф-гадәтләре һәм барыбыз тарафыннан да танылган кунакчыллыгы – һәртөрле мактаулардан өстен һәм шулай булып кала дигән нәтиҗәгә килдек.

– Кайсы гына партия җиңсә дә, аның эшчәнлеге һавасы да, табигате тә, халкы да, бөтен кешене берләштереп, йөздән артык төрдә пешерелә торган бик тәмле пылавы белән шаккатырган шушы үзенчәлекле, матур көнчыгыш иле файдасына гына булсын!

Халыкара күзәтүчеләр ясаган иң зур нәтиҗә шундый булды.

Күзәтүче ханым рәхәтләнеп фотога төшә.

ҮЗБӘК ХАЛЫК ӘЙТЕМЕ:

БАЙЛЫК ТҮГЕЛ, БЕРДӘМЛЕК – ЗУР БАЙЛЫК.

«Ялла» ВИА сәнгать җитәкчесе Фәррух Закиров һәрвакыт 18 нче мәктәптә сайлый.

Севара Абдулхаликова сайлауларда беренче мәртәбә катнаша.

Евгения Колосова үз тавышын «яшелләр» партиясе өчен биргән.

редакция кухнясы

Фотолар: Ната Смирнова. РЕКЛАМА

«КЫТАЙ ИШЕГАЛДЫ»ННАН – СЫЙЛАНУ ФӘЛСӘФӘСЕ

Татьяна Вафина

Бүген без төшке ашны «Кытай ишегалды» ресторанында ашыйбыз. Безнең кытай кухнясын әле үзләштерә генә башлаган ашказаныбыз кабул итә алырдай сый китерүләрен үтенәбез. Беренче мәртәбә, танышканда ашый торганнарны ягъни. Ресторан идарәчесе Василий Демьянов безгә өч төрле сый тәкъдим итә – 宫保鸡丁，糖醋鳕鱼 һәм 新派奶味香蕉酥.

Ике кытай студенты, бармаклары белән менюга төртеп күрсәтеп, җәһәт кенә теләгән ризыгын сайлап та куя. Без исә, бу күзне камаштырган иероглифларга карап тора-тора, тәрҗемә итүләрен сорарга мәҗбүр булабыз.

宫保鸡丁 – ГУНБАО ЧЕБИЕ

– Сычуань кухнясының легендар ризыгы бу, – дип таныштыра безне пешерелгән чеби белән Василий Иванович. – «Гунбао чебие» дип Цин династиясе чорында Сычуань провинциясе губернаторы булган Дин Баочжэнь хөрмәтенә аталган. Губернатор авызны өтеп ала торган һәм тәмләткечләр кушып хушландырылган ризыкка хирыслыгы белән аерылып торган. Ашчыларына тавыкны авызны өтә торган итеп, тәмләткечләр янына тагын арахис та кушып әзерләп бирергә боерган. Сый шулкадәр популярлык казанган ки, аны губернаторның үз исеме белән үк атый башлаганнар. Исеменә, хөрмәтләп, «гунбао», ягъни «сарай сакчысы» дигән титулны да кушканнар. Шул заманнан башлап, Гунбао чебие Сычуаньда, шулай ук бөтен Кытайда да иң яраткан сыйларның берсе исәпләнә!

Безгә китерелгән ризыкта тавыкның ак ите, муэр гөмбәләре, арахис, суган, кишер, ананас һәм шуларны тәмләтер өчен кулланылган сычуань борычы белән имбир бар.

– Бу авызны өтә торгандыр инде, – ди сагаеп кына безнең фотограф.

– Юк-юк! – дип тынычландыра аны Василий Иванович. – Әчкелтем-баллы дисәк, дөресрәк булыр. Без бу гаҗәеп тәмле сыйның рецептын Россия җирлеге өчен махсус яраштырдык. Аны һәркем авыз итеп карый алсын өчен! Теләге булганнарга махсус авызны өтәрдәй итеп тә әзерләп бирә алабыз.

КИРӘК БУЛАЧАК: тавыкның ак ите, муэр гөмбәсе, арахис, суган, кишер, ананас, сычуань борычы, имбир, тәрәч балыгы, бәрәңге крахмалы, әчкелтем-баллы соус, банан, үсемлек мае, көнҗет.

糖醋鳕鱼 – ӘЧКЕЛТЕМ-БАЛЛЫ СОУСТА – ТӘРӘЧ БАЛЫГЫ

Беренче авыз итүчеләр өчен чираттагы сый – әчкелтем-баллы соуста бирелә торган тәрәч балыгы.

– Балык тиз әзерләнә һәм бик тәмле килеп чыга, – ди Василий Иванович, безне кухняга ашчы Чжан янына әйдәп.

Чжан тәрәч балыгын тиз генә вак кисәкләргә бүлде дә бәрәңге крахмалында әвәләп алды. Шуннан соң майда кыздырып, әчкелтем-баллы соус белән бергә өстәлгә тәкъдим итте. Соуска өстәмә ингредиентлар да өстәлә икән – башлы суган белән гөмбә.

– Бу «муэр» исемле кара агач гөмбәсе, – дип аңлата Василий Иванович. – Ул аермачык үзен сиздереп тора торган дым исенә ия, өстәвенә, гөмбәләр кетердәп тора, баллы, итләч. Муэр Кытайда төрле ризыклар әзерләгәндә бик яратып кулланыла. Кытайлар аны колак яхшы ишетсен өчен файдалы дип саный.

新派奶味香蕉酥 – КЛЯРДАГЫ БАНАН

Десертка Чжан «Кытай ишегалды»ның гадирәк, әмма шулай ук үзенчәлекле, бик тәмле сыен әзерли: клярдагы банан.

– Яшел банан? – дип аптырашта калабыз без.

– Әйе, – ди ул, башын гына кагып.

– Бу десертны әзерләгәндә, өлгереп җитмәгәнрәк яшел бананнарны куллану кулай, – дип «агарталар» безнең редакцияне. – Нәкъ менә шундыйлар фритюрда кыздырып алыр өчен яраклы.

Шулай ук ак шикәр комы кушылган крахмалда әвәләп алынган бананнар, көнҗет һәм үсемлек мае агызып, фритюрда кыздырыла.

– Көнҗет белән бизәлгән бу ризык сезне илһамландырырга тиеш, һәрхәлдә, битараф калдырмаячак, – ди Василий Иванович.

ИНЬ БЕЛӘН ЯН

Чыж-чыж ризык пешкән арада без, касәләргә яшел чәй агызып, гәп корырга да өлгерәбез...

– Кытай кешеләренең туклану фәлсәфәсе турында күп ишеткәнем һәм укыганым бар, әмма сездән ишетү яхшырак булыр. Бу фәлсәфәнең нигезендә ни ята?

– Инь белән ян тәгълиматы буенча, галәм бер-берсенә капма-каршы булган, ләкин берсе икенчесен тулыландыра, бөтен итә алган көчләрнең алышынып торган тигезлегенә нигезләнә, – дип сөйләп китә Василий Иванович. – Шул рәвешле, Инь хатын-кыз башлангычын гәүдәләндерә, ул төнне һәм салкынны белдерә, ә менә Ян – ир-ат башлангычы дигән сүз, көнне һәм җылылыкны символлаштыра. Бу ашауга да кагыла, без туклана торган продуктларга да. Мәсәлән, салкын, сусыллык тойгысы бирә торган продуктлар Инь башлангычына карый, ә менә кайнар һәм өтеп ала торганнар – Ян. Ризыкны әзерләү ысулларында да чагылыш таба фәлсәфә. Димәк, Инь белән Ян арасында дөрес тигезлек урнаштыра аласыз икән (әйтик, нейтраль продуктлар ярдәмендә, мисал өчен, дөгене алыйк), сәламәт буласыз дигән сүз. Сезне тагын бераз теориягә тирәнгәрәк алып керим әле, – дип дәвам итә Василий Иванович. – Кытай кухнясында тагын бер фәлсәфә яши – биш элемент фәлсәфәсе. Аның буенча, продуктлар биш төрле элементның сыйфатларын үзендә йөртә – ут, агач, су, җир, металл.

Инь белән Ян, биш элемент арасындагы тигезлек бозылган икән, кеше авырырга мөмкин. Нәкъ менә шул тигезлекне яңадан кайтару өчен Кытай медицинасына мөрәҗәгать итәләр

дә инде. Экзотик ингредиентлар да шуннан килә – мисал өчен, женьшень тамыры, гаҗәеп гөмбәләр, диңгез атлары һ.б.

«...МОНДА ҖИР ҺӘМ МЕТАЛЛ ҖИТМИ»

– Ресторан эше дә бу фәлсәфәгә нигезләнәме? Безнең бүгенге төшке ашыбыз нинди? Утмы? Агачмы? Металлмы? Җирме? Әллә барысының бергә кушылмасымы? Мондый ризык безнең сәламәтлеккә нинди йогынты ясаячак?

– Әйе, фәлсәфәне сакларга тырышабыз. Әмма бу ашчы плитә каршында торып: «Хәзер менә бер чеметем Инь өстим, аннары бер чеметем – Ян...» – дигәнне аңлатмый, билгеле. Шулай ук ул: «Монда җир һәм металл җитми...» – дип тә үлчәп тормый. Кытай кухнясы ризыклары, ризык кабул итү фәлсәфәсе шикелле үк, меңьеллыклар буена формалашкан һәм тәрбияләнгән. Без инде бу белемнәрне сеңдереп рецептлары булдырылган һәм хәзерге көннәргәчә сакланып килгән, файдасы сыналган ризыкларны әзерлибез.

Әйдәгез, сезнең өчен әзерләнгән бүгенге төшке аш буенча аның нинди энергияләрне үз эченә алуын барлып карыйк.

– Без риза!

Өстәлдә Гунбао чебие пәйда була, аның артыннан ук – әчкелтем-баллы соуста әзерләнгән тәрәч балыгы белән яшел банан да... Тукта-тукта, аны бит танып булмый – яшеллегеннән берни дә калмаган, алтынсу булып тора...

– Кеше организмына, дөрес эшләсен өчен, Ци энергиясе таләп ителә, – дип, «лекцияне» дәвам итә Василий Иванович. – Аның бер өлеше безгә туганда ук бирелә – Ян-ци, ә калганы сулышыбыз һәм ризыгыбыз аша керә, тулылана. Ци безнең организмга кайбер балык, кош ите, коры тәмләткеч төрләре белән керә, болар – җылы элементлар. Кайнар элементлар – бәрән ите, йә булмаса югары градуслы хәмер – үлчәп кенә кабул ителергә тиеш, Инь артып киткәндә, алар таләп ителә.

«Җир» продуктларына ярмалылар – кукуруза, тары карый, шулай ук яшелчәләр – кабак, кишер, гомумән, җиләк-җимешнең төп төрләре. «Агач»ка караучылар – әче элементлар: мәсәлән, үрдәк, тавык, бодай.

Без әзерләгән ризыкларда алар уйлап һәм тиешенчә балансны саклап кушылган, шуңа да ризыклар – файдалы.

ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ ФЭНШУЙ

Ашказаннарыбызны Ци энергиясе белән тутыра-тутыра, без ресторан интерьерының да яңа гына сөйләнгән фәлсәфәгә туры килүен абайлап алабыз...

– Сездә даими рәвештә тукланып, Инь һәм Ян тәңгәллегенә ирешеп буламы?

– Мин интерьер туклану фәлсәфәсенә бәйле рәвештә эшләнгән димәс идем, ул күбрәк биш элементны исәптә тотып ясалган. Кытайлар моны фэншуй дип атый. – Иван Васильевич түшәмнәр белән диварларга күрсәтә. – Без монда агач белән металл күрә алабыз. Су һәрвакыт агып торырга тиеш, бер урында тору аның стихиясенә зарарлы, шуңа да, күрәсез, фонтан җырлый. Утка килгәндә, кухняда ул дөрләп тора, аның стихиясе җитәрлек. Утны әле тагын яктылык бирүче лампочкаларда да күрергә була, алар да үз өлешен өсти.

ҮЗ ОРГАНИЗМЫГЫЗНЫ ТЫҢЛАГЫЗ

– Кытайлар «дөрес» ризыкны ничек итеп сайлый белә? Безгә ничек өйрәнергә?

– Кытайлар сәламәт ризыкны сайлый белә дип кенә уйлау хаклыкка бик үк туры килмәстер, алар күбрәк үз организмнарын тыңлый белә, аңа нәкъ менә хәзер нәрсә кирәген тоемлый. Һәм, әйтергә кирәк, үзеңне тыңлый, ишетә белү еш кына алдатмый.

Ризык сайлый белү һәм ашау культурасы кытайларда озак гасырлар дәвамында формалашып, нәселдән нәселгә күчеп килә. Мәсәлән, алар йөкле вакытта ташбака итен ашарга ымсынган хатын-кызны туктатып калырга мөмкин: моңа җавап табуы кыен, әмма бәби көткәндә, ташбака ашамаска дигән ырым, инану бар. Ә менә тән матурлыгын саклар өчен, кытай хатын-кызлары гадәттә лотос тамыры куллана.

Кытай ризык культурасында теләсә нинди продукт файдалы була ала, әйтик, шул ук муэр гөмбәсе дә. Әйткәнемчә, ул колакның ишетү сәләтен яхшырта, дигән инану яши.

– Ә менә Россиядә баллы ризыкны артык күп ашарга ярамый, дип ышаналар. Сезнең ризыклардагы баллы тәм кытайларның сәламәтлеге өчен зарарлы түгелме?

– Дөресен генә әйткәндә, әчкелтем-баллы соус Кытайда ул кадәр еш очрамый, ә менә россиялеләр аны үлеп ярата. Кытыйлар барлык ризыкны да диярлек дөге белән ашый, нәкъ менә бу ярма Инь белән Ян энергиясе тигезлеге бозылмасын өчен кулай санала, ул аны артык йә ким булса, нейтральләштерә.

КЫТАЙ ХАЛЫК МӘКАЛЕ:

ЙОРТНЫ – КЕШЕ, КЕШЕНЕ РИЗЫК САКЛЫЙ.

@CHINESECUISKAZ

«КЫРЛАЙ» АГРОФИРМАСЫ: ЧЕБЕШЛӘРНЕ КӨЗЕН САНЫЙЛАР

Сөмбел Могыйнова

«Кырлай» агрофирмасына беренче генә баруыбыз түгел... Сөрелгән кара җирләр инде көзге эшләрнең төгәлләнүе хакында сөйли. Техника рәт-рәт булып басып тора. Әйе, зур хуҗалык акрынлап кышка әзерләнә.

Чебешләрне көзен санныйлар, ел буе эшләгәнгә нәтиҗә ясар чак. Агрофирманың нинди уңышлары бар? Быелгы ел нинди сөенечләр, сабаклар алып килгән? Кырлайга баргач, шул сорауларга җавап эзләдек.

БӘРӘҢГЕ УҢЫШЫ ЯХШЫ

«Кырлай» агрофирмасын республикада яхшы беләләр: Татарстанда җитештерелә торган бәрәңгенең 60 процентын бирердә үстерәләр. 1200 гектар җирдә икенче икмәк үсә. Быел бәрәңге утырту май азагына кадәр сузылган.

– Салкыннан куркып бәрәңгене утыртмый тордык, чөнки ул барыбер тишелми. Тәҗрибә шуны күрсәтә, – диде «Кырлай» агрофирмасының агрономы Рәмис Абдрахманов. – Бәрәңге өчен быел һава шартлары әйбәт булды. Әлбәттә, безнең кырларда заманча су сиптерү җайланмалары тора. Соңгы елларда җәйләр коры, эссе була, шуның өчен дә су сипмичә булмый.

Агрофирмада ел саен бәрәңге уңышын җыярга беренчеләрдән булып тотыналар, чөнки бик иртә өлгерә торган сортлар бар. Быел уңыш бик әйбәт: гектарыннан 400 центнер икенче икмәк җыеп алганнар (узган ел 251 центнер булган). Барлыгы 480 мең тонна бәрәңге уңышы җыелган.

– Көн саен берәр КАМАЗ бәрәңге озатабыз, – дип дәвам итте Рәмис Абдрахманов. – Ярминкәләрдә дә са-

Фотолар «Кырлай» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

табыз. Сорау бар. Шулай язга кадәр сату итәбез. Узган ел бәрәңгене вакуумлап төреп сатуга да чыгардык. Заманга яраклашырга кирәк бит. Кулланучының таләпләренә җавап бирергә тырышабыз.

«ЯШЕЛЧӘЛӘР САТЫЛЫП БЕТТЕ»

Бәрәңге язга кадәр сатылса, чөгендер, кишер кебек яшелчәләр инде сатылып беткән. Хәер, соңгылары йөз гектар гына утыртылган (90 гектар чөгендер, 10 гектар кишер.)

– Кызганычка каршы, яңа елдан соң бәрәңгегә сорау кими, ел да шулайрак була, – ди агроном. – Ә менә соңгы ике елда кишер, чөгендергә сорау зур. Бәясе дә яхшы: бәрәңге 12-15 сумнан сатылса, кишернең килосы – 20, чөгендернеке 25 сумга кадәр менде. Әнә шулай итеп ярыйсы гына эшләп алдык.

– Чөгендер, кишергә караганда бәрәңге үстерү кыйммәткәрәк чыгамы? – дим.

– Әлбәттә, кишер белән чөгендерне ике тапкыр эшкәртәсең, бәрәңгегә җидешәр тапкыр техника керә: чүбен утыйсың, ашлыйсың, агулыйсың.

Агрофирманың 37 мең тонна яшелчә сыя торган базлары бар. Әйткәнемчә, басуларга су сибү агрегатлары урнаштырылган.

– Су сибү агрегатлары төрле, – диде агроном. – Совет чорындагы кебекләре дә, чит илдән кайтарылганнары да бар. Әлбәттә, соңгылары бик көчле: бер урыннан икенче урынга күчереп йөртеп була. 1350 гектар җирне сугару мөмкинлеген бирә. Шулай булгач, корылыклы елда да уңышсыз калмыйбыз.

РАПС МАЕ ЗАВОДЫ

«Кырлай» агрофирмасы иген культуралары кырларын ел саен киметә. Моның сәбәбе бик гади: игенгә бәя түбән. Ә менә җитен, көнбагыш үстерү отышлы икән.

– Агрофирманың үзендә рапс мае ясый торган мини завод бар. Һәм ул безгә бик булыша, – диде «Кырлай» агрофирмасының игенчелек буенча генераль директор урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев. – Үзебезнең рапсны эшкәртеп бетергәч, тирә-яктан да китерәләр, аларга да май ясап бирәбез. Рапс маена сорау зур, бәясе дә яхшы.

Иген уңышы белән дә кызыксынабыз. Нәрсә генә дисәк тә, ашлыксыз булмый. Бу сорауга җитәкче менә ничек дип җавап бирде:

– Май салкын килде бит, шуның өчен дә иген культураларын салкында чәчтек. Шөкер, көзге бодай, арышлар да әйбәт кенә кышлады, язгылары да матур тишелде. Нәтиҗәдә гектарыннан 38 центнер уңыш алдык.

Хуҗалыкта рапсны быел 700 гектар мәйданда чәчкән булганнар. Тик киләсе елга гектар исәбен киметергә уйлыйлар: үзкыйммәтен капламый. Эш шунда ки, рапсны үстерү чыгымлы, ул күп ашлама сорый, бөҗәкләргә каршы тору өчен кыйммәтле агулар сибәргә кирәк. Нәтиҗәдә, сатып алу бәясе кыйммәт булса да, рапс чыгымлы культурага әйләнә. Ә менә көнбагыш белән җитен алай түгел икән. «Кырлай» агрофирмасында быел 140 гектар көнбагыш, 200 гектар мәйданда җитен үстергәннәр. Аны урнаштырып та бетергәннәр. Шуның өчен дә киләсе елга бу культураларны күбрәк утыртырга ниятлиләр.

– Дөресен генә әйткәндә, быел чәчүгә куркыбрак кергән идек, – диде Рөстәм Мөхәммәдиев. – Шөкер, әйбәт кенә башкарып чыктык. Җитәкчебез Марат Габделхәй улы Кәримов чәчүлек орлыкны да табыштырды, ягулыкны да кайтартты. Инде киләсе елга да шулай матур гына эшләргә язсын.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕК

Агрофирма ел саен диярлек техниканы да яңартырга тырыша. Бер ел эчендә генә дә лизингка яңа комбайн, трактор, кукуруз чәчкеч, салам пресслый торган җайланма алганнар. Игенгә бәя түбән булса да, терлекләрне ашатырга иң беренче ашлык кирәк. Ә мөгезле эре терлек саны биредә 2 724 баш!

– 2017–2020 елларга каралган капиталь төзекләндерү программасы буенча Иске Иябаш, Бирәзә авылларында 200 башка исәпләнгән сыер фермалары яңартылган иде, – диде «Кырлай» агрофирмасының директор урынбасары. – Иске Иябаш авылында 1800 башка исәпләнгән мегаферма эшли. Анда бүген 915 баш савым сыеры бар. Тәүлегенә бер сыер утыз литрдан артык сөт бирә. Барысы да автоматлашкан.

...Кайчандыр әтисе башлаган эшне бүген улы дәвам итә. (Агрофирманың башында РФнең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, «Сервис-Агро» директоры Габделхәй Кәримов тора.) Марат Кәримов шәһәрдә туган егет булса да, авыл җанлы бала булып үсә. Әтиләре кинәт кенә вафат булгач, уллары башланган эш ярты юлдан туктатып калдырмый. Бүген «Кырлай» агрофирмасы иң заманча технологияләр белән эшләүче хуҗалыкларның берсе. Күрсәткечләр буенча районда беренче өчлектән төшкәннәре юк. Үз эшеңне яратмасаң, җир эшен белмәсәң, бу нәтиҗәләргә ирешеп булмас иде.

САН

«Кырлай» агрофирмасы карамагында бүген 10 732 гектар җир бар. Агрофирма Арча районының ун авылында эшли. Хуҗалыкта 142 кеше хезмәт куя. Сезон вакытында кеше саны тагын да арта.

ЭМИЗ гастромәйданы –
традицияләрне саклыйбыз
һәм мәдәниятләрне берләштерәбез

Банкетлар
Китерү
Кейтеринг

ЭМИЗ

8 (843) 245 00 55 | Татарстан Республикасы, Казан ш., Сафиуллин ур., 29

ЭМИЗ: йөземнең бар көче һәм файдасы – һәр йотымда
Премиаль сыйфат һәм кабатланмас тәм

ЛАУРЕАТ 100 ЛУЧШИХ ТОВАРОВ РОССИИ 2023 КОНКУРСА
2023 ЛУЧШИЕ ТОВАРЫ И УСЛУГИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
100% ECO PRODUCT
NATURAL 100%
HALAL

emiz.ru
8 800 444 09 37

РЕКЛАМА

МИШЛЕН ХОЛЫКЛЫ ХӘЛӘЛ ҮЗӘК

ЭМИЗ – табигый йөзем чималыннан эшләнгән продукт, аны хәзер татарстанлылар гына түгел, ә Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә дә яхшы беләләр. Дөньяда аналоглары юк. Үзендәге полифеноллар (ә алар – куәтле антиоксидант) составы ягыннан ЭМИЗ – чемпион.

Сере нәрсәдә соң, дисезме? Эш шунда ки, аны әзерләгәндә, йөземнең итләч җимеше генә түгел, ә тиресе, чеме, вак кисәкләргә бүленгән төше дә кулланыла. Экологик яктан чиста бу продуктны авыз итеп караучылар аның файдасы турында легендалар чыгара. Ә рәсми медицина, үз чиратында, моны раслый.

Компания үз продукциясе исемлеген киңәйтү буенча актив эш алып бара, күптән түгел генә монда бизнесның яңа форматын эшләтеп җибәргәннәр. Нечкәлекләре хакында безгә ЭМИЗ компанияләр төркеменә нигез салучы һәм аның хуҗасы Раил Фазылҗанов сөйли:

– Алты ел дәвамында диярлек без чиста йөземгә нигезләнгән продукция чыгарабыз, ул – тулаем хәләл. Чөнки аны әзерләгәндә әчү процессы булмый, пастеризацияләү технологиясе кулланыла. «ЭМИЗ» (эликсир молодости и здоровья – әлеге аббревиатура әнә шулай шәрех ителә) составында шикәр дә, консервантлар да юк. Баштан ук без файдалы продуктларны куллану культурасын максат итеп куйдык, милләтебезнең сәламәтлеген кайгыртуны. Шуңа да, мантыйк буенча, тулаем хәләл булган яңа гастрономия мәйданын булдыру юнәлешендә эшлә дек. Бүгенге көндә бу Татарстандагы, ә бәлки, Россиядәге дә, иң зур хәләл үзәк. 1500 квадрат метрны биләгән мәйданда ике банкетлар залы бар: зур залга 400 кеше сыя, ә кечесенә – 100 кеше.

Безнең кухнябыз – искиткеч! Шулай ук бездә эшләнгән, әзерләнгән, җитештерелгән – һәммә нәрсә дә. Килгән кунакларның уңай фикере таралып, безнең рейтинг берничә ай эчендә яхшы үсте. Хәләл үзәктә хәмерле эчемлекләр булмаган бөтен чараларны да уздыра алабыз: конференцияме ул, туймы, бизнес-очрашуларммы, семинарлармы... Мисал өчен, Татарстан эшкуарлар ассоциациясе безнең даими клиентыбызга әйләнде инде, алар ай саен үз очрашуларын бездә уздыра. Зур булмаган чаралар өчен дә мөмкинлекләр тудырырга һәрвакыт әзербез.

Безнең командада бренд-шеф Жизель Мәһдиева эшли, бу – зур горурлык. Ул – «Искусство на десерт» китабы авторы, Bellouet Conseil* һәм Lenotre** француз мәктәпләрен, EPGB испан мәктәбен тәмамлаган, Мишлен ресторааннарында практика узган белгеч. Аның белән бергә без «хәләл» төшенчәсенең, татарлар белән генә тәңгәлләшеп калмыйча, дөнья дәрәҗәсенә чыгуын телибез. Ул безнең милли ризыклар белән тәңгәлләшсен иде – өчпочмак, токмач, йә булмаса көнчыгыш тәм-томнары белән. Безнең ризыклар шул дәрәҗәдә тәмле һәм затлы, алар Казанның теләсә кайсы иң яхшы рестораны белән сынаша ала. Мин инде десертларны әйтеп тә тормыйм, бер авыз итеп караган кеше аларның тәмен оныта алмаячак.

Өстәвенә, без әле кейтеринг эшен дә җайга салдык. Бу – фуршет кабымлыклары, аларны безнең бренд-шеф Санкт-Петербургтагы икенче бер бик билгеле бренд-шеф белән бергәләп иҗат итте. Безнең хәләл кейтеринг бүгенге заманча Европа стандартларына туры китереп эшләнгән, анда ипи – минималь күләмдә. Менюда бик тәмле вафли, телне йотардай профитроли һәм башка үзенчәлекле ризыклар бар. Шуны да әйтергә кирәк: бәясе буенча да кулай – бер кешегә 600 сумнан башлана. Әгәр сез төшке ашка кунак көтәсез икән, иртән шалтыратып, барысына да заказ бирә аласыз. Кейтерингка заказ ясаганда, барлык клиентлар да бездән 2600 сумлык ЭМИЗ шешәсен бүләккә ала.

Алга таба безнең мәйданда кафе ачарга да ниятләп торабыз.

Инде заказларны нинди телефон буенча кабул итүебезне әйтәсе генә калды:

8 987 290 60 40 банкетлар
8 843 245 00 55 кейтеринг
emizbanket.ru

Гастромәйдан үзе түбәндәге адрес буенча урнашкан: **Казан, Сафиуллин урамы, 29**

* Bellouet Conseil – Белуэ консалтинг (франц.).
** Lenotre – Ленотр (франц.).

AGROMASTER
ЖИТЕШТЕРҮ КОМПАНИЯСЕ
TILLERMASTER
УРТАЧА ТИЗЛЕКЛЕ КУЛЬТИВАТОР
CLASSICMASTER
ЧӘЧҮ АЛДЫ КУЛЬТИВАТОРЫ
MEGADISK
КИҢ ЙӨРЕШЛЕ ДИСКЛЫ АГРЕГАТ
TILLERDISK
КОМБИНАЦИЯЛЕ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
AGRATOR ANCER
АНКЕРЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
AGRATOR DISK
ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
AGROMASTER
Реклама
тел.: 8(85556) 2-39-08
тел.: 8-939-396-83-44
e-mail: agromaster@mail.ru
Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы,
Тукай урамы, 33 а
AGROMASTER
Европа сыйфаты – Россия бәясе!

игелекле
эшләр

мәңгелек
кыйммәтләр

акыллы
гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Әхмәтһади Максуди төрмәдә **ничек** исән калган

Татар хатын-кызларыннан беренче фән кандидаты **кем** булган

«Тарки-Тау» Россия язучыларын һәм нәширләрен **кайда** җыйган

Шигъриятнең милли авазлары **кайда** яңгырый

МИЛЛӘТ АЛГАРЫШЫ ТАРАФДАРЫ ӘХМӘТҺАДИ МАКСУДИ

Илдус Заһидуллин

XX гасыр башында татар милләте алгарышын милли башлангыч мәктәпне заман таләпләре буенча үзгәртеп коруда, яңа методикалар кулланып дәреслекләр язуда, укучыларга дини тәрбия һәм тормыш өчен кирәкле белемнәр бирүдә күрәләр. Бу юнәлештә бер төркем зыялылар зур хезмәт куя һәм матур нәтиҗәләргә ирешә. 1917 елгы инкыйлабка кадәр мәшһүр методист һәм җәмәгать эшлеклесе дигән ат алган шундый шәхесләрнең берсе Әхмәтһади Максуди була.

«ҺӘР МИЛЛӘТКӘ УКЫРГА КИРӘК...»

Әхмәтһади Казан өязе Ташсу авылы имамы Низаметдин хәзрәт Максуди һәм Мәфтуха абыстай гаиләсендә 1868 елның 28 сентябрендә беренче бала булып дөньяга килә. Бу гаиләдә Мәсфүфә, Мәншүрә исемле ике кыз бала үсә. Низаметдинның уртанчы улы Сәлахетдин төп нигездә кала, әтисенең вафатыннан соң Казанга күченеп, сәүдә белән шөгыльләнә, «Скороход» исемле аяк киеме фабрикасы ача. Кече улы Садретдин (Садри Максуди) исә Россия төрки халыклары арасында күренекле сәясәтче булып танылa.

Низаметдин мулла 13 яшьлек олы улын 1881 елны Казанның Күл буе мәдрәсәсенә Габделгаллям хәзрәткә укырга бирә. Бирегә 8 ел уку дәверендә Әхмәтһади үзен зиһенле, телләр өйрәнүгә сәләтле һәм һәрчак белемгә омтылучан шәкерт итеп таныта. Мәдрәсәдән тыш, каланың рус җәмгыяте тормышы белән кызыксына, үзлегеннән русча өйрәнә, репетитор яллап, бу телдә язу күнекмәләре ала. Шәкертнең тагын бер кызыксыну өлкәсе – Госманлы дәүләтеннән китерелгән газеталар һәм матур әдәбият уку. Ул шулай ук Бакчасарайда нәшер ителүче «Тәрҗеман»ны да укый. Шәкерт вакытында ук уйлап йөргән «Мөгаллим әүвәл» («Беренче укытучы») дәреслеген 1892 елда, Күл буе кадим мәдрәсәсендә хәлфә булып шәкертләргә белем биргәндә нәшер итә. 25 яшьлек егет, ике елга Госманлы дәүләтенә барып, андагы мәктәпләрдә укыту тәртибен өйрәнә, төрек язучысы Әхмәд Мидхәт һәм «Икъдам» газетасы редакторы белән аралаша, мөхәррирлек һәм журналист һөнәре белән кызыксына. Истанбулдан кайтышлый Кырымда тукталып, Бакчасарайга, Исмәгыйль Гаспринский янына бара һәм аның тәкъдиме белән бер уку елына «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә гарәп теле укырга кала. Бер үк вакытта мәшһүр редакторга «Тәрҗеман» газетасын нәшер итәргә булыша.

1896 елны Казанга кайткач, Әхмәтһади, милли мәгарифне һәм мәдәниятне үстерү өлкәсендә остазы Гаспринскийның киңәшләрен тотып, үзе әйткәнчә, «Һәр милләткә уку кирәк. Укымаган милләт байый алмый. Юкса без һәр милләтнең, укыган һәм баеган милләтләрнең, хезмәтчеләре генә булып калабыз» дигән фикерен тормышка ашырырга керешә. 1898 елда ул татар алфавиты һәм орфографиясе өлкәсе өчен мөһим булган татарча өстәл календаре һәм «Тәкъвиме дивари» дип аталган беренче стена календаре бастыра.

Татар укытучылар мәктәбендә экстерн юлы белән имтиханнарны уңышлы тапшырып, ул рус-татар башлангыч мәктәбе укытучысы дигән таныклыкка ия була. 1900 нчы еллар башында рус-татар мәктәбендә һәм Икенче ирләр гимназиясендә дин сабакларын алып бара.

1903–1905 елларда Казан университетының юридик һәм педагогика бүлекләрендә ирекле тыңлаучы буларак дәресләргә йөри. Бу аның һәрчак белемгә омтылуының бер чагылышы.

Дәреслекләр авторы буларак танылa башлаган методист 1903 елда – «Йолдыз», Ибраһим Терегулов белән 1904 елда – «Көндез» һәм 1905 елда «Казан» исемле татарча газеталар

Фотолар автордан алынды

чыгару максатында хакимияткә гаризалар биреп карый, ләкин һәрвакыт тискәре җавап ала.

Әхмәтһади Максуди мәгариф өлкәсендә зур эшләр башкара. Туган телдә укырга һәм язарга өйрәтү, дин нигезләре буенча белем бирү, гарәп теле нигезләрен үзләштерү, рус телен җиңел методлар белән укыту, дөньяви фәннәр буенча дәреслекләр язу юнәлешләренә үзеннән шактый өлеш кертә.

«МӨГАЛЛИМ ӘҮВӘЛ»НЕҢ 1918 ЕЛГА КАДӘР 30 ТАПКЫРДАН АРТЫК БАСЫЛУЫ, ГОМУМИ ТИРАЖЫНЫҢ САНЫ 1 МИЛЛИОН 200 МЕҢ ДАНӘ БУЛУЫНЫҢ ТӨП СӘБӘБЕ – ТАТАРЛАРНЫҢ КАДИМИ ҺӘМ ҖӘДИДИ УКУ ЙОРТЛАРЫНДА, КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ, КАЗАХ, КЫРГЫЗ ҺӘМ ҮЗБӘК МӘКТӘП-МӘДРӘСӘЛӘРЕНДӘ КИҢ КУЛЛАНЫЛУЫ БЕЛӘН АҢЛАТЫЛА.

НИЧЕК ИШЕТЕЛСӘ, ШУЛАЙ ЯЗАРГА

Әхмәтһади Казан шивәсенә нигезләнгән туган теленең исемен төрки тел дип атый. Ул татарча ничек ишетелсә, шулай язу фикерен алга сөрә: татар телендә 6 сузык бар дип саный һәм «Мөгаллим әүвәл» әлифбасында кулланган татар алфавитына берничә хәреф өсти: о-ө һәм э.

Бу дәреслек белән укыган балаларның әлифба чоры 3–4 айда тәмамлана, алар беренче уку елында язарга өйрәнеп һәм арифметика нигезләрен үзләштереп чыга торган була.

Максуди укырга өйрәтү өчен язган уку әсбапларын мәддия (мәдд – хәреф) методының ике вариантын да кулланып төзи. Беренче вариант буенча башта балаларга авазлары әйтелмичә генә сузык аваз хәрефләре күрсәтелә, аннары аларга тартык аваз хәрефләре кушылып, туры һәм кире иҗекләр, иҗекләрдән сүзләр ясала. Әмма укытучы билгеле бер вакытка кадәр тартыкларның исемнәрен әйтми. Чөнки сузыклар һәм тартыклар бер иҗек итеп тоташтырыла. Соңыннан аларны сузыкларга һәм тартыкларга таркату башлана. Икенче вариантта сузык аваз хәрефләре берьюлы түгел, ә бер-бер артлы – эзлекле рәвештә күрсәтелә. Башта бер сузык өйрәнелә, аннары аңа барлык тартыклар кушылып, иҗек һәм сүзләр ясала. Әлифбада ничә сузык алынса, тартык авазларны шулчаклы аңа кушып, өйрәнеп чыгарга туры килә.

Методист, татарча да, гарәпчә дә укырга һәм язарга өйрәтүне күздә тотып, укытучыларга методик киңәшләр дә урнаштырылган «Мөгаллим әүвәл»нең беренче басмасын мәддия методының беренче вариантына якынайтып төзи, аннан соңгы кайбер басмаларын икенче вариантына нигезли, ахыр чиктә ике вариантта да дәреслекләр нәшер итә.

Татар җәдиди мәктәпләрендә сыйныф системасы кертелгәч, берьюлы ике-өч башлангыч сыйныфта дәрес алып баручы мөгаллимгә мәддия методы бик кулай булып чыга. Гадәттә мөгаллим беренче сыйныф укучысына берике иҗекне китаптан күрсәтә яки тактага язып куеп китә, үзе исә икенче сыйныф белән эшләргә күчә. Бу вакытта беренче сыйныф баласы, мөгаллим күрсәткәнчә, иҗекләрне ятлый.

Ә ысулы саутия (аваз методы) буенча укучы иҗек ятлап утыра алмый: бу метод бөтен сыйныф белән оешкан рәвештә дәрес алып баруны таләп итә. Бала бу очракта үзенең акылы белән авазлар аша сүзләр һәм иҗекләр китереп чыгара. Бөтен авазны өйрәнгәч, кенә хәреф күрсәтелә. Хәрефләрне кушып сүз-иҗек ясарга укучыга мөгаллим ярдәм итә. Мондый шартларда мөгаллим бер сыйныф баласы белән даими эшләргә мәҗбүр була.

Шул сәбәпле җәдит мәктәпләрендә ысулы саутия белән укырга өйрәнүгә караганда ысулы мәддия киңрәк тарала. Бу хәлнең икенче сәбәбе ул вакытта татар алфавитында һәр авазны белдерүче өстәмә хәрефләр булмавында да.

Татарча әлифбаларын камилләштерүне дәвам итеп, 1902 елны Максуди «Мөтәхәррик әлифба» (мөтәхәррик – хәрәкәттәге) исемле катыргы кәгазьгә язылган зур-зур хәрефләр тупланган кисмә әлифба бастырып чыгара. Шакирҗан Таһиридан соң икенче булып, ысулы саутия буенча төрки әлифба дип, 1914 елда «Рәсемле мөгаллим әүвәл»ен нәшер итә. Шулай ук аның матур язу күнекмәләре өлгеләре тупланган «Мәшкъ хат» уку әсбабын билгеләп үтәргә кирәк.

МИЛЛИ МӘКТӘП ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕКЛӘР

Бу елларда җәдитче-методистлар беренче чиратта башлангыч милли мәктәп өчен дәреслекләр язу белән мәшгуль була. Балаларның ислам дине һәм аның йолалары турында тиешле белем алуларын кайгыртып, Әхмәтһади махсус план төзи һәм 2–3 сыйныфлар өчен «Гыйбадәте исламия» исемле җыентык әзерли. Аның «Гакаид» һәм «Тәһарәт»

Әхмәтһади Максуди Киров шәһәрендә сөргендә. 1934–1936 еллар.

МАКСУДИНЫҢ БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПТӘ ИСЛАМ ДИНЕ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ КОНЦЕПЦИЯСЕНЕҢ МӨҺИМ БЕР ӨЛЕШЕН ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТАРИХЫНА БАГЫШЛАНГАН КИТАБЫ АЛЫП ТОРА.

исемле кисәкләре – башлангыч мәктәпнең 2 нче сыйныфында укучылар өчен, «Намаз», «Җәмәгать», «Руза, зәкат вә хаҗ» исемле соңгы өч кисәге 3 нче сыйныф укучыларына атап языла. Бу китапларда кечкенә балаларга аңлаешлы итеп ислам дине турында кыскача бик күп мәгълүмат китерелә. 1905 елда дөнья күргән «Әхкәме шәргыя» (Шәригать хөкемнәре) җыентыгы, ислам фәлсәфәсендәге фарыз, ваҗиб, хәләл, мөстәхәб һәм хәрәм гамәлләр хакында сөйләнә. Җыентык 4 нче сыйныф балаларына атала.

Гомумән алганда, бербөтен программа итеп язылган бу китапларда автор башлангыч сыйныф укучыларын Матуриди гакыйдәсе һәм Хәнәфи фикһе белән таныштыра, үз-үзен тоту кагыйдәләрен аңлата, яхшыны яманнан аерырга өйрәтә.

Галим, Көнчыгыш фәлсәфәсе белән мавыгып, 1903 елда мәдрәсәләр өчен «Мизан әл-әфкәр» (Фикер үлчәве) – мантыйк дәреслеге бастыра. Әлеге дәреслекне Газиз Гобәйдуллин гарәпчә язылганы һәм шактый күләмле булуы өчен тәнкыйтьли, әмма «бу әсәр – бер «эпоха», мөгаллимнәр файдаланачак бер китап булып калачактыр», дигән бәясен дә бирә.

ҮЗЕБЕЗЧӘ МЕТОДИКА

Тел белеме өлкәсендә Максуди язган хезмәтләр аның чит телләрне яхшы белүенә нигезләнгән. Тел белгече, беренче сыйныфта «Мөгаллим әүвәл»не үзләштергән шәкертләргә атап, гарәп теленә өйрәтер өчен «Мөгаллим сәни» (Икенче мөгаллим) дәреслеген яза. Бу дәреслек балаларны Коръәнне дөрес итеп укырга өйрәтә, тәҗвид кагыйдәләре, иман шартлары, кайбер мөһим догалар һәм зекерләр белән таныштыра.

1898 елда нәшер иткән «Шифаһия» (Гарәп телен өйрәнү буенча йөз дәрес эшкәртмәсе) хезмәте, шулай ук «Истифтах» (гарәпчә синтаксис – төгәл нәхү китабы), «Каванине нәхүия» (икенче сыйныф шәкертләре өчен гарәп синтаксисы кагыйдәләре) дәреслекләре, «Кыйраәт» (гарәпчә уку китабы) – Коръән телен җиңел өйрәтерлек методик алымнары белән аерылып тора.

Әхмәтһади Максуди 1910 елда татар теленең грамматика һәм синтаксисы буенча өр-яңа төр дәреслекләр – фәнни хезмәтләр нәшер итә: «Төрки сарыфы» (морфология), 4 нче сыйныф өчен «Төрки нәхүе» (синтаксис) һәм «Төркичә сарыф рисаләсе» (этимология). Тел белеме өлкәсенә аның «Гарәбият: матбугат вә әдәбиятыбызга катышкан гарәп, фарсы сүзләренең истигъмалендә (кулланылуында) булган кагыйдәләр» (1915) исемле хезмәте дә карый.

Әйтергә кирәк, 1918 елда методистның башлангыч мәктәпнең 2 нче сыйныфы өчен «Тел белеге» (Тел белеме) дәреслегенең беренче кисәге дөнья күрә. Бу вакытка галимнең шулай ук «Төркичә имля кагыйдәләре» исемле хезмәте басылган була.

Рус, немец, француз телләрен белүче Максуди 1911 елны – «Русистан. Практический учебник-самоучитель русского языка для мусульман России по мнемонической десятичной системе», 1913 елны «Фрянгистан. Практический учебник-самоучитель французского языка, составленнный по десятичному мнемоническому методу, основанному на периодическом повторении и на «искусственной практике» дәреслекләре нәшер итә.

Җәдит башлангыч мәктәбенең 4 нче сыйныф укучыларын әйләнә-тирә, табигать һәм техник казанышлар белән таныштыруны күздә тоткан күләмле «Дөнья мәгълүматы» уку китабының максаты һәм структурасы рус педагогы Константин Ушинскийның «Детский мир и хрестоматия»се белән авазлаш. Максуди мөселман балаларына дөнья төзелешен ислам дине карашыннан чыгып аңлата. Башка темаларны язганда биология, география һ.б. фәннәр казанышларына таяна. Китапта йорт һәм хуҗалыкка, фауна һәм флорага, хайваннар дөньясына, җир ландшафтына кагылышлы темалар бар. Икенче бүлектә сүз төрле һөнәрләр, хезмәт кораллары, сәнәгать җитештерү нигезләре һ.б. турында бара.

БЕЛЕМГӘ ЮЛ – КИТАПХАНӘ ҺӘМ МАТБУГАТ АША

Әхмәтһади Максуди мөхәррирлегендә эшләгән «Йолдыз» газетасының тәүге саны кеч-

Әхмәтһади Максуди гаиләсе белән: хатыны Зәйнәп, кызлары Фатимаи-Фәридә һәм Шәфика, уллары Һарун һәм Хашим.

кенә форматта юка журнал кебек дөнья күрә, көндәлек басма буларак күзаллана. 1913 елда ул атнага ике тапкыр нәшер ителә, соңрак атнага 5 тапкыр чыгучы матбагага әверелә. Мөхәррир әбүнәчеләренә ел саен газетага кушымта рәвешендә бер китап бүләк итеп бара.

«Йолдыз»ның беренче санында ул үзе «матбага милли газета буларак оештырылды», дип искәртә, ләкин, ул заман гадәтенә ияреп, аның мәсләген күрсәтми. Мөхәррир сәяси темалардан читтә торырга тырыша, игътибарын тел һәм имля, тарих, мәктәп-мәдрәсә һәм укуукыту, тәрбия һәм әхлак кебек мәсьәләләргә юнәлтә. Садри Максуди Дәүләт думасында депутат булып торган 1907–1912 елларда Дума турында мәгълүматларны һәм энесенең сәяси темаларга чыгышларын татарчага тәрҗемә итеп халыкка җиткереп бара.

Максудиның Казан думасы әгъзасы буларак татар җәмгыяте өчен кылган тагын бер игелекле хезмәте – 1906 елда ул шәһәр җәмәгать китапханәсендә мөселман бүлеген – Көтепханәи исламияне оештыра, 1923 елга кадәр үзе аның мөдире булып эшли. Китапханә шәһәр думасы биргән матди ярдәм һәм иганә акчасына яши. Аның фондына татар һәм рус язучыларының әсәрләре, татар һәм төрек вакытлы матбугаты туплана. Шәһәр халкы арасында китапханә зур популярлык казана, уку залына яшьләр күп йөри. 1913 елның декабреннән башлап, якшәмбе көнне 12.00 дән 16.00 кадәр хатынкызлар да китапханәгә килә ала. Укучылар саны арта бара. Әйтик, 1906 елда уку залына 13,4 мең укучы килсә, 1915 елда 22,4 мең кеше китапханә хезмәтеннән файдалана. Әхмәтһади китапханә эшчәнлеге, китаплар, газеталарга еллык подписка бүләк итүче иганәчеләр турында хәбәрләрне вакытлы матбугатта яктыртып бара.

«МИН – БӨТЕНДӨНЬЯ ФИЛОСОФЫ»

Әхмәтһади 1897 елда Казан сәүдәгәре Сөләйман Мишкинның 16 яшьлек Зәйнәп исемле кызына өйләнә. Бәхетле гаиләдә бер-бер артлы алты бала дөньяга килә. Фатимаи-Фәридә, Һарун, Шәфика, Хашим, Бәһра (9 яшьтә менингиттан вафат була) һәм Бәһрамия.

Совет илендә оешкан яңа җәмгыятьтә Әхмәтһади Максуди үзенең урынын табарга тырыша. 1925–1928 елларда Казанда Шәрык педагогика институтында гарәп теле укыта. ТАССРда татар телен дәүләт теленә әвереләдерү сәясәте кысаларында аның 1923 елда «Татарстан. Самоучитель татарского языка для русских, составленный по индуктивному методу и десятичной системе» китабы нәшер ителә. Тулыландырылган икенче басмасы 1926 елда дөнья күрә.

1927–1929 елларда кечкенә китаплар рәвешендә «Фәнни Камус»ны («Энциклопедический словарь») нәшер итә. Китапка фәнни һәм иҗтимагый-сәяси эчтәлектәге 2300 термин туплана. Энциклопедиядәге терминнар, алфавит тәртибендә түгел, ә эчтәлеге ягыннан 126 параграфка бүленеп, 21 бүлеккә урнаштырыла. Әйтик, автор «Тарих» параграфында 18 терминга аңлатма бирә.

1927 елда совет хөкүмәте 35 еллык педагогик стажы булган мөгаллимгә башта – 50, соңрак 100 сум пенсия билгели. Ләкин педагогның Ливадиядәге дачасы, йорт-җире тартып алына, ул гаиләсе белән ике катлы йортының бер бүлмәсендә яшәргә мәҗбүр була.

Максуди, 1900 нчы еллар башында кызыксына башлаган фәлсәфә темасына әйләнеп кайтып, 1933 елда Көнчыгыш фәлсәфәсенә багышлаган зур хезмәтен тәмамлый һәм аны «Восточная (тюрко-арабская) логика» исеме белән русчага тәрҗемә итә. Аның «Ленин – философ» исемле кульязма фәлсәфи хезмәте дә сакланган.

Илдә репрессияләр башлагач, Әхмәтһади Максуди беренче тапкыр 1933 елда Бөтенроссия социал-фашист партиясен оештыруда һәм советларга каршы эшчәнлек алып баруда гаепләнеп кулга алына һәм 3 елга Вяткага сөргенгә җибәрелә. 1937 елда Казанга кайта һәм ел ахырында кабат кулга алына. Бу юлы пантюркист, панисламист оешма әгъзасы буларак совет дәүләтенә каршы корткычлыкта гаепләнә. Куркытуга һәм кыйнауларга түзә алмыйча, 70 яшьлек Әхмәтһади Максуди үзенә тагылган барлык гаепләрне дә таный. Нерв авырулары шифаханәсенә эләгә. Үлем җәзасыннан котылып калу өчен, табибка үзенең Көнчыгыш фәлсәфәсе хакында лекцияләрен укып, «Мин – бөтендөнья философы» дип, юләр икәнлегенә ышандыруга ирешә. Нәтиҗәдә аңа карата хөкем карары чыгарылмый һәм тоткын төрмәдән азат ителә.

Әхмәтһади Максуди 1941 елның 28 июнендә 73 яшендә Казанда вафат була. Кабере Яңа бистә зиратында, Тукай кабере белән янәшә. Исеме 1991 елда аклана.

Әхмәтһади Максуди гаиләсе белән.

ӘДӘБИ МИРАС САГЫНДА: МАҺИНУР ФӘЙЗУЛЛИНА

Гомәр Даутов

Яшь бара, гомер ага һәм инсан, җыйган тәҗрибәсеннән чыгыпмы, калебендә барган физиологик процессларның сүлпәнләнүенә карапмы, дөньядагы кыйммәтләргә яңа өстенлекләр куя, карашларны үзгәртә, мөнәсәбәтләрне яңача бәяли икән.



ТАРИХ ПӘРДӘСЕНЕҢ БЕР ЧИТЕН АЧЫП...

Соңгы вакытта Батулланың «Урыннары җәннәттә булсын» дигән китабын укыйм. Китапның беренче битенә язылган «Мәрхүм шәхесләребез турында мәрсияләр, хатирәләр» дигән рәсми сүзләр артында титаник, бик тә мәгънәви һәм кирәкле хезмәт ята. Ул шушы китабы белән генә дә әдәбият тарихына кереп кала алыр иде.

Татар дөньясының йөзек кашы булган талант ияләрен ул тормыш-көнкүреш шартларында, дуслары һәм хезмәттәшләре белән аралашуда, киеренке, катлаулы, кайчак кәмит шартларда күрсәтеп, аларның да, нәкъ безнең шикелле үк, ипи-сөт ашый торган гади кешеләр булуын тасвирлый. Язучы безнең алда галәмәт катлаулы да, фаҗигале дә тарих пәрдәсенең бер читен ача.

Татар дөньясы катлы-катлы һәм тармаклы икән. Монда эзләнәсе-тикшеренәсе өлкәләр күп, торган саен яңа яклары белән ачыла тора ул. Моны үзем эшләгән КФУ филиалы булган Алабуга институты мисалында гына да әйтә алам. Мәсәлән, 1913 елда үткәрелгән бокс ярышында Россиянең беренче чемпионы исемен яулаган Нур Алиев узган гасырның 20 нче елларында Алабугада башкарма комитет рәисе булып эшли. Татар хатын-кызлары арасында беренче булып филология фәннәре кандидаты исемен алган Маһинур Фәйзуллина исеме тар даирәгә генә билгеле. Ләкин соңгы вакытта бу исемгә институт директоры Елена Мерзон игътибар итеп, татар филологиясе кафедрасына Маһинур Фәйзуллина эшчәнлеген ачыклау бурычы йөкләнде.

Татарларны инкыйразга китергән биш сәбәпне Гаяз Исхакый әле 1903 елда ук «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә формалаштыра. Шуларның берсе буларак татар зыялыларының тамак туйдырып көн итәр өчен вак-төяк эшләр белән шөгыльләнеп, дөнья мәшәкатьләренә батып, зур эшләргә вакытлары да, көчләре дә калмавы күрсәтелә. Ягъни тормыш-көнкүреш мәшәкатьләренә батып, зур, милли гамьле хезмәттән читләшүләре ассызыклана.

Узган ел Маһинур Фәйзуллина яшәгән йортка институт хисабына мемориаль такта урнаштырылды. Быел галимәнең киңкырлы эшчәнлегенә багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция узды. Биш-алты ел элек, бәгъзе фәкыйрегез әле кафедра мөдире йөген тарткан чагында, Маһинур Фәйзуллинаның кызы Ария апа сау-исән һәм әледән-әле институтка килеп йөри иде. Килгән саен әнисе турында мәкаләләр басылган газета йә фотография күтәреп килә. Ни үкенеч, агымдагы эшләр белән мавыгып, вакытында бу апага һәм ул алып килгәннәргә тиешле игътибар бирелмәгән, соңыннан, ремонт вакытында, кафедраны бөтен кәгазьләре белән башка бүлмәгә күчерделәр, аннан кире кайтардылар... Кыскасы, болганды дөнья, буталды. Ләкин чынлап торып еласаң, сукыр күздән яшь чыга, дигәндәй, эзләнә торгач, Маһинур Фәйзуллинага кагылышлы документлар тутырылган тартма килеп чыкты.

Фотолар автордан, ачык чыганаклардан алынды.

ХАТЛАРДАГЫ ЯЗМЫШЛАР

Маһинур Фәйзуллинаның тормыш юлы чордашларыныкына бик тә охшаган. Ул 1901 елда Арча якларыннан бәхет эзләп чыгып киткән Гайнулла гаиләсендә, казах далаларында урнашкан Атбасар шәһәрендә дөньяга килә. Башта туган шәһәрендә, аннан Троицк шәһәрендәге укытучылар семинариясендә укый. Гражданнар сугышы вакытында Омскига күченә, «Азат Себер» газетасында эшли, 1922 елда шушы газета редакторы Хәбиб Вәлиевкә кияүгә чыга.

1925 елда яшь гаилә Мәскәүгә килә, бер-бер артлы ике уллары – Ук белән Өмет, кызлары Ария туа. 1928 елда ирен Казанга җир эшләре буенча министр урынбасары итеп билгеләләр. Бераздан Хәбиб Вәлиев репрессия дулкыннарына эләгеп һәлак була. «1941 елның көзендә Маһинур Фәйзуллина Алабугага «командировкага» җибәрелә (асылда исә – сөрелә)», – дип яза Наип Лаисов «Татар язучылары – Алабугада» хезмәтендә. Гомеренең ахырына, 1983 елга кадәр, Маһинур Фәйзуллина Алабугада яши, татар әдәбияты укыта, 1956–1967 елларда татар филологиясе кафедрасы мөдире вазифаларын башкара.

Табылган тартмада сакланган язмалар арасында Афзал Шамов, Мөхәммәт Мәһдиев, Габдрахман Әпсәләмов кебек әдипләрнең Маһинур апага язган хатлары кызыклы һәм кыйммәтле. Хатлар арасында миңа Заһидә Тинчуринаныкы очравы да кызыклы тоелды. Белгәнебезчә, Заһидә ханым – драматург Кәрим Тинчурин «халык дошманы» буларак репрессияләнгәч тә, аңа тугры калып, бер урыннан бер урынга күчеп йөреп, булдыра алган кадәр иренең кулъязмаларын, шәхси әйберләрен саклап калган кеше. Үзе әдәби иҗат белән шөгыльләнмәсә дә, ул, татар язучылары, театр әһелләре белән тыгыз аралашып, элемтә тотып яши.

Революциягә кадәр «действительный статский советник» дәрәҗәсенә ирешкән Шаһбазгәрәй Әхмәров гаиләсендә унынчы бала булып дөньяга килгән Заһидә, русча белем алгангадыр инде, күрәсең, Маһинур Фәйзуллинага хатларын русча яза. Әлбәттә, өлкән яшьтәге ике ханымның сүзләре, беренче чиратта, сәламәтлек, олыгаю белән килә торган авырулар турында, һәм бу табигый. Ләкин, нигездә, татар дөньясында барган вакыйгалар, шуңа бәйле рәвештә теге яки бу күренекле кешегә, аның иҗатына бәя бирү – алары да бар. Заһидә ханым Маһинур апага Казан яңалыклары, үзе катнашкан чаралар, аерым шәхесләрнең эшчәнлеге турында сөйли: «Дорогая Майнур, – дип яза ул 1963 елның 1 гыйнварында, – в татарском театре смотрела «Аирле юл» по роману Абсалямова. Не понравилось. Скучно, нудно. Сарымсаков совсем не справился с передачей романа в пьесу. Роман хорош, а пьеса очень плоха».

МИЛЛИ ГАМЬ

Габдрахман Әпсәләмов – Маһинур Фәйзуллинаның укучысы. Язмыш Маһинур апаны ерак Себердән Мәскәүгә китереп куйгач, ул Нариманов исемендәге татар мәктәбенә эшкә урнаша, булачак язучыга татар теле һәм әдәбияты укыта. Әлеге мәктәп янәшәсендәге бинага татар эшчеләр клубы да урнашкан була, монда еш кына ул вакытта шулай ук Мәскәүдә яшәүче Муса Җәлил килә, татар милли музыкасының булачак сандугачы Сара Садыйкова чыгышлар ясый.

Кыскасы, Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә татар дөньясы яши. XX гасыр башы күтәрелеше әле дәвам итә, ләкин, кызганычка каршы, озын гомерле генә булмый.

Әпсәләмов, иҗатының иң югары ноктасына менеп, татар әдәбиятында иң продуктив эшчәнлек күрсәтүче әдип булып танылгач та, укытучысы Маһинур Гайнулла кызы белән элемтәсен өзми. Маһинур Фәйзуллина бер мәкаләсендә болай ди: «Әпсәләмовка язган бер хатымда үземнең Казаннан ераклашуым, әдәби хәрәкәттә катнаша алмавым турында зарланып язганмын...»

1 Дуслар, хезмәттәшләр арасында.

МЕНӘ НӘРСӘ БЕРЛӘШТЕРӘ ЗАҺИДӘ БЕЛӘН МАҺИНУРНЫ! АЛАР МИЛЛИ ГАМЬ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ БЕЛӘН, АНЫҢ ӨЧЕН БОРЧЫЛЫП, КЫЗЫКСЫНЫП ЯШИЛӘР.

Укытучысының күңел халәтен тоеп-аңлапмы, аңа язган җавап хатында Габдрахман Әпсәләмов болай ди: «Сез гомерегезне бушка уздырмадыгыз бит... Сезнең изге эшегез укучыларыгызның, шәкертләрегезнең күңелендә, эшендә җимеш бирә. Әгәр мин язучы булганмын икән, моның өчен мин бит иң элек үземнең укытучыларыма бурычлымын, алар минем күңелемдә ана теленә, туган әдәбиятка мәхәббәт уяттылар. Ә минем шикелле кешеләр сезнең шәкертләрегез арасында бик күп...»

Кеше күңеле – карурман, нинди генә омтылышлар, нинди генә хисләр һәм серләр яшәми анда. Башлангыч белемне яхшы әзерлекле, яңача укыта торган мөгаллимнәрдә алган Маһинур милли җанлы булып формалаша. Укытучылар семинариясендә Газиз Гобәйдуллиннан, Петербургта Бестужевлар курсын тәмамлаган Ракыя Юнисовадан белем алу бәхете тәти аңа. Үз чоры белән аның кыйммәтләре дә рухи нигез булып, умырткасын билгели, әлбәттә.

ТУКАЙ ФӘНЕ БАШЫНДА

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңеле ниләр сизгәнен;
Мескин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Кандидатлык диссертациясенең тикшеренү үзәгенә Тукай иҗатын ала Маһинур Фәйзуллина. Тәрәзә артында – 30 нчы еллар, һәр нәрсәгә марксизм ноктасыннан, һәр әдәби образга сыйнфыйлык күзлегеннән бәя бирелә торган вакыт. Шуларны исәпкә алып, ул Тукайның 1905–1907 еллар иҗатындагы сәяси карашларны өйрәнүне максат итеп куя. Ләкин әле бу вакытта Тукай фәне юк. Бар истәлекләр, бар аерым мәкаләләр, әмма алар җыелмаган, тупланмаган һәм системалаштырылмаган. «Ул елларда Тукай иҗаты басылган газета-журналларның редактор Камил Мотыйгый кулында сакланганын әйттеләр, – дип яза Маһинур Гайнулла кызы. – Мин аның белән таныштым. Мотыйгый миңа кулында сакланган барлык газета-журналларны файдаланырга бирде».

Моны укыгач, Батулланың инде алдарак телгә алынган китабында язылган сүзләр искә килеп төште: «Кызганыч ки, без һәрвакыт соңга калабыз. Ун елга, егерме елга соңга калабыз, гасырга соңга калабыз. Татар акылы төштән соң. Башка килмәгән, өлгермәгәнбез, курыкканбыз; кыскасы, бик тә ялкау без. Ялкау өчен сыныкка сылтау табыла тора. Картлар белән озаклап сөйләшмәдек, эбиләргә йөрмәдек, аларны сөйләтмәдек, алардан фотолар, архивлар алып калалмадык». Маһи-

2 Маһинур Фәйзуллинаның бала чагы. Атбасар, 1910 ел.

3 Семинаристкалар. Троицк шәһәре. 1916 ел.



4 Муса Җәлил автографы куелган бүләк китап.

нур апабыз, күргәнебезчә, ялкау да, битараф та булмаган һәм ул шушы гамәле белән генә дә совет чорында археографик эзләнүләрне башлап җибәргән Сәид Вәлиди, соңрак бу эшне яңа биеклеккә күтәргән Миркасыйм Госманов, Җәүдәт Миңнуллин, язма мирасны җыеп, халыкка кайтару кебек күзгә күренмәс, әмма бәһаләп бетермәслек кыйммәтле хезмәткә бөтен гомерен багышлаган һәм әле хәзер дә дәвам иттерүче Раиф Мәрданов кебек галимнәр белән бергә тарихка кереп калырга лаеклы.

Үзеннән торганны, ягъни тиешле таләпләргә туры китереп диссертация язуны Маһинур Фәйзуллина тиз һәм югары кимәлдә башкарып чыга. «Ләкин... тиз арада гына аны яклый алмый. Репрессияләр, кулга алулардан соң татар филологиясе буенча белгечләр калмый дияргә була», – дип яза Наип Лаисов. Ниһаять, 1943 елда диссертация яклана. Ләкин... «халык дошманы хатыны» дигән кара сакал ияргән галимәгә филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми исем Югары аттестацион комиссия тарафыннан 1949 елны гына раслана.

ҖӘЛИЛГӘ СУКМАК

Татарда шагыйрьләр күп. Ханлыкка пайтәхет булып торган Казанны элек «шагыйрьләр шәһәре» дип атаганнар. Дәүләтчелекне югалтканнан соң да язма әдәбият яшәүдән туктамаган. Ләкин дөнья татарның ике шагыйрен белә: Тукай һәм Җәлил.

Маһинур Фәйзуллина беренчесе турында тәүге өйрәнүче галимнәр рәтендә гыйльми тикшеренүләр үткәрсә, икенчесе белән шәхси таныш булып, тыгыз аралашып һәм иҗатына шулай ук беренчеләрдән булып бәя биреп яши. Мәскәүдә эшчеләр клубында башланган дуслык, дуслык кына да түгел, ә иҗади хезмәттәшлек Казанга кайткач та дәвам итә. «Хат ташучы» поэмасы басылып чыккач, шагыйрьнең автограф язып галимәгә бүләк иткән экземплярлары сакланып калган. Аңа кадәр Маһинур Фәйзуллина Җәлил иҗаты турында мәкалә бастырып чыгара һәм моның әһәмияте ул чор өчен гаять зур була.

5
Соңгы вакытта Маһинур Фәйзуллина эшчәнлегенә институт директоры Елена Мерзон игътибар итеп, татар филологиясе кафедрасына аның эшчәнлеген өйрәнү бурычы йөкләнде.

РЕПРЕССИЯЛӘРДӘН СОҢ, ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ ӨЛКӘСЕНДӘ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ЯЗАРДАЙ, ФӘННИ ЭЗЛӘНҮЛӘР АЛЫП БАРЫРДАЙ КЕШЕ КАЛМАГАН БУЛА.

Галимә үзе болай дип яза: «1939 елда Оренбург педагогика институтының татар бүлеге студентларына совет әдәбияты курсын укытырга җибәрделәр. Программада Муса Җәлил иҗатын өйрәнү дә куелган иде. Күпме эзләнсәм дә, аның иҗаты турында тикшеренү һәм тәнкыйть материалларын тапмадым». Сүз уңаеннан шуны әйтик: тәнкыйть мәкаләләре булмау, бәлки, шагыйрьнең бәхетенә дә булгандыр. Чөнки кайбер тәнкыйтьчеләрнең бары марксизм ноктасыннан гына бәя бирелеп язылган язмалары кешегә ярлык тагуга кайтып кала һәм андый хәл булган очракта, бик мөмкин, без бүген Казан уртасында һәйкәл куелган каһарман Җәлилне белмәс тә идек. Муса Җәлилнең башлангыч чор иҗаты күбрәк марксизм ноктасыннан язылып, аны чын мәгънәсендә шагыйрь итәчәк мәңгелек кыйммәте булган әсәрләр әле соңрак туачагын беләбез...

Маһинур Фәйзуллина шагыйрь әсәрләрен укып, анализ ясый, Җәлилнең үзе белән очрашып, иҗатының идея-тематикасын ачыклый, шигъриятендәге автор позициясен билгели һәм мәкалә «Совет әдәбияты»нда (хәзерге – «Казан утлары» журналы) басылып чыга. Бу Җәлил шигъриятен фәнни тикшерүдә беренче адым була.

Татарстанның көнчыгышында урнашкан кечкенә генә шәһәрдә яшәп, әдәбиятта, мәдәнияттә әнә шундый тирән эз калдырган, педагогик эшчәнлек алып барган тирән рухлы кеше Маһинур Гайнулла кызы Фәйзуллина булганын истә тотыйк әле. Бөтен гомерен татар халкына хезмәткә багышлаган әлеге шәхескә сүзебез дога булып барса иде!

Мари шагыйре, язучы, публицист Анатолий Ишалин.

РОССИЯ КИТАП ДӨНЬЯСЫ – УЧ ТӨБЕНДӘ

Луиза Янсуар

4–6 октябрьдә Махачкалада (Дагыстан) «Тарки-Тау - 2024» 11 нче Халыкара Төньяк Кавказ китап фестивале һәм ярминкәсе узды. Стальский бульвары янәшәсендә урнашкан чатырлар Махачкала халкын чакырып торды: ни генә юк иде аларда – нәниләр өчен чыккан үзенчәлекле басмалардан башлап, китап дөньясы белән бәйле заманча флеш-продукциягә кадәр. Әйдәп баручы нәшриятлар, китап сатуның нечкәлекләрен белгән топ-менеджерлар, исемнәре телдән төшмәгән заман язучылары, милли әдәбият вәкилләре – барыбызны да, мәгърур учларына күтәреп алгандай, җыйды «Тарки-Тау».

Октябрь күркәм булды быел. Ә Каспий яр буенда без аның бөтенләй дә кабатланмас хозурлыгына юлыктык. Оештыручыларга вакытны белеп сайлаганнары өчен аерым рәхмәт. Болар – Дагыстан Республикасы Мәгълүмат һәм нәширлек агентлыгы, «Дагыстан» мәдәни-публицистик журналы, «Укый торган Россия» Китап фестивальләре ассоциациясе, Россия халыклары әдәбиятларын үстерү программасы. 2024 елда фестиваль Көньяк Осетия, Төркия һәм Иран делегацияләрен дә кабул итте. Барлыгы 60 тан артык нәшрият, китап сәүдәсен оештыру белән шөгыльләнүче оешма катнашты.

СССР НЫҢ «ЮГАРЫ ӘДӘБИ ЭШЕЛОНЫ» ҺӘМ ДАГЫСТАН АВТОРЛАРЫННАН – ЗАМАНЧА СКИЛЛ

Дәүләт нәшриятларында басылып чыккан китаплар һәм продукция белән генә түгел, ә шәхси нәшрият тотучылар, аерым авторлар белән дә очрашып, аралашып кайттык. Әлбәттә, «иректе агым»да йөзүчеләрнең – үз йөзү стиле, төпкә китмәүнең үз серләре. Әле узган гасырда гына туган телендә язып, махсус тәрҗемәчеләре булган Рәсүл Гамзатов – уникаль очрак. Совет чорында аларны, һәр республикадан чүпләп алып, югары эшелон милли язучылары буларак күтәреп-танытып, алтын бәһасендә йөрткәннәр. «Милли әдипләрнең» бу югары эшелонына кергән авторларны ишетмәгән совет кешесен табуы кыендыр: кыргызлардан – Чыңгыз Айтматов, башкортлардан – Мостай Кәрим, калмыклардан – Давыт Көгелтинов, казахлардан – Олжас Сөләйманов, балкарлардан – Кайсын Кулиев, абхазлардан – Фазыл Искәндәр...

Фото: фестиваль һәм БГН архивыннан

МАРАТ ГАДЖИЕВ, «Тарки-Тау – 2024» фестивале һәм ярминкәсе кураторы, «Дагыстан» мәдәни-публицистик журналы баш мөхәррире:

– 2012 елда беренче мәртәбә оештырдык, Милли китапханә бинасында. Шуннан бирле Махачкалада һәр көзне «Тарки-Тау» уза. Бу – зур җаваплылык һәм дәрәҗә. Эш буенча Россия китап фестивальләрендә күп булырга туры килде. Һәрвакыт: «Эһ, бездә дә эшлисе иде бит шушыны!» – дип кайта идем. Ул чакта Дагыстанда китап базарындагы хәлләр мөшкел: дәүләт кибетләре нуленче елларда ук ябылып беткән, «Арбат»тан кала, китап сегментында бер генә нокта да юк, ул да балалар өчен китаплар белән уку әсбаплары гына сата.

Махачкалада китап фестивале белән ярминкәсенең кирәклеген аңлату җиңел булмады. «Бу безгә нәрсә бирә соң?» – диебрәк карадылар. Беренче елларда катнашучылардан аренда хакы да алмадык, аларны безнең мәйданга чакырып кызыксындырасы, ияләштерәсе бар иде. Иң истә калган көчле фестиваль-ярминкәләр 2018, 2019 елларга туры килә – Европа (Сербия, Словения һ.б.), Балтыйк буе илләреннән, Әрмәнстан, Казахстан, Азәрбайҗан, Белоруссиядән килделәр.

«Тарки-Тау»га заманның әйдәп баручы тере язучылары, китап базарында трендлар булдыручылар килә. Алар бездә тәҗрибә уртаклашырга әзер икән, инде күп нәрсәгә ирештек, дияргә була. Язучы хезмәтенең дәрәҗәсе, китап мәдәниятен үстерүнең кирәклеге турында сөйләшү гаять әһәмиятле бүген. Милли әдәбиятларга, туган телендә яза торган, аны саклап калырга омтылган шәхесләргә – аерым игътибар.

Туган телендә язганнарга бүген дә Россия базарына чыгуның бер генә юлы бар – рус теленә сыйфатлы, яхшы тәрҗемә аша. Үзен нәшер итәрдәй нәшриятларны табу һәм укучының кабул итәчәгенә ставка ясау.

Башкорт шагыйре Фәнил Бүләков.



СССР ТАРКАЛЫП, «СУВЕРЕНИТЕТЛАР ПАРАДЫ» УЗЫП, ДӨНЬЯ ҮЗ ТИРӘЛИ ТАГЫН БЕРНИЧӘ МӘРТӘБӘ СӘЕР МӘТӘЛЧЕКЛӘР АТЫП АЛГАННАН СОҢ, БҮГЕНГЕ МИЛЛИ АВТОРЛАРГА НИШЛӘРГӘ СОҢ? БУ СОРАУ ҺАМАН ДА АЧЫК БУЛЫП КАЛА БИРӘ.

Бу – четерекле, вакытны һәм энергияне ала торган, синнән генә тормаган ялыктыргыч юл. Җитмәсә, бүген ул дәүләт дәрәҗәсендә элеккеге рельсларга куелмаган да. Ә менә русча язып, туган төбәге колоритын чагылдырган авторларның мөмкинлекләре күбрәк, укучыга барып җитү дә тизрәк.

Совет чорында без, Дагыстан дигәч, Рәсүл Гамзатовны күз алдына китерсәк, соңгы елларда исеме телдән төшмәгән Ислам Ханипаев пәйда булды. Хәзер күпләр өчен Дагыстан аның исеме белән тәңгәлләшәдер, мөгаен. Ханипаев очрагы – совет заманына охшаш, әмма заманча кире вертикаль: үзләрендә кадере асылда нәкъ менә Мәскәүдә китаплары басылып популярлашкач артты.

Исламның уңыш формуласы «Лицей» премиясе белән бәйле, аның финалисты һәм лауреаты булганнан соң, ул нәширләр өчен кызыклы объектка әверелә. «Таврида» арт-кластеры да үз ролен үти. Хәзер инде ул – «НОС», «Национальный бестселлер» финалисты, «Ясная поляна»ның укучылар тавыш бирүе буенча җиңүчесе. Мондый скилл илһамландыра, билгеле, әмма җигелеп эшләү белән фортунаны да бизмәннәрдән алып ташларга кирәкмидер.

– Авар телен яхшы беләм, тик әдәби дәрәҗәдә иркен сөйләшмим. Авылларда тел әле саклана, әмма шәһәр җирлегендә инде – бик сирәк. Хатыным да – авар, балалар тугач, туган телне сеңдереп тәрбияләргә сүз куештык, – ди Ислам. – Китапларым аша Дагыстанны дуамал бандитлар яши торган «дары мичкәсе» итеп кенә түгел, ә сәяси, иҗтимагый җирлектә хәйран негатив җыелган булса да, күпмилләтле төбәк, низаглы шартларда үзләрен саклап калырга, булдыра алганча яшәргә омтылган кешеләрнең туган бишеге буларак та күрсәтергә телим.

Китап базарында ышанычлы гарант вә гигант булган, үз авторларын, шул исәптән Ислам Ханипаевны танытуның бөтен механизмнарын куллана белгән «Альпина»да түгел, ә кечкенә генә «Перо» Мәскәү нәшриятында 3 000 тираж белән әсәрен бастырган Әминә Дамадаева белән дә гәпләшеп алдык. Ул да чыгышы буенча – авар. Әсәре тауларда тәрбияләнеп үскән авар кызы – Херай (кушаматы – «Херося») турында.

– Язучы булу турында башыма да китереп карамадым, әмма бу тарихны күбрәк кешегә сөйлисе, җиткерәсе килде, – ди Әминә Дамадаева. – Сурәтләрен махсус ясаттык, Диана Пирбудагованы таптык. Хәзер менә китапның үзен дә күбрәк кешегә таратасыбыз, таныштырасыбыз килә. Кызыклы тәҗрибә, билгеле, тик җиңел димәс идем, моңа үзеңне баштанаяк багышларга кирәк.

Мари язучысы һәм «төп әкиятчесе» Елена Юнысова.

– Очрашуларга телне белмәгән ата-аналар да балаларын еш алып килә. Әниләр белән әбиләр телен белдек, дип, куанып кайтып китәләр, – дип сөйләде ул безгә, борчулары белән дә бүлеште. – Шәһәр җирлегендә телне саклауның шушындый утраучыклары булу бик булыша, әмма инде районнар белән авылларда да тел бик зәгыйфьләнә...

Мари Элдан килгән икенче язучы – гомерен балалар тәрбияләүгә, мәгариф өлкәсенә багышлаган Анатолий Ишалин. Ул мәктәп директоры булып та эшләгән, Мари Эл Мәгариф министрлыгының Гомуми һәм мәктәпкә кадәр белем бирү идарәсенең әйдәп баручы эксперты һәм белгече дә булган, шигырьләр, проза һәм публицистика өлкәсендә иҗат та иткән.

– Милли республикаларда язучы ул, һичшиксез, мәгърифәтче, халыкны агартучы, шунсыз булмый, – дип елмая чыгышы белән Башкортстандагы марилардан булган Анатолий Сергеевич.

ӘБИ САНДЫГЫ, ТЕАТРАЛЬ ҺӘМ УРАМ ФОРМАТЛАРЫ, НЕЙРОЧЕЛТӘР, ХАЛЫКНЫ АГАРТУ

Россия халыклары әдәбиятын үстерү программасы кысаларында очрашулар һәр өч көндә дә каралган иде. Беренче көнне мари авторлары белән танышудан башладык. «Әби сандыгы»ннан милли костюмнар алып, этнографик элементлар, детальләрне кулланып, мари җырларын, әкиятләрен яңартып, уен һәм театр, остаханәләр рәвешендә эшләү тәҗрибәсе белән уртаклашты «төп мари әкиятчесе» Елена Юнысова. Алъяпкыч-сөлгеләрдәге мари чигешләрен сыйпап карый-карый, нинди сакраль мәгънәгә ия булуы турында белдек, йолаларны җырлап-уйнап-башкарып карадык.

РОССИЯДӘ, РУС ТЕЛЕННӘН ГАЙРЕ, КУЛЛАНЫЛЫШТА БУЛГАН 100 ДӘН АРТЫК МИЛЛИ ТЕЛ БАР, ШУЛАРНЫҢ 59 Ы – ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛ. ЯГЪНИ АЛАРДА ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘР ИҖАТ ИТЕЛӘ, КИТАПЛАР, ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАР БАСЫЛА, СПЕКТАКЛЬЛӘР КУЕЛА.

Шагыйрь, тәрҗемәче, әдәби тәнкыйтьче, БГН баш мөхәррире, Милли әдәбиятларны үстерү программасы кураторы Максим Амелин.

Күрше республикадан килгән коллегалар – шагыйрь һәм мөгаллим, З.Биишева исемендәге башкорт гимназиясе директоры Фәнил Бүләков, М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университеты доценты, Башкортостан Республикасы Корылтае – Дәүләт Советы депутаты Зәки Алибаев белән әдәби чараларда, түгәрәк өстәлләр, конференцияләрдә еш очрашабыз. Уртак төрки тамырлар һәм әдәбият турында да, бүгенге көндә язучыларны үстерү һәм телне саклау мәсьәләләре турында да еш фикер алышабыз. Монда да лекцияләр белән иҗади очрашулар кызыклы кайнар дискуссиягә әверелде – заманча театраль, урам форматлары турында да сөйләштек, флешмоблар, слэмнар, нейрочелтәр безгә нәрсә биргәне хакында да бәхәсләштек, проект идеяләре белән дә уртаклаштык.

Фестивальнең милли әдәбиятлар юнәлешенә йомгак ясап, Берләшкән гуманитар нәшриятның (БГН) баш мөхәррире, Россиядәге милли әдәбиятларны үстерү программасы кураторы, шагыйрь, тәрҗемәче, әдәби тәнкыйтьче Максим Амелин болай диде:

– Без туктаусыз үзгәреп торган сәяси-иҗтимагый шартларда яшибез, бу мәдәнияткә дә тәэсир итми калмый. Һәр халыкның, нәни генә этник төркемнең дә әдәбиятын

саклап калу, киң аудиториягә җиткерү, язма мирасын теркәп алу өчен тырышабыз. Кайчакта хәтта көрәшәбез дә. Һәр әдәбият – тулы бер яшәеш моделе, халыкның менталитеты, тарихи барышы. Бер генә тел югалса да, без коточкыч ярлыланабыз, нәрсәнедер бөтенләйгә югалтабыз.

Башкорт язучысы, публицист, әдәбият белгече, депутат Зәки Әлибаев.

АНТОЛОГИЯЛӘР ҺӘМ БҮЛӘКЛӘР МАРАФОНЫ

Берләшкән гуманитар нәшрият (БГН) ел да поэзия, проза, балалар әдәбияты, биография-мемуарлар, фәнни-популяр басмалар юнәлешендә дистәләгән китап чыгара. Ул Россиянең интеллектуаль әдәбият юнәлешендә әйдәп баручы нәшрияты дип танылган. Милли әдәбиятлар фестивален оештыра, авторлар белән очрашулар, лекцияләр, остаханәләр циклы эшли, шулай ук «Милли әдәбиятлар порталы»н алып бара.

Милли әдәбиятларны теркәү, саклау һәм киң аудиториягә җиткерү юнәлешендә БГН антологияләр нәшер итте. Бүгенге көндә алар – дүртәү: заман поэзиясе, прозасы, балалар әдәбияты һәм драматургиясе. Антологияләргә 50 милли телдән тәрҗемә ителгән авторлар һәм аларның әсәрләре кергән.

– Антологияләрне чыгарганда, һәр милли телдә иҗат итүче автор белән эшләүнең ничек икәнен беләбез. Бу – гаҗәеп катлаулы, озак вакытны һәм түземлекне таләп

Татар шагыйре, драматург, тәрҗемәче, әдәбият белгече Луиза Янсуар.

итә торган, энергияне ала торган эш. Әмма нәтиҗәсе моңа торырлык, – ди Максим Альбертович.

«Тарки-Тау»ның кульминациясе – бүләкләү. Быел Гран-прига чыгышы белән дагыстанлы балалар язучысы Наира Алидес әкиятләре сериясе өчен «Эпоха» нәшрияты лаек дип табылды. Ә иң ошаганы – балаларны кадерләүләре! Ел әйләнәсендә Махачкала һәм Дагыстанда эшләп килгән күргәзмәләргә нәтиҗә ясалды. «Балалар рәсеме» белән «Экологиягә багышланган плакатлар» бәйгеләрендә җиңгән балалар, яшүсмерләр лаеклы бүләкләрен һәм урыннарын алды.

Рәхмәт, «Тарки-Тау», яңадан очрашканчы!

Татар шагыйре, тәрҗемәче, Татарстан китап нәшрияты вәкиле Рифат Сәлах.

«ТАРКИ-ТАУ – 2024» ЯЛ КӨННӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛДЕ: ГАИЛӘЛӘР БЕЛӘН КИЛЕП, УРЫНДЫКЛАР КУЕП, ПЛЕДЛАР ҖӘЕП, ТЫҢЛАДЫ, УЕННАР УЙНАДЫ, ОСТАХАНӘЛӘРДӘ КАТНАШТЫ МАХАЧКАЛЫЛАР. ҺАВАСЫ БАЛЛЫ ЛИМОНАД КЕБЕК ИЗРӘП ТОРГАН КӨЗГЕ ШӘҺӘРНЕҢ КӘЕФЕНӘ БИК ТӘ ХУШ КИЛДЕК, ДИДЕЛӘР.

Фотолар: goodfon.ru, авторларның архивларыннан алынды

ШИГЪРИЯТНЕҢ МИЛЛИ АВАЗЛАРЫ

Луиза Янсуар

Милли әдәбият вәкилләре буларак, соңгы арада халыкара фестивальләрдә катнашкан кайбер язучыларның иҗатлары белән кыскача танышып, китапларына күз төшереп узыйк. Бүгенге киштәбездә – татар, башкорт җирлегендә яшәгән һәм иҗат иткән өч шагыйрьнең җыентыклары булыр.

КҮҢЕЛ БӨРТЕКЛӘРЕ

Рифат Сәлах

«Күңел бөртекләре», «Яшел ай», «Ташта үскән гөлләр», «Ак фәрештә» шигырь җыентыклары





Бүгенге татар яңа буын яшьләр шигърияте үзенчәлекле, төрле һәм бай. Аның нечкә лирика, гражданлык позициясе бөркеп торган шагыйрьләре дә, тирән фәлсәфә һәм формалар, жанрлар белән «уйнаучы» эксперимент тудыручылары да, Көнчыгыш белән Көнбатыш синтезын ясап, «яңа шигърият» булдырырга омтылучылары да бар.

Рифат Сәлах – бу плеядада үзенең самими дә, лирик-фәлсәфи дә хиссияте белән аерылып тора. Ул шагыйрьлекнең нәкъ менә традицион-милли чагылышы, дисәк тә була. Аның иҗаты үзенең табигый агышы, тавышы белән җәлеп итә һәм күңелдә кала.

«Күңел бөртекләре» дип исемләнгән беренче китабы Рифат Сәлах дигән шагыйрьнең яралып кына килүен күрсәтә, яшьлек, студентлык чоры иҗатын үз эченә ала. Бу гади дә, мөлаем дә, кайчак беркатлырак та тоелган җыентыктан яшьлекнең беренче омтылышлары, хыяллары, тойгылары бөркелеп тора. «Яшел ай» инде башка – аңарда җитлегү бар. Монда темалар, образлар тыгызлана, ачыклана төшә, шагыйрьнең үз кыйбласын, юнәлешен табуы, үзе өчен тәгаенләгән сукмактан атлап китүе сизелә.

«Ташта үскән гөлләр» белән «Ак фәрештә» җыентыклары Рифатның шигърияттә үз куышын, тирмәсен тапкан автор булуын раслый. Ул шунда үз мәгънәләре белән яши һәм үз эчке «мин»е, дөнья белән сөйләшә. «Ташта үскән гөлләр» Хаҗ сәфәренә барганда туган тойгылардан үрелгән, аның лирик каһарманы бүгенге җирлектә иман, дин һәм кешелекнең рухи кыйммәтләре турында уйлана.

1987 елның 8 июлендә Татарстанның Буа районы Яңа Чәчкап авылында туа. Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлый.

Мәктәптә укыганда ук әдәби иҗатка тартыла. 2004 елдан актив яза башлый. Университеттагы «Әллүки» түгәрәгенә йөри, 2007–2009 елларда аны үзе дә җитәкли. «Тәрәзә» татар студентлары газетасын чыгаруда актив катнаша.

Шигырьләре республика вакытлы матбугатында даими басылып килә, русчага тәрҗемә ителеп, антологияләргә һәм җыентыкларга керә. 4 шигырь җыентыгы, балалар өчен китап авторы. Татар теленә азәрбайҗан шагыйре Сона Вәлиеваны тәрҗемә итә, 2016 елда «Аразбары» китабы басылып та чыга.

Рифат Сәлах төрле елларда «Идел» яшьләр журналында, «Шәһри Казан», «Дарелфөнүн» газеталарында, Татарстан Язучылар берлегендә матбугат бүлегендә хезмәт куя. Хәзерге көндә «Татарстан китап нәшрияты»нда мөхәррир булып эшли.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты.

– ТАШТА ҮСКӘН ГӨЛЛӘР ОБРАЗЫ ХАҖДА ВАКЫТТА ТУДЫ. ТАУ-ТАШЛАРГА КАРАП, МОНДА НИНДИ ГӨЛЛӘР ҮСӘР ИДЕ ИКӘН ДИП УЙЛАНЫП БАРДЫМ. ШУЛВАКЫТ ВАК КЫНА, ЛӘКИН ДӨНЬЯНЫ ГҮЗӘЛЛЕККӘ ТӨРЕРДӘЙ КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛӘР КҮЗ АЛДЫМА КИЛДЕ. ИРЕКСЕЗДӘН АЛАРНЫ ТАШТА ҮСКӘН ГӨЛЛӘР ИТЕП КҮРДЕМ.
«ТАШТА ҮСКӘН ГӨЛЛӘР» – КҮҢЕЛЕМНЕҢ КӨНДӘЛЕГЕ УЛ. ҺӘРБЕР МИЗГЕЛЕМ НИНДИ БАР – ШУНДЫЙ. МИНЕ АҢЛАРГА ТЕЛӘГӘН КЕШЕ БУ КИТАПНЫ УКЫСА, ЯШЕРЕН СЕРЛӘРЕМНЕ ДӘ БЕЛЕР СЫМАН. АНДАГЫ ШИГЫРЬЛӘР ДӘ, СӘЯХӘТЛӘРЕМ ДӘ, МӘХӘББӘТЕМ ДӘ – АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ БҮЛӘГЕ.

Рифат Сәлах

«КИЕКЛЕГЕМ АРКАСЫНДА...»

Фәнил Бүләков

«Кыйбла эзләгәндә», «Торналарны офык чакыра» шигырь җыентыклары

Тугандаш әдәбиятлардагы каләм әһелләрен без гадәттә күзәтеп-укып-белеп барабыз, һәртөрле чараларда, әдәби җыеннарда очрашканда, үзара фикер алышабыз, бәхәсләшәбез, кайсыдыр нокталарда кисешәбез, фикердәшләр булып чыгабыз. Кыскасы, үзара энергия алмашы, иҗади процесс бара. Башкорт әдәбиятындагы язучылар, күршеләр белән – бигрәк тә.

Фәнил Бүләков 2009 елда киң катлам укучыга беренче шигырьләр җыентыгын тәкъдим итә, әдәбият мәйданына аяк баса. Тәүге китабы «Кыйбла эзләгәндә» дип атала. Башкорт әдәбиятының икенче бер вәкиле – галим, әдәбият белгече, тәнкыйтьче, 2016–2022 елларда Башкортостан Язучылар берлеге җитәкчесе Зәки Әлибаев аның турында болай дип яза: «Тәүге шигъри җыентыгы белән әдәбият мәйданына аяк басып, шагыйрь тормышта үз позициясе, яшәү һәм хезмәт максаты булган шәхес итеп күрсәтте». Ул Фәнил Бүләков лирикасында фәлсәфи, эпик башлангыч барлыгын ассызыклый, аның шигырьләренең хисси һәм форма ягыннан бөтенлеген, тәэсир итү көчен билгели.

«Торналарны офык чакыра» шигырьләр җыентыгы шагыйрьнең лирик каһарманын алдыбызга инде тормыштан кыйналып та, иркәләнеп тә, сыналып та сынау алган, шул эзләрне йөрәгендә саклаган, әмма киләчәккә барыбер өмет белән караган зат буларак китереп бастыра. Фәнил Бүләков гади генә, әмма тирән бер фикри куәт белән яза, аңарда ясалмалык, укучы белән уйнау, аны шаккаттыру өчен тырышу юк. Шуңа да ул беренче юлларыннан ук ышандыра – бу язмышны барлык зилзиләләр, тормыш борылыш-чатларында күзәтәсе, аның белән бергә тоясы, кичерәсе, кирәк була калса, яклыйсы, саклыйсы килә.

Бугазымнан алган чакта,
Тормыш-бүре кан сораган.
Киеклегем аркасында
Җаным бик еш каңгыраган.

Гомумән, ул «киеклек», табигать һәм аның стихиясе белән кушылганлык, бөтенлек башкорт әдипләре иҗатында, бигрәк тә шагыйрьләрдә аеруча җете, аермачык күренә. Сихерле һәм үзенә бөтереп ала торган борынгы көче бар бу бөтенлек-синтезның.

Фәнил Бүләков 1980 елның 5 июлендә Башкортостанның Учалы районы Имангол авылында туа. 1997–1998 елларда Имангол мәдәният йортында эшли. Башкорт дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый. Студент елларында Башкортостан дәүләт телерадиокомпаниясендә «Тамыр» студиясендә хезмәт юлын башлап җибәрә, «Тай-тулак» тапшыруын алып бара. Соңрак «Тамыр» телестудиясенең мөхәррире булып эшли. 2004–2006 елларда Мәскәүдә Телевидение һәм радио тапшырулары хезмәткәрләренең белемен камилләштерү институтында телерадиожурналистика белгечләре бүлегендә укый.

2008–2009 елларда Учалы районы «Яйык» газетасында хәбәрче булып эшли, ике ел Башкорт дәүләт университетында «Шоңкар» әдәби түгәрәген җитәкли. 2009 елда – «Яшьләр тавышы» сериясендә «Кыйбла эзләгәндә» дигән беренче шигырьләр җыентыгы, 2018 елда «Торналарны офык чакыра» китабы дөнья күрә.

2009 елдан – мәгариф һәм муниципаль хезмәт өлкәсендә: Имангол урта мәктәбе директоры, Имангол авыл хакимияте башлыгы, Имангол авыл советының 26, 27 нче чакырылышлары депутаты, Имангол мәктәбендә башкорт теле һәм әдәбияты укытучысы, Учалы башкорт корылтае җитәкчесе. 2021 елдан – Уфаның З. Биишева исемендәге 140 нчы башкорт гимназиясе директоры.

Башкортостан Язучылар берлеге әгъзасы, «Илһам чишмәләре» конкурсы Гран-при иясе, «Яшьлек» газетасының Рәйес Түләк конкурсы җиңүчесе, Чиләбе өлкәсе Сосновка районының Сәләм Галимов исемендәге премиясе лауреаты.

ТАШ ХАТЫН

Зөлфия Ханнанова

«Мин – башкорт, дип танышыгыз...», «Килен тәңкәсе», «Сәгать белән сөйләшәм», «Таш хатын» шигырь җыентыклары

Мин кем инде синең алларыңда,
Ә шулай да сының бик якын,
Чал гасырлар аша икебезне
Нидер бәйли кебек, Таш хатын!

Зөлфия Ханнанова исеме безнең татар әдәби мохитендә еш яңгырый, аның иҗатын да, матбугат, мәдәният, телләр һәм яшьләрне үстерү өлкәсендәге, хөкүмәт эшчәнлеген дә яхшы беләбез. Татар-башкорт әдәби багланышлары, халыкара фестиваль-очрашулар аннан башка күз алдына килми.

Иҗатының тагын бер югары баскычы буларак соңгы җыентыгын кабул итәргә буладыр – биредә Зөлфия Ханнанова үз чоры, милләте һәм әдәбияты вәкиле буларак кына түгел, ә гомумән тарихи-мәңгелек яссылыкка чыгып аваз сала. Аның лирик каһарманы дәверләр-чорлар белән бәйләнеше турында да сөйли, үзенең нәкъ менә монда, туган тиягендә басып торып, ыруы белән туфрагы сагында булуын да раслый.

Китап ике телдә нәшер ителгән – башкортча һәм русча. Тәрҗемәләрне эшләгән Сергей Янаки аның иҗаты турында болай ди: «Зөлфиянең китабы, иҗаты – дөньяга бүген җитеп бетмәгән гармонияне кайтара, дияр идем. Ул әхлакый кыйммәтләр сагында тора, аларны безгә дә тапшыра».

Милли әдәбиятларның үз тарихи барышын һәм язмышын күздән кичерүе, киләчәге турында уйланулары – безнең барыбыз өчен дә уртак. Һәм бу турыдан-туры тел, бездән соң каласы буыннарның кая юл алуы турында хафалану белән бәйләнеп китә. Кайсы гына милли шагыйрь-язучыны алма, очрашулар, фикер алышулар вакытында без, иң беренче чиратта, бүгенге глобализация шартларында телнең йотыла баруы, милләтебезнең ассимиляция кичерүе хакында сөйләшәбез. Әсәрләрдә бу, билгеле, иң тирән чагылыш алган җан авазы булып яңгырый.

Зөлфия Ханнанова Башкортостанның Дыуан районы Иске Хәлил авылында туа. 1991 елда Башкорт дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый, Белорет районы мәктәпләрендә балалар укыта. Уфага күчеп, «Шоңкар» журналында бүлек мөдире, Уфа каласы Киров районы һәм Уфа шәһәре хакимиятендә, Башкортостан Республикасы Хөкүмәтендә 18 ел җитәкче вазыйфаларында эшли.

Бүгенге көндә «Ватандаш» журналында әдәбият бүлеген җитәкли. Россия ислам университетын тәмамлый. Ул шулай ук башкорт телендә чыккан «Әс-Сәлам» газетасының мөхәррире дә.

Башкортостан һәм Россия Язучылар, Журналистлар берлеге, Беларусь Язучылар берлеге әгъзасы.

Башкортостан Республикасының Ш.Бабич исемендәге яшьләр премиясе лауреаты, Башкортостан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.

– ЯҢА КИТАБЫМДА БЕР СОРАУГА ҖАВАП ЭЗЛИМ: КЕМ УЛ – ТАШ ХАТЫН? ТАШ – БАШКОРТ ӘДӘБИЯТЫНДА, ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА ЕШ ОЧРЫЙ ТОРГАН ОБРАЗ. УЛ – БАШКОРТ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНЫҢ РУХИ НЫКЛЫГЫ, ЧЫДАМЛЫГЫ СИМВОЛЫ. ХАЛКЫБЫЗ ҖЫРЛАРЫНДА ДА БИТ: «ТАРИХ ЯЗАР ИДЕМ ТАШЫНА...» –ДИП ӘЙТКӘН. ТАШЛАР БИК КҮП МӘГЪЛҮМАТНЫ САКЛЫЙ. ШУНЫҢ ИШЕ, ТАШТАЙ НЫК БУЛГАН ХАТЫН-КЫЗЛАР ДА – МИЛЛӘТНЕҢ ГЕНЕТИК ХӘТЕРЕ САГЫНДА ТОРУЧЫЛАР. НИНДИ ГЕНӘ СЫНАУЛАР КИЛМӘСЕН, АЛАР ЯШӘҮНЕ ДӘВАМ ИТКӘН. «ТАШ ХАТЫН» ТОРАТАШ СЫНЫ БЕЗНЕҢ ТАРИХ, ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ИНСТИТУТЫ ФОЙЕСЫНДА ТОРА. ЕШ КЫНА АНЫҢ ЯНЫНА ТУКТАЛАМ ҺӘМ УЙЛАНАМ.

Зөлфия Ханнанова

ТАКТАШ ХРОНИКАСЫ



XX гасыр башында культ дәрәҗәсендә кабул ителгән, исән чагында ук тере мифка әверелгән Такташ бүген дә үзенең серлелеген һәм куәтен җуймый. Киресенчә, еллар узган саен әллә без – аңа, әллә ул безгә якыная гына шикелле.

Кечкенә Һади 1901 елның 1 гыйнварында элеккеге Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордва Республикасы Тарбеево районы) Сыркыды авылында дөньяга килә.

Әтисе Хәйрулла абзый тарлыкта, авыр шартларда үсә, әмма тора-бара үз хуҗалыгын ныгыта. Балаларын какмый-сукмый, укый-яза белгән кеше буларак, аларга белем бирергә омтыла.

Әнисе Шәмсениса Аганина – Һадига иң зур йогынты ясаган кеше. «*Әнием ике сеңеле һәм бер абыйсы белән яшьли ятим калган. Өчесе дә укый-яза белгән. Ул вакытта Сыркыдыда укый-яза белүче хатын-кызлар бишәү генә булган. Болар кешедә ачлы-туклы урак урып, кышын балалар укытып, читтә йөргән кешеләргә хатлар язып, укып көн күргән. Бөтен сер аларда булган. Авылдагы фаҗигале вакыйгаларга җырлар чыгаручы өч сеңел саналганнар*». (Такташ истәлекләреннән.)

Балага башта «Мөхәммәтҗан» кушалар. Мишәрләр, аны бозып, «Мокамай» дип йөртә торган була. Ахыр чиктә, исемен «Мөхәммәтһади» дип үзгәртәләр. «*Һади тугыз айда тәпи йөрде, ике-ике яшь ярымда чиста итеп сөйли белә башлады. Басынкы, еламый, кайда ятса – шунда йоклый, кунакны аңлап, аны сыйларга ярата, табында кунакка тәлинкәләр куя иде. Яраткан эшләреннән берсе – каз бәбкәләрен карау. Бервакытны ике каз бәбкәсен куенына алып йоклаган, иртә белән торса, бәбкәләр изелеп үлгәннәр. Йөрәге әрнеп, үбеп-үбеп елады да кабер казып күмде. Бүтән хайваннарны да ярата, атлар, сыерларның күзләрен үбә, йоннарын тарый, сыйлый-сыйпый*». (Әнисе истәлекләреннән.)

Мокамай исемле дусты, батрак малае турында 7 яшьтә шигырь яза. Үсеп буй җиткәч, Мокамайны авылда, тәгәрмәч урлауда гаепләп, бик каты кыйнап, караңгы базга ябалар. Ул, хурлыкка чыдый алмыйча, үзен пәкесе белән суеп үтерә. Бу хәбәрне Такташ бик авыр кичерә. «Мокамай» поэмасын сәхнәдән искиткеч тәэсирле итеп укый торган була. Тыңлаучылар, елый-елый, Такташны туктата: «Тукта, зинһар, Һади абый, үзәкне өзәсең...»

Авыл мәдрәсәсенә йөри башлый. Сыркыды муллаларының укытуы аны да, әти-әнисен дә канәгатьләндерми. Малайны 30 чакрым ераклыктагы Пешлә мәдрәсәсенә җибәрәләр. Анда алдынгы фикерле мөгаллимнәр эшли, шәкертләр саны 500 гә җитә. «*Пешлә дәвере безнең өчен бик алмашыну дәвере. Аңар 1913 елда укытырга килгән Кәрим Буреев дигән мөгаллим сәбәп булды. Ул бер атна кичендә, бар шәкертләрне җыеп, Тукай шигырьләрен укыды. Икенче көнне барыбыз да шигырь яза башладык. Билгеле, Һади ул нәрсәгә җаны-тәне белән күмелде. Язган нәрсәләрен шәкертләр бик яратып укый иде. Кайчакта Кәрим абый, шәкертләрне җыеп, аның язганнарын үзе укый*». (Кардәше һәм яшьлек дусты Низам Арсланов истәлекләреннән.)

Матбугат белән дә шунда таныша – мөгаллимнәр «Тәрҗеман», «Вакыт», «Йолдыз», «Ялт-йолт» басмаларын алдыра, шул чор язучыларының яңа әсәрләре укып бара.

Беренче бөтендөнья сугышы башланганны бик нык хәтерендә калдыра. Туганы Ибрай икенче чакыруга әләгә, моңарчы тәмәке тотмаган агасының, тартып, «өч бала белән

Һади Такташ туганнан туган абыйлары Мифтах һәм Низам белән.

Фотолар: ТР Милли музее фондларыннан

йортны хатын кешегә калдырып кит... балалар да ачтан үләрләр, йорт та таралыр...» дип, уф-танып утырганын искә ала.

Китапханә хуҗасы. Мәдрәсә тәмамлагач, бер елын авылда уздыра, мөгаллиме Нуркиннан тел, тарих, география, хисап, табигать фәннәре турында фәнни китаплар ала. «Ул минем китапханәмнең икенче хуҗасы булып китте», – дип язып калдыра остазы. Сеңлесе Хәнифә болай ди: «Китап сатып алыр өчен, эни Һади абыйга үзенең чәченә үреп йөри торган тәңкәләрен берәм-берәм бирә торган иде».

Урта Азия. 1915 елда Хәйрулла абзый Һадины, кардәш байга ияртеп, Урта Азиягә озата. «*Хезмәткә китүдән мин күз алдыма ике максат тоттым: 1) авыл мәктәбендә башлаган белемемне дәвам иттерү; 2) әти-әниләремә акча белән ярдәм күрсәтү*» (Такташ автобиографиясеннән). Әмма кибеттә йомышчы малай булып эшләүдән кергән акча үзен тәэмин итәргә дә такы-токы гына җитә. Бай кардәшләре аны укытырга уйламый да. Һади Яңа Бохарадагы мануфактура кибетенә өйрәнчек булып керә, аннан приказчик хезмәтенә күчә. Тик сәүдә өлкәсенә йөрәге ятмый. Алдынгы яшьләр, мөгаллимнәр белән дуслашып китә, культура эшләрендә катнаша. Спектакльләр куялар. Һади әйбәт оештыручы булып таныла, артист булып та уйнап йөри. Җәмгыятьнең хәйрия акчалары өчен җаваплы исәпләнә.

«Төркестан сахраларында» – матбугатта чыкккан беренче шигыре, 1918 елның 21 гыйнвары санында. Ташкентта чыга торган «Олуг Төркестан» газетасына хәбәрләр дә яза.

Фетнә. Оешма әгъзалары төрки халыклар өчен бердәй белем бирү системасын төзергә хыяллана. Иске тип мәдрәсәләр тотуны һәм рухани белем бирүне тәнкыйтьләп, әмиргә мөрәҗәгать итәләр. «Фетнә» кискен бастырыла: эзәрлекләүләр, кулга алулар башлана. «1917 *елгы февраль переворотын мин хуҗаларым тарафыннан урамга чыгарып ташланган хәлдә, эшсезлектә каршыладым. 16 яшьлек үсмер булганым хәлдә, Бохара әмирен төшерүне үзенең максаты итеп куйган политик оешманың эшендә катнаштым*». (Такташ автобиографиясеннән).

Россиягә кайткач, яңа хакимиятнең ничек урнаша башлавын үз күзләре белән күрә. Чит җирләрнең ачысын-төчесен татып кайткан үсмер егеткә ихтирам арта. Аны авыл китапханәсенә мөдир итеп билгеләп куялар, мәктәп советы әгъзасы итеп сайлыйлар.

Мөгаллим. 1918–1919 елларда Спас шәһәрендә укытучылар курсында укый, аны авыл мөгаллим итеп билгелиләр. Беренче классларны укыта, балалар сабакка күңел биреп, бер дә калдырмый йөри, аны ярата. Әмма авылда Такташның активлыгын өнәмәүчеләр дә була, үзен дә инде Сыркыды гына канәгатьләндерми башлый.

Оренбург. 1919 елның көзендә Такташ Оренбургка юл ала, РКП (б) ның Оренбург губерна комитеты органы булган «Юксыллар сүзе» газетасы редакциясенә эшкә керә. «*Газета идарәсендә икебездән башка кеше юк. Авыллардан килгән хәбәрләрне Такташ җентекләп эшли, кайчакларда үзе дә барып кайта иде*». (Афзал Таһиров истәлекләреннән.)

«Кабил белән Һабил». 1920 ел башында Такташ газетаның редколлегия әгъзасы һәм секретаре итеп билгеләнә. Җәен ул татарлар һәм башкортлар өчен ачылган политсовет курсларында укый. Афзал Таһиров 1920 елның көзендә Такташның «Кабил белән Һабил» дигән шигырен алып килеп, квартирасында укыганын искә ала.

«Күк сөргеннәре». «*1920 елның июль аенда ертылай гаскәри киенгән зәңгәр күзле, озын сары чәчләрен артка тараган берәү килеп, шагыйрь булуы, кульъязмаларын «Хөр яшьләр» газетасына бастырырга теләве турында сөйләде. Бу кеше Һади Такташ иде. «Күк сөргеннәре» исемендәге шигырен калдырды. Бөтен Россия Шәрык коммунист яшьләренең конференция делегатлары кичәсендә укыдым. Тыңлаучылар кемнең әсәре булуын сорады. «Оренбургта шундый көчле шигырь яза белүче дә бар икән», – дип әйтүчеләр булды*» (Мөхәммәтша Мамин истәлекләреннән.)

Ташкент. Идел-Җаек буйларында каты ачлык башлангач, 1921 ел башында Ташкентка күчә. «Газраиллләр», «Караңгы төннәрдә» инде 1916 елда Бохарада ук язылган була. Ташкент чорында программ әсәрләре булып таныла-чак «Таң кызы», «Онытылган ант», «Урман кызы», «Күләгәләр», «Нәләт», «Җир уллары трагедиясе»н иҗат итә. Әдәби-музыкаль кичәләрдә актив катнаша, газета-журнал редакцияләре тирәсендә еш кунак була.

«Мәңгелек әйберләр». «*1921 елның кызу җәе. Яланбаш, яланаяк бер егет бархыт тавышы белән: «Минем поэмам бар иде, шуңа отзыв бирмәссезме», – дип, үзенең Һади Такташ булуын, 1918 елдан бирле шигырь язуын сөйләде. Поэмасының исеме «Һабил»ме, «Кабил»ме, ләкин фәрештәләр белән эш кылуга, Тәүрат*

Һади Такташ Ташкентта.

Такташның әнисе Шәмсениса.



Такташның әтисе Хәйрулла.

Һади Такташ беренче хатыны Гөлчирә Хәмзина һәм уллары Рафаил белән.

Һади Такташның икенче хатыны Гөлчирә Такташева-Мансурова.

каһарманнарының берсе икәне исемдә. «Нигә соң, – дим, – газазилләр, газраилләр белән маташасыз, җирдә кешеләр беткәнмени?» Тузган башлы дәрвишсыман егет: «Мине мәңгелек әйберләр, бөек проблемалар кызыксындыра», – диде». (Фатих Сәйфи истәлекләреннән.)

Мәскәү. Төркестан эшче-дехкан коммунистлар университетында ана теле укыта. Үзәк Комитет күрсәтмәсе буенча Ташкентта кыска сроклы сәяси әзерлек курслары ачыла. Яшьләр Көнчыгыш хезмәт ияләренең Мәскәүдәге коммунистик университетына керергә әзерләнә. 1922 елның июлендә Такташ та алар белән Мәскәүгә китә. Маяковский, Есенин һ.б. шагыйрьләрнең чыгышларын, лекцияләрен тыңлый, завод-фабрикаларга йөреп, эшчеләр тормышын өйрәнә.

Казан. 1922 елның ноябрендә Казанга килеп төшә. Язучылар һәм артистлар белән таныша, «Җир уллары трагедиясе» әсәренең соңгы вариантын әдипләр белән нәшрият хөкеменә тапшыра. *«Выписка из протокола Заседания Редакционной Коллегии Акадцентра ТНКП от 22 ноября 1922 г. Слушали: Ф. Бурнаш читает письменный отзыв-рецензию группы татар-ских литераторов о трагедии в стихах поэта Такташева «Джир уллары». В своей рецензии они указывают, что трагедия является в татарской литературе шагом – новым по широте и глубине затронутой темы, в революционности по его разработке. Поэтому она должна быть издана и распространена сейчас же. Постановили: направить трагедию Такташева «Джир уллары» в Татгосиздат для печати».*

Суфлёр. Татар дәүләт Академия театрына суфлёр булып эшкә урнаша, 1923 елда «Чаян» журналының секретаре булып китә, 1924–1925 елларда – «Октябрь яшьләре», 1926 елда – «Авыл яшьләре», 1926–1929 елларда «Азат хатын» басмаларында эшли. 1929 елда кабат «Чаян»га әйләнеп кайта һәм соңгы көннәренә кадәр шунда җаваплы секретарь булып хезмәт куя.

Өч дус (сулдан уңга): Габдрахман Минский, Һади Такташ, Гадел Кутуй.

«Басарга, ләкин дәүләт нәшрияты хисабына түгел» дип, резолюция салына җыентыкка. Бу асылда «басмаска» дигән сүз. Такташ «Корылтай» дигән хосусый нәшриятка мөрәҗәгать итә, җыентыгын «сатылса, акчасын түләрбез» дигән шарт белән кыскартып чыгаралар. Китапка реакция бик көчле була: берәүләр аны күккә чөеп мактый, берәүләр тәнкыйть утына тота.

«Җир уллары трагедиясе» 1923 елның 12 апрелендә Татар дәүләт Академия театрында Кәрим Тинчурин тарафыннан куела. *«Вакыйгалар композитор С. Габәши җитәкчелегендәге көчле хор чыгышы белән аралаша. Төп рольләрдә театрның күренекле артистлары М. Әпсәләмов (Адәм), Ә. Мәҗитов (Кабил), М. Вәлишин (Һабил), Г. Болгарская (Әкълимә) Х. Колмәмәт (Җәбраил) уйный. Спектакльгә рух бирүче, аның оптимистик яңгырашын тәэмин итүче Идея-Газазил образын Такташ үзе башкара».* (Һәнүз Мәхмүтов язмаларыннан.)

«Такташ үлде». 1923 елның 30 ноябрендә әдәбият түгәрәгендә «Такташ үлде» шигырен укый. Җыелыш рәисе Такташны «символист Такташ» дип тәкъдим иткәч, шагыйрь үзе моңа каршы: *«Мин сезгә символизм буенча язылмаган нәрсә укыйм. Аны школаларга аеру минем эшем түгел, бәлки әдәбият тикшерүчеләр эше», – ди һәм, шаярып: «Мин такташист кына», – дип өсти* (Хәсән Хәйри китабыннан.)

«Гасырлар һәм минутлар» Ленин үлгәч үк иҗат ителә. Такташ аны Татар педагогика техникумының утырышлар залында Ленин үлүгә багышланган кичәдә тынсыз калган тамашачы каршында оста итеп укый.

«Сулф» уздырган әдәби диспутта футурист Ризванов Такташ иҗатын сызып ташлап, әдәбиятта алга таба эшләргә мөмкинлек бирмәү фикерен алга сөрә. «Футуристлар гына революция шагыйрьләре булып калырга тиеш», – ди. Әмма аудитория шагыйрьне яклап чыга, диспутның интрига өчен эшләнгәне исбатлана. *«Фикерләрнең күпчелеге Такташның пролетариат идеологиясенә якынлаша баруын, бу көнге эшче-крестьяннар тормышыннан тирән мәгънәле, инкыйлаби әсәрләр бирә башлавын исбат иттеләр».* («Кызыл Татарстан», 19 апрель, 1924 ел.)

Эйнштейн теориясе һәм Лобачевский геометриясе. *«Бервакыт Такташ Казан университетының химия лабораториясенә мине эзләп килде. Эйнштейнның чагыштырмалылык теориясе белән Лобачевскийның евклидча булмаган геометриясе турында сораштыра башлады. Университетта «Дөньяның ахыры бармы?» дигән лекция тыңлаган икән, кызганычка каршы, аның кайбер моментларын аңламаган...».* (Химия фәннәре докторы, профессор Г. Камай, «Совет әдәбияты» журналы, 1951 ел.)

«Давылдан соң» әсәрен 1924 елның ноябрендә яза. «Сез тикшереп укысагыз, минем неореализмга күчүемне «Давылдан соң» әсәремнән бик яхшы күрерсез», – ди. Ул вакытта әле «социалистик реализм» термины әдәби тәнкыйтькә кереп китмәгән булганлыктан, яңа төр иҗатны шартлы рәвештә «неореализм» дип йөрткәннәр.

«Сыркыды авылы» әсәрен 1924 елның декабрендә яза. Шәхми бабай – реаль кеше, 1918–1923 елларда авыл советында каравылчы булып эшли, 1924 елда үлә. Такташ аның янына барып, төннәр буе сөйләшеп утырырга ярата.

«Октябрь яшьләре» журналының 1925 елдагы 6–7 нче санында «Эшче-крестьян яшьләре әдәбияты» мәкаләсен бастыра: *«Татар шагыйрьләре (баштанаяк һәммәсе) быттан ерак. Аларның җансыз шигырьләрендә күренмәгән быт авыл җырларында дөресрәк күренә һәм алар хәзерге шагыйрьләрнең массадан ерак, бүлмә хыялы белән язылган шигырьләреннән яратыла төшеп укыла»*.

«Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасын 1927 елның февралендә тәмамлый. «Гажур» нәшрияты аны аерым китап итеп бастырып чыгара. Әсәр искиткеч зур популярлык казана, кулдан-кулга йөреп укыла.

«Караборынның дусты» Мәскәүдә аерым китап булып 1927 елның августында басылып чыга.

«Күмелгән кораллар» драмасы Татар дәүләт Академия театрында, Октябрь революциясенең 10 еллык юбилеен каршылап, 1927 елның 4 ноябрендә куела.

«Үтеп барышлый» шигырен Әстерханга иҗат командировкасына барганда, Рузаевка станциясе аша узгач, 1918 елның июнендә яза. Габдрахман Минский белән әдәбият кичәләре уздыралар. Эшчеләр, иртәдән кичкә кадәр кассага чират торып, билет алалар, очрашуларга агылалар. Такташның моңа бик тә рухы күтәрелә.

Казанга пароходта Горький килә. Августның матур көннәрендә аны каршыларга төшүчеләр арасында Такташ та була. «*Язучыларның һәм матбугат работникларының Горький белән очрашуларына аерым кичә багышланды. Мәрхүм Такташ белән мин «Казан» гостиницасына Горький янына бардык һәм, җыелыштан соң, Островский-Бауман урамнары ерып булмаслык халык белән тулганга күрә, Горькийны караңгы тыкрыклар буенча яңадан номерга озаттык*». (Г.Кутуй, «Кызыл Татарстан», 18 июнь, 1941 ел.)

«Югалган матурлык» Татар дәүләт Академия театрында 1929 елның гыйнварында куела. Киң җәмәгатьчелектә зур шау-шу, бәхәс кузгата.

«Мокамай» һәм «Алсу» поэмаларын тәмамлый. «Безнең юл» журналының 2 нче санында басыла.

«Азат хатын» редакциясеннән эштән чыга. 1929 елның 15 марты була бу. «*Газета-журнал редакциясе өчен аерым бүлмәләр юк иде, икебезгә бер өстәл. Штатта фотограф та, машинистка да, рәссам да юк. Типография ерак. Җәяү чабабыз, акча булганда, «барабыз» ала идек... Ул мине журнал өчен ничек материал алырга, килгән материалларны ничек төзәтергә өйрәтте*». (Гөлчирә Гафурова, «Такташ турында истәлекләр».)

Бер төркем татар пролетар язучылары.

Татар пролетариат язучылары ассоциациясе, татар язучылары җәмгыяте әгъзалары һәм сәнгать көчләре 1929 елның 10 августында СССРның көнчыгыш, көньяк республикаларына сәяхәткә чыга. Экскурсия маршруты: Казан – Әстерхан – Махачкала – Баку – Тблиси – Сухуми – Коджари – Симферополь – Ялта – Харьков – Мәскәү – Казан. 18 кешелек экскурсия 10 августта 13:00 сәгатьтә «Год революции» пароходы белән Казаннан кузгалып китә. 18 сентябрьдә Казанга кайтып төшә.

«Комсомольская правда» газетасында 1930 елның 4 гыйнварында И. Бороздинның «Татарская литература» мәкаләсе басылып чыга: *«Такташ также прошёл романтику, но за последнее время он обрёл свежие жизненные бытовые моменты. «Такташ, говорит о нём в своей статье Кутуй, поэт «мелочей», он из мелочей умеет создавать крупное и ценное. Одна из положительных заслуг Такташа в современной татарской литературе – это его богатый язык. В этом отношении он талантливее остальных». Такташ пользуется большой популярностью среди татарской молодёжи»*.

«Камил» киносценариен 20 марттан да соңламыйча язып тапшыру турында «Востоккино» белән килешү төзи.

Маяковскийның фаҗигале үлеме. Такташ аңа «Чигенү» шигырен багышлый: «Ах, Володя, бәгърем, бик ялгыштың...»

«Татар мәдәнияте йорты»нда 1930 елның маенда Кутуй һәм Такташ кичәсе ясала.

ИМЕШ-МИМЕШЛӘР

1. **Такташ белән Кутуй бик дус була**, бер-берсенә «канатым», «йөрәк маем» дип эндәшә. «Җидегәнчелек» дуслыкларын какшата. Такташка «Кутуй өстеңнән әйтте», дип ишеттерәләр. Кутуй Такташны халык яратудан көнләшкән, дип фаразлаучы галимнәр бар. Моны бернинди фактлар да расламый, киресенчә, Кутуй күпчелек язмаларында Такташка мөнәсәбәтле бик җылы сүзләр әйтә. Тагын бер версия – имеш, Кутуй, Гөлчирә Хәмзинаны ошатып йөреп, Такташның өйләнүен кичерә алмаган. Әмма Кутуй Галимәгә өйләнгәч, көн дә диярлек аларның өйләренә кунак булып нәкъ менә Такташ килеп йөри, аңа Кутуйларның ишеге гел ачык була. Күрәсең, бу икәүнең арасына кара елан җибәреп, кемнәрдер үз дигәненә ирешә. Алар исәндә аңлашырга өлгерми. Кутуй Такташны җирләү процессиясенә ияреп зиратка кадәр бара, аны табутка да, кабергә дә якын китермиләр.

2. **Такташка аталар**, әмма ул исән кала. Кемнең заказы булганын, хәтта бу хәлнең чынлыгын раслый торган документлар, фактлар да теркәлеп калмаган. Такташ атучының да, заказчының да кем икәнен белгән, шуңа шау-шу кубармаган, диләр. Пуляны да үзендә саклап тоткан, янәсе.

3. **Такташка – дело?** Такташ үлеменнән соң, имеш, НКВД кешесе Гөлчирә Мансурова-Такташевага әйтә: «Ник елыйсың, елама, аңа инде дело ачылган иде, ә болай – кабере кайда икәнен беләсең».

4. **Такташ үзенә кул салган.** Моны да раслый торган бернинди факт та юк. Икенче гаиләсендә җан тынычлыгы тапкан һәм алда бик күп эшләре көтеп торган шагыйрьнең бу адымны ясавы, ни генә дисәң дә, сәер булыр иде.

Такташ Донбасска бара. 1930 елның июнендә эшчеләр һәм пролетариат вәкилләре белән очраша. Кайткач, бу хакта тирән хисләр белән сөйли: «Бик күпне күрдем. Донбасс, аның алдынгы шахтёрлары онытылмаслык дуслык эзләре калдырды. Бүләк тә бирделәр: шахтёр лампасы».

«Камил» пьесасы 1931 елның 3 гыйнварында Татар дәүләт Академия театрында куела. Музыка – Сәйдәшевнеке. Зур уңыш белән бара.

Иҗат отчёты белән театр бинасында 1931 елның гыйнварында чыгыш ясый. Кичә кызып барган мәлдә кинәт ут сүнә. Зал белән сәхнә караңгылыкта кала. Такташ укуыннан туктый. Шунда ук залдан: «Такташ, укы!» һәм «Һади, дәвам ит!» дип кычкырган тавышлар ишетелә. Такташ яттан укуын дәвам итә.

«Үзем турында» мәкаләсе басылып чыга: *«Хәзерге вакытта мин «Киләчәккә хатлар» әсәре өстендә эшлим. Аларда мин киләчәк буыннарга безнең яңа тормыш өчен, яңа кеше өчен алып барган героик көрәшебезне тасвирларга тырышам».* («Кызыл Татарстан» газетасыннан).

«Камил» сценарие мәсьәләсе буенча октябрьдә Мәскәүгә бара.

Тимгелле тиф белән авырый башлый. 1931 елның ноябрендә Такташны дәвалау буенча ТАПП һәм «Кызыл Татарстан» конкрет чаралар күрә. Профессор Терегулов, профессор Ворошилов, доцент Вилинскийлар берничә консилиум җыя. Әмма хәле көннән-көн начарая, соңрак профессорлар авыруының үзгеми шешүгә әйләнгәнен белдерәләр.

8 декабрь 1931. Иртән сәгать алтынчы яртыда Кооператив урамы, 41 нче йорт адресында урнашкан фатирында Һади Такташ вафат була. Көндезге 3 сәгать 30 минутта гәүдәсе анатомия больницасына күчерелә, 4 сәгать 21 минутта Мәгариф Союзының Ак залына урнаштырыла.

9 декабрь, 1931. Такташ гәүдәсе янында язучылар, артистлар, студентлар һәм эшчеләрдән почётлы каравыл тора. Татар симфония оркестры, Татар-башкорт сугыш мәктәбе кыллы оркестры матәм маршы уйный. Хушлашырга килүчеләрнең саны ун меңнән артып китә. Такташны күмү өчен Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты секретариаты комиссия төзи.

10 декабрь, 1931. Көндезге бердә гәүдәсе чыгарыла. Табутны Бауман, Кооператив урамнары буйлап Ирек мәйданына күтәреп баралар. Хөкүмәт комиссиясеннән Хәйруллин митинг ача, Салихов, Корбангалиев, ТАППтан З. Гали, Кызыл Армиядән Чанышев, Татпромсоветтан Х. Садри, «Красная Татария»дән Вульфсон сөйли. Аннан гәүдәсе Карл Маркс урамы буйлап туганнар каберлегенә озатыла. Г. Гали, К. Нәҗми, Ф. Сәйфи, Ф. Мөсәгыйть, Такташның туганнары нотык тота. Кабергә иңдергәндә, Чанышев командасы мылтыклардан салют бирә.

100 000 СУМ

һәм башка бүләкләр

Бүләкләрне уйнату 2025 елның 6 февралендә узачак.

Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru сайтында белә аласыз.

Акция 2024 елның 15 октябреннән 2025 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 26.01.2025 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин

ТАТ МЕДИА

РЕКЛАМА

Зәй районы Карман авылында туып үскән. Бигеш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт педагогика институтының чит телләр факультетында белем ала. Яр Чаллы телерадиокомпаниясендә, «Другая сторона» газетасында хәбәрче һ.б. эшләрдә хезмәт куя.

Әдәби иҗат белән бала чактан мавыга. Шигырьләр, хикәяләр яза. 2024 елда «Әй син, гомер!» һәм «Балачак иле» дип аталган ике шигырьләр җыентыгы дөнья күрде.

Бүген укучыларыбызга авторның «Язмышлар ярында» хикәясен тәкъдим итәбез.

Фирдәүсә Бикмәтова

ЯЗМЫШЛАР ЯРЫНДА

Әллә нидән сискәнеп уянып китте ул. Карашы чәчрәп торган караңгылыкка терәлгәч, үзенең зират коймасына сөялеп йоклап киткәнен исенә төшерде Кәримә. Йөрәге күкрәк читлеген ярып чыгардай булып тибәргә тотынды, сулышы капты, телен әйләндереп, төкерек йотарлык хәле дә калмаган кебек тоелды аңа. Кабаланып, кыр читендә ялгыз янган утны эзли башлады хатын. «Ярый бу якка әйләнеп чыгарга өлгермәгән икән, минем черем итеп алуым гына булган икән бит бу», – дип, өстенә салган юка бишмәтен рәтләп куйды, башындагы чуклы яулыгын җайлап бәйләде. Әле ныклап җылынып та өлгермәгән язгы җирдә утырып, гәүдәсенә салкын йөгергән иде аның. Аякларын язгалады, кулларын угалап, әледән-әле җылы сулышын өргәләде. Җитмәсә калынрак өс-баш юнәтә торган да түгел, ачлы-туклы, хәсрәтле замана шул. Җылынырга теләпме, үзен-үзе кулга аласы килепме, зират коймасына аркасы белән ныграк сыенды да язгы кыр өстенә текәлде.

Әй, язмыш... Ир куенында кинәнеп яши дә алмый калды шул... Алыптай зур гәүдәле, зәңгәр күзле, бар кеше белән дә тыныч мөгамәләдә иде Мансуры. Елмаеп җибәрсә, күзләре дә кушылып көлә иде аның. Авыр сүз әйтмәде, какмады-сукмады. Алай да беренче күргәч, яратмаган иде аны Кәримә. Кайдан яратасың, ди, инде. Үз алдына елмаеп куйды хатын. Абыйлары күрше авылга кияүгә биреп җибәргәндә бик яшь, әле яңа 20 сен генә тутырган иде. Газиз әти-әнисе кочагында тагын бераз иркәләнеп яшәп каласы килгән иде дә бит. Шул яшенә җитеп, яшьләр арасына бик чыгып йөрмәде. Егетләр белән үзе алдан сүз катып сөйләшү турында сүз дә юк инде анысы. Күбрәк кырыс абыйлары тәрбиясендә үскән кыз сабыр холыклы, оялчан, итагатьле һәм күндәм иде. Гөл чәчәгеннән күренә, дигәндәй, төс-кыяфәте әнисенеке кебек, килеш-килбәте ир-ат күңеленә хуш килерлек. Гәүдәгә әллә ни зур булмаса да, аяклары озын, биле нәзек, килештереп кигән гади күлмәгеннән калку күкрәкләре күңелне җилкендереп торырлык.

Тыныч кышкы төн. Авыл йоклый. Иренеп, теләр-теләмәс кенә төшкән кар бөртекләре Кәримәләр капка төбендәге чана җигелгән җирән атның пар күтәрелеп торган аркасына тияргә дә өлгерми эри тора. Җигүле ат, кузгалырга әмер көтеп торгандай, әледән-әле аякларын алыштыргалап куя. Хуҗасы кызуланып кереп киткән вак бизәкле капкага карап пошкыргалап ала.

Ул көнне абыйлары, ишеккә кемдер килеп кагылуга, Кәримәгә булган кирәк- яракларын җыештырырга кушып, өйалдына чыгып китте. Аларның ниндидер ир-ат белән басынкы гына сөйләшеп торуларын ишетте Кәримә. Кулына я бер әйберен, я икенчесен тотып карады кыз. Аннары чыбылдыкның бер башын күтәрә төшеп, өйалдындагы ир-атның тавышын аерасы килепме, ни турында сөйләшкәннәрен беләсе килепме, каты киеренкелек белән, ишек артына колак салды. Ул да түгел, такта белән бүленгән бүлмә артында ваемсыз йоклап яткан әти-әнисенең сулыш алган тавышын ишетеп, Кәримә мышкылдап елап җибәрде. Газим абыйсы аны кияүгә алучы бар дигән иде бервакыт. «Мөгаен, шушы

Фото: vsegda-pomnim.com; иллюстрация: Петр Крохоняткин. 18+

кешедер. Юкка әйбер җыярга кушмыйдыр болар, – дип уйлады Кәримә. – Мине төнгә каршы кая җибәрәләр? Әни белән әтине күрми, газизләремнең хәер-фатихасын да алмый китәмме инде? Мине урлап китүләре түгелме соң бу?»

Ике авыл арасы ерак түгел-түгелен. Алай да 9–10 чакрым булыр. Ул ара чанада толып ябынып утырган Кәримәгә мәңгелек булып тоелды. Мансур әледән-әле сүз катып караса да, Кәримә аңа, оялып, тартынып кына, кыска җаваплар кайтаргач, атын ипләп кенә әйдәкләп барган ир-ат тынып калды. Җылы толып астында Кәримә бераз изрәп китеп, үз уйларына бирелде. Киләчәк бераз шөбһәле дә, көтелмәгәнчә якты, матур, дулкынландыргыч та, билгесез дә иде. «Нинди кеше икән бу Мансур? Аның әти-әнисенә ярап булырмы?» дигән сораулардан алып, моңа кадәр бер күрмәгән ир-ат белән оялмыйча ничек йокларга ятармын дигән сорауга кадәр башыннан үтте Кәримәнең. Ул тагын үз алдына елмаеп алды. Ул төнне дә, тагын киләсе төннәрне дә тимәде аңа Мансур. Бик җайлы, ипле, акыл утырткан кеше иде шул. Кәримәдән 5 яшькә олырак та иде бит. Әти-әниләре дә кәләшне тиешенчә каршылады. Бик карт кына мулла шаһитлар алдында яшьләрнең никахлашырга ризалыгын алып, Коръәндәге «Ән-Ниса» һәм «Ән-Нур» сүрәләреннән ир белән хатын никахына аять әйткәч кенә, ирлехатынлы гомер кичерә башлады алар. Алгы көпчәк кая тәгәрәсә, арткысы да шуннан барыр дип тәвәккәлләп, ваемсыз яшьлеген калдырып, олы тормышка аяк басты кыз.

...Кәримәнең уйларын трактор тавышы бүлде. Хатын җитез генә торып басты да кулында тегеләй дә, болай да эвәләгән ак яулыгын селкергә кереште. «Күрәме икән?» – дигән уй белән, биегрәк булырга теләгәндәй, аяк очларына күтәрелде. Яулыгын җайлабрак тотып, кызурак болгады ул. Тракторның төнге караңгылыкны ертып күренгән тонык утлары зур шатлыгы, зур өмете, киләчәге иде аның.

Трактор гөрелдәве тынгач, һавада яңадан сөйләп аңлата алмаслык сихри тынлык урнашты, җил дә исми кебек. Агачлар әле яшел шәлен ябынырга өлгермәгән, шауламый. Ялгызы гына үсеп утырган карт каен, Кәримә кебек, гәүдәсен турайткалап ыңгырашып алды сыман.

Трактор әйләнеп килгәнче, оеган саннарын язып, бераз йөреп килсә дә ярый. Аның тавышын ишетүгә, яңадан сакка басар Кәримә... Ул зират коймасы буйлап атлады. Бераз яктыра да башлады. Кабер ташлары һөҗүмгә әзерләнгән солдатлар кебек сафка баскан. Яңадан куркуын басарга тырышып, ашыгып үткәнен яңартырга кереште Кәримә. Аның узган сукмагына карап, тормышында булган иң истәлекле хатирәләре белән күңел күген яктыртасы килде. Әммә уйлары аны кабат-кабат йөрәгендә сакланган әрнүләренә кайтарды. Мансуры белән җиде ел гына яшәп калды шул. Ярты ел дигәндә Кәримәдә үз иренә булган сөю хисе ярларыннан ташып тора иде. Ниндидер уртак рухи бәйләнеш бар иде алар арасында. Кәримә, шул хисләргә бирелеп, борын төбеннән генә салмак җыр сузып җибәрде.

Тау буенда чилтер-чилтер
Ага бит ул салкын су,
Син булмагач яннарымда,
Бигрәкләр дә ямансу.

Аннары сирәк кенә башын төртә башлаган үлән астында йоклап яткан әрвахларның рухын куркытмыйм тагын дигәндәй, кинәт туктады да, уйлары Мансурга әйләнеп кайтты. Укырлык-язарлык белеме булганга, аны авыл советы башлыгы итеп куйдылар. Җир җимертеп эшли белгән Мансурны районга алырга торалар иде. Иренең хезмәт кенәгәсендә бары тик шушы бер язма бар. Бу аяусыз сугыш бөтен хыялларын пыран-заран китерде, көле дә калмады, җилгә очты алар. Кичә генә дөнья көлә иде, кичә генә дөньяның бар ягы түгәрәк иде.

Фашист гаскәрләренә каршы барган дәһшәтле сугышның беренче айларында ук диярлек утыз дүрт яшен тутырган Мансурны күршедәге ике яшьтәше белән сугышка алдылар. Кулында вактан-вак, чуктин-чук өч баласын тотып калды Кәримә. Олы улы кырыс сугыш башланган елны укырга керде. «Әни, мин әти дошманны җиңеп кайтсын өчен тырышып укыйм, ямe», – дияр иде Җәмил. Сүзендә торды, көн дә яхшы билгеләр генә алып кайта иде. Кәримә аны һәр көн: «Улым, бүген билгеңне кемгә бирәсең?» – дип кәефләнеп каршылады. «Сиңа», «әтигә» яки «сеңлем Тәслимәгә», кайсы көнне билгеләре ике яшьлек энесе Мөсәвиргә дә эләгә иде.

Мансур артыннан ук Кәримәнең ике абыйсы да сугышка китте. Алар өчен дә җаны өзгәләнә, алар турында уйлары да күңел читен тырнап тора иде Кәримәнең. Алай да, исән-имин кайтырлар, дигән өмет белән яшәде ул.

Биш ай дигәндә ире Мансурның Ленинград өчен барган сугышта хәбәрсез югалуы турында хат алды Кәримә. Күрше авылдан аның белән бергә яуга киткән, терсәктән сул кулын өздереп кайткан ир-ат: «Алар артобстрел вакытында окопка сикереп төшеп кенә үлделәр», – дигән хәбәр белән кайтты. Сыкранды авыр ярадан Кәримә, күкрәгә белән ут йотып, төннәрен дә, көннәрен дә каһәр суккан сугышны каргады. Аямады ул, мәрхәмәтсез, аның Мансурын, Кәримәне дә аямады, нәниләрен дә кызганмады. Ул көннәрдә күңелендәге кара болытны ертып беркайчан да якты кояш чыкмас кебек тоелды аңа. Күпме югалтулар алып килде илгә мәлгунь сугыш. Әнә күрше бичаракай Маһибанәт түтинең ире дә, олы улы да сугышта һәлак булды. Шушы көннәрдә кече улын да хәрби комиссариатка чакыртканнар икән, диделәр. «Син бүген аның хәлен кара, түзә бит, Аллаһ берәүгә дә адәм күтәрмәслек сынау бирмәс», – дип, үз-үзен тынычландырды ул. Елап та, нәфрәтләнеп тә утырып булмый. Өч баланы тәрбияләргә кирәк. Матчага кыстырылган хатлар гына белә иде аның хәлен, алар гына төннәрен койган күз яшьләренең шаһиты иде. Мансурдан килгән хатларны кат-кат укып, яттан өйрәнеп бетергән иде Кәримә. Язмышына буйсынды ул. Синең хакка балаларыбызны исән-имин үстерермен, дип, күңеленнән Мансурына ант бирде хатын. Үзе кебек тол калган хатыннар белән ат җигеп урман эшенә йөрде, кырда урак урды...

Сугышның өченче елы бара иде. Йорт саен – тол, йорт саен – ятим. Әледән-әле яраланып аксак-туксак, гарип-гораба калган, чулак-чукрак булган, я тагын башка сәбәп белән сугышка яраксыз ир-атлар кайта башлады туган төбәккә. Алар өйдә тик ятмады, хатыннар белән колхоз эшенә чыгып йөри башлады. Күпләрен җитәкче итеп куйдылар. Газим абыйсы бер кулын яу кырында калдырып кайтты. Контузиядән соң башы авыртып җәфаланды, мескенкәем. Гата абыйсы да исән-сау, немецны Көнбатышка куып бара иде. Энесе Гариф унсигезен тутырып килә, ватаны өчен яуга барырга аның да чираты җитте.

Кеше бәхетен тар-мар итеп талаучы ачы язмыш ул елны Кәримәнең капкасын тагын килеп какты! Салкын көз уртасында төн буе, питләләре бушап кыегая төшкән капканы, ниндидер шомлы хәбәр китергәндәй, җил ачып-ябып йөрде. «Әни, башым авырта», – дип уянды Мөсәвире. Кәримә, ут янган улын кулына алып, маңгаена юеш чүпрәк куеп карады, догалар укып, тирбәтеп утырды. Хәлсез бала әнисе куенына башын төртеп йокыга талды. Әмма икенче көнне дә, өченче көнне дә башы авыртуга зарланды. Табиблар да сәбәбен таба алмады, төрле дарулар биреп карадылар. Баланың хәле яхшырмады. Җиденче көн дигәндә, ана кулында җан бирде кече улы, төпчеге, йөрәк парәсе. Әле ирен югалту хәсрәте дә сүнмәгән-сүрелмәгән иде. Бәгыре таш булып катты Кәримәнең.

...Трактор тавышы ишетелде. Кәримә уйларыннан бүгенге халәтенә кайтты. Күз нурларын сирпеп, тавыш килгән якка карады. Бу трактор тавышы аның яшәү моңын җырлый иде. Ул, кызу-кызу атлап, кизү торган урынына ашыкты. Кулында әрле-бирле әйләндергән ак яулыгы төн буена инде ничәнче мәртәбә маяк булып хезмәт итте аңа.

Трактор уты, якыная барып, әлҗе-мөлҗе килә. Карашын аерып, йокысыз төннән арыган, дымлы, ялкынсу күзләрен яктырып барган күккә күтәрде Кәримә. Җидегән йолдыз баткан инде. Аның урынына таң йолдызы – Чулпан калыккан. Авылдагы сирәк-мирәк йортның торбаларыннан күксел бөҗра булып төтен пошкый. Кем ипи сала, кем иртәнге аш пешерергә әзерләнә торгандыр. Балаларын, газизләрен, туйганчы ашатып, матурдан-матур өс киемнәре алып киндерә алмаса да, тормыш көннән-көн җайга салынып килә бит.

«Хатын-кызның бәхете – ирдән. Ирле хатыннарның балалары тук, кигән киемнәре мулданрак инде, ни дисәң дә, бер кеше тапкан мал ике кеше тапкан булмас», – дип, уйга чумды Кәримә. Ир кулы тигән каралты-кура, ихата түзек, җыйнак, ыспай була. Кагасы, ямыйсы булса да, кешегә сорап керәсе юк, бәхетле хатынның – бар да үзендә. Баласына мәктәп кирәк-ярагы дисеңме, агачтан чана-чаңгы дисеңме, итек-читек дисеңме... Ата иңен тоеп яшәгән бала канатлы була, зур биеклеккә күтәрелергә пар канаты – әти-әнисе булганнар бәхетле. Сыңар канат ни талпынса да, җирдән ерак китә алмый шул. Аннары үзенең дә сөепсөелер чагы. Егерме сигез яшендә тол калган хатын ир тәмен белеп кенә өлгергән иде әле.

Үзенең яшерен теләкләреннән үзе дә ояла иде Кәримә. Иркәләп, назлап карый торган күзләр, тәме бетми, җаннан китми торган, җылы, өмет бирердәй, юатырдай сүзләр кирәк иде аңа! Дөрес, ялгыз хатынга кайбер әрсезләре төнлә бер генә ишек какмады. Андыйларны бусагага якын да китермәде Кәримә.

Карап туймаслык матур иде ул. Сугыштан соң авыл тирәсендә, тирә-юньдә ир-атлар күбәя төште. Сау-сәламәт кайткан ир-егетләр йорт барлады, гаилә корырга кереште. Кияүгә сорап килүчеләр дә булмады түгел, булды. Күрше авылдан калку гына гәүдәле, тотлыгыбрак сөйләшә торган бер ир-ат килгән иде, аны бер күрүдә үк ошатмады Кәримә. Ул ике йорт аша яшәүче, баласыз тол хатынны кияүгә алды. Авылдашы Мәүлет ничә тапкыр яраширгә дип килде янына: «Балаларыңа ата булырмын, сине кимсетмәм», – диде. Кәримә, яратудан да түгел, мохтаҗлыктан, ялгызлыктан, бу тол язмыштан туеп: «Әллә, тәвәккәлләп, Мәүлет белән уртак тормыш корып җибәримме?» – дигән икеле-микеле уйлар белән йөри башлаган иде. Улы Җәмил каршы төште әнисенең ниятенә. Матчадагы саргаеп беткән хатларны алып итәгенә атты. Ул хатларны кабат-кабат укыды ул төнне Кәримә, кабат-кабат, кабат-кабат... Үзен дә, Мансурны да, балаларын да кызганып елады. Шушы хатлар аңа иренә тугры калырга ярдәм итте ул чакта. Аннары, бар авырлыкны Аллаһ сынавы дип, җанга түзем сорап, сабыр гына яши бирде Кәримә.

Улы Җәмил куандырып торды. Әтисез калган ир бала тормыш камчысын иртә татый. Аны да ятимлек ачысы тиз олыгайтты. Йорт тирәсендәге эшкә кулы ятып тора. Ризыгын хәләл көч белән, тир тамызып табарга кирәклеген белә иде ул. Авыр таш, кузгатсаң, җиңеләя, дигәндәй, булдыра алырдаен – үзе, җайлый алмаганын кешедән сорап, әкренләп олы тормышка кереп китте яшүсмер егет.

Ул елны кызы Тәслимәгә унбер яшь тулды, ә Җәмил җиде классны тәмамлап, Яр Чаллы шәһәрендәге фабрика һәм заводлар өйрәнчеклегенә укырга керде. Балалары үсеп, кул арасына керә башлады дигәндә дә ялгызлыкның, толлыкның михнәтен, җәбер-золымын татыды Кәримә. Мыек калкыткан улын башкалар арасында ким-хур итәсе килмәде аның. Җан өшеткеч кыш айларында, чана тартып, улына ризык илтер өчен, ике мәртәбә илле чакрым җир барды. Ат чанасы ярган юлдан бару уңайлы түгел шул. Чанага салынган бәрәңге капчыгы, төенчекләп бәйләгән башка кирәк-яракны сөйрәп, әйләнә дә төшә, әйләнә дә төшә. Җитмәсә, җигүле атларны юлдан читкә чыгып үткәреп җибәрергә кирәк. Кайсы сүгә, кайсы кызгана...

Кайда туган, шунда уңган, диләрме? Улы, укуын тәмамлауга, колхозга механизатор булып урнашты. Сабый бала сыман ихлас куанды Кәримә! Кем улы дигәндә: «Минем улым ул!» – дип горурланды хатын. Ялгыз булгач, аны кимсетүчеләр дә табылып торды бит. Әмма үзенә башкалардан сүз әйттермәскә тырышты, кеше арасында ким-хур буласы килми иде аның.

...Бүген төнлә Җәмилне зират очындагы басуга җир сукаларга куйганнар иде. Кичтән эштән арып кайткан әнисенә улы тартынып, оялып кына зираттан бик курыкканын әйтте. Кәримә, үзен олылырча тотарга теләп тә, әле балалыктан чыкмаган, унбишен дә тутырмаган улын бик яхшы аңлады. «Улым, үлгәннәрдән курыкма, исәннәрдән курык, – диде тыныч кына. – Каршы килмәсәң, мин дә синең белән барам».

Ашап-эчкәннән соң, Тәслимәгә ишекләрне яхшылап бикләп ятарга кушып, кырга чыгып киттеләр. Бала хакына ни эшләмисең? Кәримә трактор кабинасында басуны берничә әйләнде. Җәмил белән икесенә монда урын бик тар иде. Ул да түгел, Кәримәнең көн дәвамында колхозда авыр эш эшләп ватылган тәннәре трактор селкеткәннән тагын да авырта төште. Колагы томаланды. Кәримә улын зират янында көтәргә булды. Улына ак яулыгын болгап торырга вәгъдә биреп, трактордан төшеп калды. Тимер ат кузгалып киткәч, бик куркып кына зират коймасына таба атлады. Күкрәгенә сөт төшкән яшь хатын кебек, әле күптән түгел генә суы тулып аккан каенга тотынып, кара ташларга озак кына карап, өнсез басып торды. Тирә-юньдә бер тавыш та килми, тыныч иде. Монда аның йөрәк парәсе – Мөсәвире ята. Хатын күз яшьләрен түгеп арыган иде. «Улым, бүген мин синең янәшәңдә», – дип уйлады ул. Куркуы бетеп киткәндәй булды. Аякларын да юньләп тоймаган Кәримә зират коймасына терәлеп утырды. Ул бераздан оеп йоклап киткәнен сизми дә калган иде.

Таң атты. «Кара әле, улының трактор тавышы хәйраннан бирле ишетелми. Әйләнеп килер вакыты җиткән иде бит», – дип, айнып киткәндәй булды ул. Җәмилнең: «Әнии-и!» – дип кычкырганына, тавыш килгән якка башын борды. Кыр читендә улы, әнисен үзенә чакырып, кулын болгап тора иде. Кәримә, ярым йөгереп, ярым атлап, улы янына кузгалды. Җәмил әнисе килеп җиткәнче үк: «Без Сабир белән кырның теге башында алышындык. Мин, аякларым язылсын дип, такыр җирдән җәяү килдем», – дип, елмаеп каршылады аны. Әнисе улын аркасыннан сөйде. «Әни, син минем зираттан курыкканны кешегә сөйләмә яме», – дип, читенсенеп өстәде улы. Әнисе аңа ягымлы итеп елмайды да баш какты.

Ике чандыр, тәбәнәк гәүдә, бераз бөкрәя төшеп, кояш нурларыннан үрелгән сукмакка атлады. Алда аларны матур тормыш көтә иде. Әмма Кәримә, калган ике баласыннан да узып, ялгызы гына бик озак гомер итәсен белми иде әле.

ПАТША САРАЕ СЕРЛӘРЕ (0+)

Казан Кремленең Губернатор сараен ни өчен элеккеге хан сарае урынында ук салганнар? Аның мигъмары кем? Хакимлек итүче Романовлар династиясе резиденцияләреннән берсе саналган император фатиры нинди булган? Бу һәм башка сорауларга җавапны «Император фатирлы йорт» күргәзмәсендә табарга мөмкин. Биредә Губернатор сараендагы борынгы җиһазларга хозурланырга, археология раритетларын һәм хәтта XVI гасыр тәңкәләре хәзинәсен күрергә була. Экспозициянең бер өлеше Казан ханлыгы чорындагы хан сараена һәм XVI–XVII гасырлардагы патша даирәсенә багышланган. Хәзер исә Губернатор сараенда Татарстан Республикасы Рәисе резиденциясе урнашкан.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр). Дүшәмбе – ял көне

Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

афиша

«ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» КАБАТ СӘХНӘДӘ (16+)

Камал театры «Тапшырылмаган хатлар» спектакле премьерасына чакыра. Гадел Кутуй повесте буенча пьесаны яшь драматург Энҗе Гыйззәтова язган, әлеге заманча мәхәббәт тарихын ГИТИСның режиссёрлык факультетын тәмамлаган Әскәр Галимов куйган. 1930 нчы елларда тәмамланып, дөньяның кырыктан артык теленә тәрҗемә ителгән мәшһүр әсәрнең яңача укылышы вакыт белән сыналган хакыйкатьләрне дәлилләү өчен гайре табигый чишелешләр һәм яңа мәгънәләр вәгъдә итә. Премьера легендар татар режиссёры Марсель Сәлимҗановның 90 еллыгы уңае белән сәхнәләштерелә.

28 ноябрь, 19:00. Зур зал

Г.Камал исем. Татар дәүләт Академия театры

Казан, Татарстан ур., 1

БӨЕК ҺӘМ ОНЫТЫЛГАН АВАНГАРД (6+)

Парадокс: моннан 100 ел элек әзерләнгән күргәзмә хәзер генә дөнья күргән. Мәскәү, Петербург, Казандагы авангард һәм реалистик рәсем сәнгате осталарының өч йөзләп эше хакында сүз бара. Авторларның исемнәре генә дә ни тора! Николай Фешин, Василий Кандинский, Александр Родченко, Варвара Степанова, Ольга Розанова... Өченче күчмә сәнгать күргәзмәсе өчен сайлап алынган картиналар, графика һәм сыннарны 1921 елда Вятка губернасы шәһәрләрендә күрсәтергә карар кылына. Экспонатлар арбаларда күчерелә, Яранскига гына килеп җитә алалар, аннары юлсызлык һәм акча юклыгы сәбәпле туктап калалар. Картиналар турында искә төшерүче дә булмый, һәм XX гасыр азагына кадәр алар Вятка губернасы музейларының запасникларында саклана... Бүгенге экспозициядә башлангыч чор совет сәнгате күренекле вәкилләренең Вятка сәнгать музее, Яранск төбәкне өйрәнү музее, Слободской төбәкне өйрәнү музее, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм шәхси тупланмаларда сакланган ике йөздән артыграк әсәре күрсәтелә.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр)

Кабул итү урыннарының Күргәзмәләр залы

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, kamalteatr.ru, puppet-show.ru

«ТУГАН-ТУМАЧА» ҺӘМ МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР (12+)

Безнең тормыш сәяси катаклизмнардан, җете глобаль вакыйгалардан, зур фәнни ачышлардан тора. Ләкин гомеребезнең 90 проценты кечерәк вакыйгалардан үрелгән: балаңны ашатырга акчаң, мичкә ягарга утының, баш өстеңдә түбәң бармы, гаиләңне асрый аласыңмы һ.б. Бу мәшәкатьләр безнең көнкүрешебезнең 90 процентын тәшкил итә. «Туган-тумача» – шушы 90 процент вакытны ничек лаеклы итеп яшәү турындагы спектакль. Ул режиссёр Илгиз Зәйниевнең тормыштан алып, әбисе сүзләренә нигезләнеп язылган әсәре. Биредә 1950–1970 нче елларда татар авылында яшәүчеләрнең тормышы күрсәтелә. Геройларның прототиплары – авыр язмышлы, төрле холыклы реаль кешеләр. Әлеге спектакльдә язмышлар каршылыгы, характерлар бәрелеше, мәхәббәт һәм нәфрәт урын алган. Моннан тыш, спектакльдә татар хатын-кызларының рухи көче, физик ныклыгы да чагылыш тапкан.

22 ноябрь, 18:30
К.Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры
Казан, Горький ур., 13



ГҮЗӘЛ ЭПОХА ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ (6+)

«Эрмитаж-Казан» үзәгендә ачылачак яңа экспозиция безне Belle Epoque, яки Гүзәл эпоха (Европа тарихының XIX гасыр азагыннан алып 1914 елга кадәр чоры шулай атала) белән таныштыра. Әлеге дәвер сынлы сәнгатьтә һәм бөтен дөнья тарихында үзгә бер урын алып тора. Европа өчен иң бәхетле һәм ваемсыз еллар бу, гөрләп үсү, тынычлык, муллык эрасы. Һәм барыннан да бигрәк Франция өчен – Belle Epoque атамасы шунда туган. Гүзәл эпохада иҗат ителгән даһи әсәрләр – кешелекнең бөек мирасы. Казан экспозициясенә Камил Писсарро, Клод Моне, Поль Гоген, Андре Дерен, Огюст Ренуар, Анри Море, Альфред Сислей, Поль Сезанн, Анри Матисс, Пабло Пикассо, Анри Руссо, Альфред Моурер, Альфонс Муха, Анри де Тулуз-Лотрек, Эжен Грассе һәм башка осталарның әсәрләре куелган.

29 ноябрьдән. Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр). Дүшәмбе – ял көне
«Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 нче кат
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

МИЛЛИ КИЕМ КҮРГӘЗМӘСЕ (0+)

«Казанское Поволжье: образы народной культуры» күргәзмәсендә XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырның беренче яртысында яшәгән рус, татар, башкорт, мари, мордва, чуваш һәм удмуртларның 40 тан артык милли кием комплексын күрергә була. Әлеге уникаль экспозиция – Татарстанда үткәрелгән зур фәнни-тикшеренү эше нәтиҗәсе. Киемсалым, бизәнү әйберләре, аксессуарларны яңадан торгызу өчен, музей фондларында, хосусый тупланмаларда, мәктәпләрдә сакланган сирәк экспонатларны өйрәнгәннәр. Нәтиҗәдә Татарстан халыклары традицион бәйрәм мәдәнияте үрнәкләренең уникаль галереясы пәйда булган.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Кабул итү урыннарының Күргәзмәләр залы
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

СӘХНӘДӘ – «ФИЛАРМОНИАДА» (12+)

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә «Филармониада» Халыкара сәнгать фестиваленең чираттагысы үтә. Беренче тапкыр фестиваль 2008 елда оештырылды. Максаты дөньякүләм танылган осталар катнашында югары дәрәҗәдәге сәнгатьне күрсәтү, яңа исемнәр ачу иде. Фестиваль классика, фольклор, эстрада, джаз, нәфис сүз, бию һәм башкалар кебек сәхнә сәнгатенең төрле юнәлешләрен чагылдыра.

Фестиваль «Простак в мире джаза» дип аталган концерт белән башланып китә. Татарстан Республикасы филармониясенең джаз оркестры һәм Россиянең атказанган артисты Борис Галкин тамашачыларга кызыклы программа әзерләде.

5-15 декабрь көннәре.
Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе,
Казан, Павлюхин ур., 73

«КҮЧӘ КОМНАР», КАЛА ЭЗ...

Гарәп дөньясының гына түгел, ә бөтен җир шарының иң эре, мәртәбәле Халыкара китап фестивале һәм ярминкәләренең берсе 5–17 ноябрь көннәрендә Шарджада узды. 2024 елгы фестивальдә 112 илдән 2 500 нәшрият, 450 дән артык язучы һәм әдәбият галиме катнашты. Чараларның санына килсәк, 1 350 гә җитә иде.

Кышка кереп барган Шарджа безне 38 градуска җитә торган челләсе, көн әйләнәсе яңгырап торган азан моңына күмелгән мәһабәт мәчетләре, күккә ашкан йортлары белән каршы алды.

Кайда гына бакма, китап фестивале белән бәйле реклама: таблолар, транспарантлар, инсталляцияләр җирле халыкны да, туристларны да елның иң көтелгән вакыйгаларының берсенә әйдәп тора.

– Китап бар нәрсәнең башында тора, ул кешелек туплаган кыйммәтләр белән казанышларның сакчысы, – дип башлады сүзен Шарджа китап фестивале белән ярминкәсенең генераль директоры Әхмәд әл-Әмәри. – Мәгълүмат чиксез артып киткән заманда китапның шәхси белем туплау өчен дә, җәмгыятьнең тулаем прогрессы өчен дә төп чыганак булуын онытмаска кирәк.

Ачылыш тантанасында Шарджа тагын бер сокландырды: 4 экранга, диварлар белән түбәләргә берьюлы күз явын алырдай манзаралар проекцияләнде. Көне буе гөрләп торган ЭКСПО төнлә дә тынмады. Классик форматтагы чаралардан тыш, бу елны «Поэзия төне» дә планлаштырылган иде, ул гарәпчә, инглизчә, урду, пенджаби, малаялам һәм тагал телләрендә узды. Тере музыка белән кушылып-үрелеп киткән шигъри чыгышлар мәдәниятләр арасында булган чикләрне юкка чыгара.

Быелгы тагын бер үзенчәлек – креатив язу буенча оештырылган махсус семинарлар. Аларга теркәлеп, гарәп, Мисыр, Канада, Америка авторларыннан язарга өйрәнү серләренә төшенергә була иде.

Теләсә кайсы илнең мәдәниятен аның ризыгын авыз итеп карамыйча татып-сеңдереп булмый, диләрме әле? Һәм бу, чыннан да, дөрес! Шуңа ЭКСПОдагы Кулинар почмак турында да әйтми булмый. Вьетнам, Оман, Ирландия, Словения, Непал, Көньяк Африка Республикасы һ.б. илләрдән килгән 17 шеф-повар монда телне йотардай хикмәтле сыйнигъмәтләр «иҗат итте».

Ап-ак ком чүлләре, пляжлары, утлары белән балкып, озатып калды Шарджа. Кайчандыр күренекле нәшир, меценат Закир Рәмиев, шагыйрь Дәрдемәнд әйткәндәй, «комнар күчә» торды, ә без ул комнарда Татар иленнән килгән сүзебезне, эзебезне калдырып кайтып киттек...

...киләсе очрашуга кадәр!

Фотолар Луиза Шарова, Алексей Арзамазов, фестиваль архивыннан



Коръәнгә һәйкәл.

Жыелыштык һәм гәпләшәбез.

Китап фестивале һәм ярминкәсеннән күренешләр.

Төнге Шарджа күренешләре.

AIGUL.USMANOVA
КЕЙТЕРИНГ
Тәмле сый бергә булсын!
БАНКЕТЛАР | ФУРШЕТЛАР | БОКСЛАР
Бер кеше өчен 600 сумлык меню
Казан ш., Крутая ур., 3
+7 (843) 203-45-00
+7 (937) 154-00-16
kazan.aigul-usmanova.ru
*Айгөл Усманова
Реклама Усманов Линар Марселевич ШЭ